ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№11 (323) – НОЯБРЬ 2018

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Президент маршрутлары буенча

Каз өмәсе – борынгыдан килгән гадәт

Күн авылы: хикмәтле атамалар

ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ – БАЛАЧАК ШАГЫЙРЕ

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

ЭТ ӨРӘ, КӘРВАН БАРА…

«Сез ерткыч икәнсез, әфәнделәр!» – дип, «Раба любви» фильмындагы атаклы гыйбарәне кабатлыйсы килә. Социаль челтәрләрдә кайсыдыр бер ватандашыбызның шаярып язган постын усал шәрехләр белән «утка тота» башлаганда, гадәттә. Тәнкыйтьчеләр юморны аңлап та җиткермәскә мөмкин. Йә булмаса, тулы контекстны бөтенләй исәптә тотмаска. Тик яза, тәнкыйтьли! Менә шуннан китә инде…

Ә кемгәдер юморны аңлау сәләте бөтенләй бирелмәгән булырга мөмкин. Бу бит музыкага сәләт булмау белән тәңгәл: әйтик, тирә-юньдәгеләрнең тавышыбыздан колаклары тонса да, без, аны шәйләмичә, мавыгып җырлавыбызны дәвам итәбез. Ничек инде җырламыйсың ди, йөрәк җилкенгәндә! Шуңа да бу чытырманга – шәрехләр чытырманына – кереп тормавыгыз яхшырак. Табиблар киңәш итми! Сәламәт булыйм, дисәгез, социаль челтәрләрдә чабулап йөрмәгез, шәрехләр белән иш-куш булмагыз һәм бер алтын кагыйдәне истә тотыгыз: сезнең артыгыздан төкереп калалар икән, димәк, сез алдарак дигән сүз!

Икенче бер гади дә, үтемле дә киңәш: әниегезгә шалтыратып, аны Әниләр көне белән тәбрик итегез! Тәбрикләргә соңга калсагыз, болай гына – сөйләшеп алыр өчен генә булса да шалтыратыгыз! Калганы – тормышның гадәти ыгы-зыгысы гына. Аңа әллә ни игътибар итеп торырга кирәкми.

Сәламәтлек телибез сезгә – рухи яктан да, мәгълүмати өлкәдә дә.

СЕЗНЕҢ БАР ЯКТАН ДА СӘЛАМӘТ РЕДАКЦИЯГЕЗ

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Олеся Бондаревская,
Руфия Фазылова
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Сафа Гәрәев, Ксения Сёмина, Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыктагы фото: халык шагыйре Шәүкәт Галиев
Фото Галиевларның гаилә архивыннан алынды

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Татар телендә тираж: 1000 данә,
рус телендә: 2500 данә

Гомуми тираж: 3500 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № Е-3109
Басарга кул куелды: 23.11.18

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Сату бүлеге белгече: Гүзәл Подольская

Коммерция директоры урынбасары:
Җамилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **924 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7076** – татар телендә
Индекс **П7077** – рус телендә

Альфрид Шәймәрданов. «Сальвадор Дали кышын Казанда»

НОЯБРЬ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

5. Республикада, илдә, дөньяда.
Татарстан Президентының эш сәфәрләре

14. «Перезагрузка» стереотипларны җимерә.
Бизнеста ничек революция ясарга

20. Дингә бару юлы.
Дингә ышанучыларның хисләре белән кемнәр уйный

26. Иман ярдәмендә терелү.
Наркотикларга бәйлеләрне ничек яңадан тормышка кайтаралар

34. Интернет баш миен буйсындырырмы?
Тормышын «офлайн»нан башка күз алдына китермәүчеләргә нәрсәдән сакланырга кирәк

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

42. Безнең сафларга бас, туган.
Көзге «Керәшәләр» кайларга чакыра

56. Сез хезмәт итегез. Без көтәрбез.
Солдат өчен эш урыннары кайда саклана

50. Борынгыдан килгән гадәт.
«Каз өмәсен»дә кунакта

56. Татар ашлары.
Иң тәмле табикмәкне кем пешерә

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

62. Тарихи сәхифәләр.
Казан ханлыгының беренче ханы кем булган

66. Китап киштәсе.
Композиторлар язган китаплар нинди була

70. Кече ватан патриотлары.
Шәүкәт Галиевның юбилее уңаеннан

84. Татар авыллары.
Күннән атка әйләнгән авыл

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

26.10

Антон Силуанов, РФ Хөкүмәте Рәисенең беренче урынбасары – финанс министры, – Казанда, Россия Федерациясе һәм Казахстан Республикасы арасында хезмәттәшлек буенча Хөкүмәтара комиссиянең пленар утырышында:

– Татарстан – уңайлы инвестиция климаты булдыру буенча Россиядәге иң алдынгы субъектларның берсе. Республика тулай продукт үсешенең югары темпларын күрсәтә. Бу илдәге уртача күрсәткечтән ике тапкырга артыграк.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

7.11

Павел Колобков, РФ спорт министры, – ТР Хөкүмәте һәм РФ Спорт министрлыгы арасында Физик культураны һәм спортны үстерү өлкәсендә бәйләнешләр булдыру, хезмәттәшлек итү турында килешү төзегәннән соң:

– Планнар зурдан, Татарстан безнең өчен – әһәмиятле партнер. Шулай ук спортка булган мөнәсәбәт белән спорт принциплары буенча да. Спорт белән шөгыльләнүчеләр исәбе буенча да Татарстан лидерлар арасында – бу халыкның 40%ы. Биредә спорт белән бәйле күпсанлы программалар тормышка ашырыла.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

7.11

Зураб Церетели, сынчы, – Казанда, Россиядә Рудольф Нуриевка беренче һәйкәл ачылу тантанасында:

– Мин бу сынны күтәренке рух белән, яратып эшләдем. Бу – җан авазы. Мин Казанны бик яратам, бу – уникаль шәһәр. Монда күп тапкырлар булганым бар. Сездә – менә дигән тарих бар, һәм аны, сәнгать теленә күчереп, күтәргә генә кирәк.

Фото ТР Президенты сайтыннан

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Татарстан Президенты **КАЙЛАРГА** юл тота

Клиент хакына бизнес **НӘРСӘГӘ** әзер

Шәхси пространствоны **НИЧЕК** сакларга

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

2019 елның
I яртыеллыгына
**«Татарстан»
журналына язылу
дәвам итә**

Реклама 16+

«Татарстан» журналына ТР буенча язылу индекслары:

П 2381 **татар телендә** 924 сум 00 тиен

П 2378 **рус телендә** 924 сум 00 тиен

«Татарстан» журналына РФ буенча язылу индекслары:

П 7076 **татар телендә**

П 7077 **рус телендә**

ПРЕЗИДЕНТ МАРШРУТЛАРЫ БУЕНЧА

Татарстан Президентының эш графигы никадәр тыгыз булуын аңлар өчен, бернинди махсус хронометраж таләп ителми. Аның сәфәрләре маршрутына күз салу да җитә. Республика, ил, дөнья буйлап туктаусыз йөри ул. Еш кына Рөстәм Миңнеханов иртән нинди дә булса Европа илендә потенциаль инвесторлар белән сөйләшүләр үткәрергә, көндез Россия башкаласындагы мөһим киңәшмәдә катнашырга өлгерә, берничә сәгатьтән соң исә Әлмәттә нефть тармагы үсеше перспективаларын тикшерә... Һәм көн саен диярлек шундый хәл күзәтелә.

Юлда үткән сәгатьләр һәм чакрымнар, мөһим очрашулар, җитди чыгышлар һәм җаваплы карарлар. 2018 елның көзе дә вакыйгаларга бай булды. ТР Президентының соңгы арадагы эш сәфәрләреннән «Татарстан» аеруча әһәмиятлеләрен сайлап алырга тырышты.

РОССИЯ – ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ. **ТАТАРСТАН КҮПЕР САЛА**

«IslamicEconomyAward» премиясен 2013 елда Дубай ислам икътисадын үстерү үзәге булдырган. Ул мөселманнарның социаль-икътисадый муллыгын арттыруга саллы өлеш керткән бизнес-инициативалар һәм инновацион идеяләр өчен бирелә. Инициатива һәм идеяләр ислам илләре арасындагы икеяклы сәүдә һәм инвестицион мөнәсәбәтләрне ныгытуга һәм дөньядагы башка илләр белән икътисадый бәйләнешләрне куәтләндерүгә булышырга тиеш.

НӘРСӘ:

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Дубайдагы (Берләшкән Гарәп Әмирлекләре) Глобаль ислам икътисадый саммитында (GlobalIslamicEconomy Summit) чыгыш ясады. Биредә үк Дубай әмирлеге тәхетенә утырырга тиешле принц Хамдан бин Мөхәммәд бин Рәшид Әл Мактум ТР Президентына ислам икътисадын үстергән өчен махсус бүләк – «IslamicEconomyAward» премиясен тапшырды.

КАЙДА:

Дубай

КАЙЧАН:

30 октябрь

Фото: ТР Президенты рәсми сайтыннан алынды; Марсель Бадыкшин

ТУЛЫРАК:

Форум кысаларында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Дубай әмирлеге тәхетенә утырырга тиешле принц Хамдан бин Мөхәммәд бин Рәшид Әл Мактум, БГӘ икътисад министры Солтан бин Сәет Әл Мансури, Хосусый секторны үстерү ислам корпорациясе (Ислам үсеш банкы бүлекчәсе) җитәкчесе Айман Сиҗәни белән очрашулар үткәрде.

Россия – Берләшкән Гарәп Әмирлекләре мөнәсәбәтләре кысаларында Татарстан белән БГӘ арасында сәүдә-икътисадый хезмәттәшлек мәсьәләләре, ислам банкингы тармагындагы бүген республика территориясендә гамәлгә кертелә торган проектлар тикшерелде. Шулардан берсе – Татарстанда Халыкара ислам финанс үзәген төзү проекты – Россия Саклык банкы белән бергәләп тормышка ашырыла.

БЕЛЕШМӘ:

GIES – ислам икътисады һәм хәләл индустриянең иң зур вакыйгаларыннан берсе. Форум төрле тармаклардагы әйдәп баручы дөньякүләм танылган экспертларны берләштерә. Быел анда бөтен дөньядан өч меңгә якын делегат катнашкан.

Россия Президенты Владимир Путин кушуы буенча Рөстәм Миңнеханов 2014 елдан бирле «Россия – Ислам дөньясы» Стратегик күзаллау төркемен җитәкли. Россиянең ислам дөньясы белән мәдәни-цивилизацияле нигездә тагын да якынаю процессына һәръяклап булышу, төп халыкара проблемалар буенча позицияләрне килештерү, шулай ук икътисадый хезмәттәшлекне киңәйтүгә һәм яшьләр оешмаларының үзара элемтәләрен җайлауга булышлык күрсәтү Төркемнең төп бурычы булып тора.

КАЗАН ҺӘМ ТОМСК АРАСЫН ИННОВАЦИЯЛӘР ЯКЫНАЙТА

НӘРСӘ:

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Томск өлкәсе губернаторы Сергей Жвачкин Татарстан Республикасы белән Томск өлкәсе арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник һәм социаль-мәдәни хезмәттәшлек турында Килешү имзалады. Документны 2018–2021 елларда гамәлгә кертү буенча чаралар планы кабул ителде.

КАЙДА:

Томск

КАЙЧАН:

8 ноябрь

– Татарстан белән Томск өлкәсен күптәнге дустанә мөнәсәбәтләр бәйли. Башкача булуы мөмкин дә түгел. Безнең төбәктә татарлар икенче титул милләте булып тора – барлыгы 17 мең татар исәпләнә. Алар арасында эшкуарлар, идарәчеләр шактый, татарлар төбәкнең мәдәни тормышында мөһим роль уйный.

Сергей Жвачкин,
Томск өлкәсе губернаторы

Фото: ТР Президенты рәсми сайтыннан алынды; Марсель Бадыкшин

ТУЛЫРАК:

Татарстан Президенты һәм Томск өлкәсе губернаторы өлкә татар җәмәгатьчелеге активы белән очрашты һәм җирле Татар мәдәнияте үзәгенең 25 еллыгына багышланган концертны карады. Томск өлкәсендә берничә татар иҗтимагый оешмасы эшли. Татар вокал-хореография коллективлары, яшьләр клубы, татар телен һәм традицияләрен өйрәнү буенча балалар өчен төрле түгәрәкләр бар.

Татар общинасы вәкилләре Рөстәм Миңнехановн һәм Сергей Жвачкиннан Томскидагы XVII гасыр башында нигез салынган Татар бистәсенең тарихи йөзен саклауда ярдәм итүләрен үтенде. «Тарихи-мәдәни мирасны саклау буенча республиканың тәҗрибәсе зур, без бирегә белгечләребезне җибәрербез, алар сезгә ярдәм итәр», – дип вәгъдә бирде Татарстан Президенты.

БЕЛЕШМӘ:

Татарстан Республикасы белән Томск өлкәсе арасында тәбәкара товар әйләнеше 1,7 миллиард сум тәшкил итә. Татарстан Томскига җиңел һәм йөк автомобильләре, автошиналар, пыяла, медицина җиһазлары, дарулар һәм төрле азык-төлек җибәрә. Томск өлкәсеннән республикага медицина эшләнмәләре, кабельләр, кондитер эшләнмәләре һәм консервлар кайтарыла.

– Томск өлкәсе Россиянең әйдәп баручы инновацион төбәкләреннән берсе санала. Безгә югары технологияләр, фәнни-техник хезмәттәшлек һәм белем бирү тармагында үзара хезмәттәшлекне арттыру кирәк. Модернизация һәм инновацияләр тармагында мәгълүмат, студентлар һәм фәнни кадрлар алмашы реаль файда китерергә мөмкин.

Рөстәм Миңнеханов,
Татарстан Президенты

ПЕТРОПАВЛОВСК. БОЛГАРДА ОЧРАШКАНЧЫГА КАДӘР!



Фото: ТР Президенты рәсми сайтыннан алынды; Марсель Бадыкшин

НӘРСӘ:

Петропавловскида дәүләт җитәкчеләре Нурсолтан Назарбаев һәм Владимир Путин катнашында үткән XV Россия һәм Казахстан төбәкара хезмәттәшлек форумының темасы – «Казахстанда һәм Россиядә туристлыкны үстерүдә яңа алымнар һәм тенденцияләр». Форум эшендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты. Татарстан Республикасы форум кысаларында ачылган туристлык күргәзмәсендә үз экспозициясен тәкъдим итте. Россия һәм Казахстан президентлары Татарстан экспозициясе белән танышты. Рөстәм Миңнеханов аларга ТРнда туристлык индустриясе үсеше һәм Казахстан белән хезмәттәшлек турында сөйләде.

КАЙДА:

Петропавловск

КАЙЧАН:

9 ноябрь

– Төрле пландагы актив төбәкара элемтәләр безнең илләр арасында дуслыкны һәм ике як өчен дә файдалы партнерлыкны ныгытуда, чын күршеләрчә, союзникларча Россия-Казахстан мөнәсәбәтләренең бөтен комплексын үстерүдә бик мөһим роль уйный.

Владимир Путин,
Россия Президенты

ТУЛЫРАК:

ТР Президенты Казахстан белән Татарстан арасында «Бөек Идел юлы» проектын үстерү турында килешүләр имзалануын искә төшерде. Аның максаты – Казахстан белән Татарстан, Россиянең башка төбәкләре арасында икеяклы туристлык агымын активлаштыру. ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән Бөек Болгар – Татарстан хәзинәләре арасындагы энҗе, ул туристлар агылуына лаек урын. Рөстәм Миңнеханов, булган потенциалны мөмкин кадәр күбрәк файдалану зарур, дип саный. Анда инде кирәкле инфраструктура булдырылган, иң заманча таләпләргә җавап бирерлек «Кол Гали» кунакханәсе ачылган.

Рөстәм Миңнеханов Россия Президенты Владимир Путинга борынгы Болгар шәһәрен барып күрергә, шулай ук Казахстан Президенты Нурсолтан Назарбаевны да чакырырга тәкъдим итте. Ике ил җитәкчесе борынгы шәһәрнең матурлыгын һәм бөеклеген үз күзләре белән күрсә ничек яхшы булыр иде!

БЕЛЕШМӘ:

Россия һәм Казахстан төбәкара хезмәттәшлеге форумы 2003 елдан бирле ел саен әле бер, әле икенче илдә, гадәттә ике дәүләтнең чик буендагы шәһәрләрдә уздырыла. Форум эшендә дәүләт башлыклары, төбәк һәм хакимият җитәкчеләре, бизнес вәкилләре катнаша.

МАХАЧКАЛА. ИГЕЛЕК ҺӘМ ИМАН ТУРЫНДА

НӘРСӘ:

«Россия – Ислам дөньясы» Стратегик күзаллау төркеме рәисе, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановҗһәм Дагыстан Республикасы Башлыгы Владимир Васильев рәислегендә «Россия – Ислам дөньясы» Стратегик күзаллау төркеменең IV утырышы үткәрелде. Утырыш яшьләр арасындагы экстремистлыкка каршы тору һәм тыныч ислам традицияләрендә белем бирү мәсьәләләренә багышланган иде.

«Россия – Ислам дөньясы» Стратегик күзаллау төркеменең IV утырышы нәтиҗәләре буенча резолюция кабул ителде. Аерым алганда, анда: «Экстремистлыкка каршы көрәшнең көнүзәк мәсьәлә булуын күздә тотып, инде файдаланыла торган чараларга идеологик, белем бирү төрендәге эшләрне өстәүне максатка ярашлы дип саныйбыз. Безнең төп бурычыбыз – радикаллык һәм террорчылык котырынуына каршы тору гына түгел, әмма беренче чиратта әлеге җинаятьчел идеяләрнең таралуын булдырмау буенча превентив эш алып бару ул», – диелгән.

КАЙДА:

Махачкала

КАЙЧАН:

12 ноябрь

Фото: ТР Президенты рәсми сайтыннан алынды; Марсель Бадыкшин

ТУЛЫРАК:

Утырышта катнашучылар Россия-мөселман уртак «Булачак лидерлар академиясен» төзү турында тәкъдимне бертавыштан хуплады. Уртак фикер буенча, мондый академия террорчылыкка каршы көрәшнең нәтиҗәлелеген арттыру мөмкинлеген генә биреп калмыйча, иң мөһиме, «радикаль идеяләрнең тууына һәм таралуына каршы торырга сәләтле кешеләр әзерләячәк. Әлеге проект Якын Көнчыгыштагы вазгыятьне тотрыкландыруда гына түгел, гомумән халыкара эшләрдә киеренкелекне киметү өчен зур әһәмияткә ия».

Стратегик күзаллау төркеменең IV утырышын тәгәлләп, Рөстәм Миңнеханов «Россия – ислам дөньясы» милли премиясен тапшырды. 2018 елда әлеге бүләккә Ришат Хәмидуллин («Хозур» Нәшрият йорты, Татарстан, динара һәм милләтара дошманлыкны кисәтүгә багышланган һәм экстремистлыкка каршы юнәлтелгән социаль роликларны эченә алган «Просто о главном» фильмы) һәм Хаҗиморат Рәҗәпов (Дагыстан, яшьләрне әхлакый һәм патриотик тәрбияләү, җәмгыятьтә конфессияара диалогны пропагандалау, тынычлыкны һәм үзара хөрмәтне ныгыту турында «Человек и вера» документаль проекты) лаек булды.

БЕЛЕШМӘ:

«Россия – Ислам дөньясы» милли премиясе ислам хакында белемнәрне арттыру һәм таратуга, Россия халыкларының үзара аңлашуына ирешүгә һәм дәүләт-конфессия мөнәсәбәтләрен гармонияләштерүгә өлеш керткән өчен ел саен тапшырыла.

КЛИЕНТ ХАКЫНА СИН НӘРСӘГӘ ӘЗЕР?

Казанда «Перезагрузка 2.0» форумы узды. Танылган дөнья һәм Россия спикерларына Татарстан эшмәкәрләреннән һәм әлегә үз бизнесы турында хыяллана гына торган кешеләрдән торган тугыз меңлек (!) аудиториягә үсеш траекториясен күрсәтү, шулай ук аларны уңышның конкрет кораллары белән тәэмин итү өчен нибары бер көн бирелде.

...Алып баручы «Татнефть-Арена»ның шыгрым тулы аудиториясен, алдан уйлаганча тәэсир итеп, планлы рәвештә җанландыра башлады. «Бизнес һәм эшмәкәр үзе энергияле булырга тиеш, дигән шарт белән кем дә кем килешә, шул кулын күтәрсен!» – дип кычкыра ул залга. Аңа җавап итеп, меңләгән кул өскә күтәрелә. «Кемнәр минем белән, җәмәгать?!» Куллардан урман үсеп чыга, диярсең. Әмма бу да чик түгел – публикага зарядка ясарга тәкъдим итәләр. Һәм мин үз күзләремә ышанмый торам: меңләгән кеше, дәррәү урыннарыннан куба. Сәхнәдә – тоташ хисләр ташкыны, трибуналар драйвтан дер селкенә. Хоккей җанатарлары турында сүз дә була алмый! Бирегә килгән эшмәкәрләр кебек аудиторияне «Татнефть-Арена» залының әле, мөгаен, моңарчы күргәне булмагандыр. «Күбрәк энергия! Гәүдәгез дә, акылыгыз да энергия өчен ачык булсын!» – дип әфсенли алып баручы микрофонын да, кешеләрне дә. «О-оо-оо!» – дип, аның сүзләрен хуплап, җавапка сөрән сала меңләгән кешелек аудитория. Ә аннан инде «хакыйкать мизгеле» үзе дә килеп җитә. Ул килеп җиткәч, залдагы һәр кеше үз-үзенә сорау бирергә тиеш була: «Мин монда нәрсә өчен?» Ут сүнә, дөм караңгы пространствода, шәмнәр сыман, смартфоннарның уты гына келпеп кала. Беренче ассоциация – Лужники стадионындагы Виктор Цой концерты кадрлары, әйтерсең. Хәер, юк, ул түгел, билгеле. Бүген аның урынына алмашка инде башка кумирлар килде.

Фотолар «Синергия» Университеты Бизнес Мәктәбеннән алынды

ПЕРЕЗАГРУЗКА 2.0

Автор:
Ольга Туманская

Ә СИН ЛИДЕРМЫ?

«Без инде үз көчен сарыф иткән, искергән кануннарны үзгәртергә кирәк икәнлеген аңлыйбыз». «Без эшмәкәрләргә йөзебез белән борылып басачакбыз һәм салым шартларын яхшыртачакбыз». РФ Хөкүмәте Рәисенең беренче урынбасары Антон Силуанов чыгышы, аңлашыла инде, тоташ алкышларга күмелде. Күрәсең, ул «Татнефть-Арена»да утырган сигез меңләп кешенең һәм онлайн-трансляция барган Чаллы IT-паркындагы тул-тулы залның нәкъ менә ишетергә теләгән сүзләрен әйткәндер. Ә аңардан да көчлерәк алкышларга ТР Президенты сүзләре лаек булды. Сүз уңаеннан, алдагы елдагы «Перезагрузка»да Миңнехановтан... отжимание ясавын – идәннән күтәрелүен үтенгәннәр иде. Тик торганнан гына түгел, әлбәттә, ә #ВыборЧемпионов180318 Бөтенроссия милләтара эстафетасы кысаларында. Шунда ук, сәхнә уртасында, хәтта пиджагы белән галстугын да салып тормыйча, Рөстәм Нургалиевич тиешлечә – 18 тапкырга җиткәнче отжимание ясаган иде. Бу юлы аңа спорт өлкәсендә каһарманлыклар күрсәтергә туры килмәде-килүен, әмма Силуанов кагылган мәсьәләне ачыклап бетерергә кирәклеге көн кебек ачык иде. Миңнеханов бу юлы да сынауны кабул итте:

– Сер түгел, бездә әле каршылык тудыра торган бюрократик киртәләр шактый, – дип таныды ул. – Төрле кешеләр, төрле төшенчәләр бар. Әмма үзләренә җаваплылык алган һәм эш урыннары булдырган кешеләр хакимият тарафыннан яклау да тоярга тиешләр... Мин кече һәм урта бизнесны үстерү өчен каралган акчаларны Татарстанга җәлеп итеп, алар белән сезне тәэмин итәргә вәгъдә бирәм.

Миңнехановны «Матч-ТВ» телеканалының генераль продюсеры Тина Канделаки алыштыра. «Кем ул лидер?» – дигән сорау ташлый ул залга һәм... үзе турында сөйли башлый.

– Бүген халык танымаган даһилар юк! – ди Тина Канделаки. – Бары тик вакытында яңарыш кичерергә теләмәүчеләр генә бар. Алар, үзләренә җаваплылык алып, лидерлар булырга гына теләми, шулай ук – башкаларга үзләренең уникаль булуларын исбатларга да. Нәрсәсе белән уникаль булуларын, дәресрәге. Ә бит җирдә уникаль булмаган кеше юк ул. Сез минем белән килешәсезме? Үзләрен уникаль дип исәпләүчеләр, йөгез әле, кулларыгызны күтәрегез! Шәп! Искитке-е-е-еч!

Миңа аның чыгышы, озаграк тыңлаган саен, стендапны хәтерләтте: Канделаки алкышларны, авызына гына карап торган публика белән уйнап, шаярып, тыеп кабул итеп кенә торды. «Соры куртка кигән ир-ат, кайда сез хәзер: Инстаграмдамы, Фейсбуктамы, Твиттердамы? Вотсапта? Ярый, андагыларга миннән кайнар сәлам юллагыз!» Шаярулар арасында ничек лидер булырга икәнне дә өйрәтте. Кыскача гына итеп әйтсәк, шәхси үсеш һәм ыргылышның Тина Канделаки тәкъдим иткән ысулы мондыйрак: үзегез турындагы мәгълүматны бөтен җирдә дә яңартып чыгыгыз. Социаль челтәрләрне даими һәм системалы рәвештә алып барыгыз. «Контент белән идарә иткән кеше дөнья белән дә идарә итә бүген!» Фотосессия ясагыз («Спорт белән шөгыльләнегез! Сез үзегез шөгыльләнгән өлкәдәге дәрәҗәгә тәңгәл булырга тиешсез!»). Коммуникациягә зур игътибар бирегез (үз телегездә, әмма бүгенге медиабазарның кагыйдәләренә туры килә торган итеп). Сүз уңаеннан, уңышлы коммуникациянең бер төре буларак, Канделаки безгә бик тә билгеле шәхеснең аккаунтын күрсәтеп узды. Бер фотография һәм аның астындагы язу буенча аның шунда ук кемнеке булуы аңлашылды: «Доброе утро! Хәерле иртә!» Сез дә аңладыгыз бит, шулаймы?



ТАБИБЛАРНЫ ТИМЕР ЮЛДАН ЭЗЛӘГЕЗ

Ә аннары залны янә зарядка көтә иде. Миндә сораулар шулкадәр күп җыелды ки, аларны турыдан-туры «Синергия» Бизнес Мәктәбе ректоры Григорий Аветовка юнәлдердем. Әлеге мәктәп «Перезагрузка» оешмасында ТР Хөкүмәтенең уку-укыту партнерына әверелгән иде.

– Кайчакта миңа мондагы хәлләр, беләсезме, нәрсәне хәтерләтә...

– Кашпировскийнымы? – дип җанланып китә Аветов.

– Йә булмаса – сектаны. Каян килә болар барысы да?

– Безнең Россия укытучыларыннан! Хәтерлисезме: «Балалар, мине ишетсәгез, кулларыгызны күтәрегез! Әйдәгез әле, торып басыйк! Без яздык, без яздык, кулларны язылйк, арыдык...» «Олимпийский» белән «Татнефть-Арена» мәйданнарында гына бу секта буларак кабул ителә ала. Асылда, аудитория белән эшләүнең күптәннән билгеле ысулы, болай иткәндә, турыдан-туры кешенең уң як ярымшарына тәэсир ясала. Игътибарны җәлеп иткәннән соң, һәр 20 минут саен блоклар арасында тәнәфес ясарга кирәк, чөнки 20 минуттан артып китсә, игътибар инде югала, тарала башлый. Беркем дә тыңламый һәм ишетми. Гаять эре Nordic Business Forum, Европаның иң алдынгы эшмәкәрләр җәмгыятен туплап, үз чараларын нәкъ менә шушындый форматта уздыра. Андагы тәнәфесләр вакытында сикерүләр дә, хәтта биюләр дә урынлы санала! Югыйсә, аудитория белән ничек идарә итәр идең? Әлбәттә, Давоста узган Халыкара икътисадый форумда сез мондыйны күрмәссез. Әмма шунысы да күрсәткеч: анда бит бөтен кеше йоклый!

Нәкъ менә «Синергия» әле күптән түгел генә Мәскәүгә Тони Роббинсны алып килде. Ул чакта халыкара танылу алган мотивация тренеры белән миллиардерның чыгышы 20 меңнән артык халыкны җыйды. Күбесе билет өчен күз алдына китерергә дә куркыныч акчалар сарыф иткән – унар, йөзәр мең. Казанда үткән «Перезагрузка 2.0» аудитория өчен бушлай каралган иде. Ул шулай ук республиканың үзе өчен дә бушлай булдымы икән? Оешманың нинди колачны иңләвенә һәм спикерларның

дәрәҗәсенә, «йолдызлы» составына караганда, шактый кыйммәткә төшкәндер, дигән шик бар. Ә менә эффектына килгәндә, нәрсә көтәргә?

– Тыңлагыз әле, сез чынлап та бер көн эчендә нәрсәгәдер ирешеп була, дип исәплисезме? Эшмәкәрнең аң-фикер йөртү сәләтен яңартып корыр һәм үзен «грамоталы эшмәкәрлек компетенцияләре»нә өйрәтер өчен бу – бик аз вакыт лабаса, – дим Григорийга.

– Кайчакта хәтта ун минутлык аралашу да минем башымда парадигмаларны алыштырып куя ала, – ди ул миңа җавап итеп. – Эшмәкәрнең алдагы уңышын турыдан-туры форум белән бәйләп буламы? Без андый статистика алып бармыйбыз. Икенче яктан караганда, форум – стимул бирә, уятып җибәрә торган чара ул. Биредә атаклы мотивация бирүче спикерлар җыелган. Алар даими рәвештә тукып торалар: «Син булдырасың! Бар да эшлә генә!» Ә аннан аларны сәхнәдә ул кадәр үк билгеле булмаган спикерлар алмаштыра: болары инде файдалы булган бизнес-короллар турында сөйли. Мисал өчен, хәзер Герман Гаврилов дигән затның чыгышы көтелә. Ул – Roistar дигән компаниягә нигез салучы. Безгә клиентлар трафигын ничек итеп анализларга кирәклеге турында сөйләргә тиеш. Бу эшмәкәрләргә бизнесларында инде иртәгә үк кирәк булачак нәрсә. Мин үзем дә аның сөйләгәннәрен теркәп барырга җыенам. Йә булмаса – Инди Гогохия, ул эшмәкәрләрне үз Инстаграмнарын ничек алып барырга өйрәтәчәк. 45 минутлык лекцияләр – аудиториягә нинди дә булса нигез белемнәрне җиткерү өчен иң кулай формат.

– Сез хәзер (әйтергә кирәк, Хөкүмәт заказы буенча) меңләгән кешене эшмәкәрлек белән шөгыльләнергә мотивацияләргә тырышасыз. Ә бездә исә ул арада хастаханәләрдә табиблар җитеп бетми...

– Беләсезме, миңа калса, нәрсәгәдер ирешә алмаган табибларның барысы да эшмәкәрлек юлына кереп киткәндер, дип уйларга кирәкми – бу ике проблема бер-берсенә берничек тә бәйләнмәгән. Минемчә, табиблар да аз, эшмәкәрләр дә. Табиб була алмаучыларга килгәндә, алар бизнеста зур акчалар белән эш итәдер, дип исәпләмим. Бәлки, аларны дәүләт корпорацияләреннән эзләп карарга кирәктер. 1,5 миллион кеше, әйтик, Россия тимер юллары тармагында эшли! Мин югары сыйныфларда укыганда, безнең мәктәптә барысы да таможенник булырга хыяллана иде. Бәлки, табиб була алмаучыларны шуннан да эзләргә кирәктер...

ИНСАЙТНЫ ЭЛӘКТЕРЕГЕЗ!

Радислав Гандапас кулларын күтәрә дә, зал үрә торып баса. Әмма торып басарга дигән сигнал – бер мәртәбә кул чабып алу булмады. Бу дәрес – арзанлы трюкларга сатылмагыз. Бизнес-тренер шулай итеп зал белән уйный. Һәм, әйтергә кирәк, залга бу ошый. Монда нәкъ менә Гандапасны күрер өчен, аның хакына гына килүчеләр дә җитәрлек. Ул публиканы вакыт-вакыт сикереп торырга мәҗбүр итә – йә берәмләп, йә кулга-кул тотынышып. Һәр бирем – яңа дәрес. Тиеш нәрсәне тиешле вакытта эшлә, янәсе. Һәм – чын күңелдән, зур теләк белән, югары дәрәҗәдә! Башкалардан тизрәк! Үз-үзең белән ярышып! Кооперацияне файдалан. Болар барысы да – уңышка илтүче трамплиннар...

Чыгыштан соң аудиториянең бер өлеше фойега агыла, мөгаен, инсайтны үзе аша уздырып, ваемлар өчендер. Гандапас хезмәткәрләр өчен каралган махсус ишектән чыгып китә. Бик бәхетлеләр генә аны коридорның берсендә – матбугат конференциясендә очраталар. Гандапасны уратып алалар. «Сез максатыгызга ничек ирешәсез?» – дип сорыйлар аңардан. «Тагын бер кабат (камерага карап, блог өчен) кабатлагыз әле: мин бизнеста хатын-кызларның булуы яклы!» – дигән үтенеч яңгырый. «Мин бизнеста хатын-кызларның булуы яклы!» – дип шунда ук җавап та бирә Гандапас. Ул сүзгә бик һәвәс. Һәм рәхмәтле дә – «Татнефть-Арена» бит аңа, әнә, нинди меңләгән кешедән торган аудитория бүләк итте. Бәлки, әле аның үзенең дә инсайт мизгеледер.

– Кешене эшмәкәр итә ала торган нинди дә булса аерым бер сыйфат бармы? – дип соравымны бирәм мин дә. Инде кулуарларда.

– Иң әһәмиятле мәсьәләләр арасындагы вак-төяк уңышсызлыкларга да, уңышларга да (бу сыйфат, гадәттә, ялланып эшләүчеләргә хас) артык игътибар бирмәскә киңәш итәр идем. Презентация барып чыкмадымы? Клиент берни дә сатып алмадымы? Ярый, шулай булсын әлегә. Клиентны дистанциянең озынлыгы белән бәйле гомуми нәтиҗә кызыксындыра бит. Эшмәкәрләр – ул аерым бер каста. Тик мин шулай да моның тумыштан бирелә торган сыйфатлардан торуына ышанмыйм. «Мин сатучы түгел, мин бу эшне сөймим!» – ди, мәсәлән, кемдер. Аның тормышында казына башласак, балачакта урнашып калган ялгыш фикерләргә килеп чыгасың. Әйтик, әти-әниләре алып сату белән шөгыльләнүчеләрне тәнкыйтьли торган булган да, баланың аңына бу эш начар, дигән инану кереп калган. Кемдер әйтә: «Мин оратор түгел!» Димәк, кайчандыр аның чыгыш ясаганда уңышсызлыкка очраганы булган. Иманым камил: һәркем эшмәкәр булып китә ала. Әмма билгеле бер шартларны үтәгән очракта гына. Мәсәлән, бизнесның ничек эшләве хакында аз гына булса да белү сорала; сыгылмалылык таләп ителә, чөнки бизнеста бар да даими рәвештә үзгәреп тора. Үз стратегияңне булдырырга әзер булу – мөһим шарт.

Без постмодернизм заманында яшибез, ә ул идеяләр кризисы белән характерлана. Мегаполисларда барлык нишалар да күптәннән инде яулап алынган. Мондый ситуациядә ничек итеп үз эшеңне табарга да башлап җибәрергә? Ниша эчендәге эзләнүгә игътибар юнәлтергә киңәш итәм, диде Радислав Гандапас. Һәм инде башкалардан тизрәк тә, сыйфатлырак та итеп башкару – уңышка илтүче беренчел фактор. «Тесла»ны искә ала ул, алар бит үз машиналарын нибары 36 хезмәткәр көче белән генә эшли. Бу эшне коруның һәм бизнес-процессларны хәрәкәт иттерүнең бөтенләй башка дәрәҗәсе. Сәнәгатьне арзанрак итеп кору һәм продуктларга көндәшләреңдә булмаган сыйфатлар бирә алу юлларын эзләп табу зарур. Үз кулланучыгызны һәм ихтыяҗ өлкәсен булдырыгыз. Барбершопларга – махсус ир-атлар өчен генә ачылган чәчтарашханәләргә нигез салучыларны гына искә төшерегез. Яисә спорт продуктлары сатуны гына алыйк. Әйтегез әле, без элек L-карнитин эчә идекме? Юк лабаса! Һәм, иң мөһиме, эшне житез йөртегез, көтеп утыру – бизнес кагыйдәсе түгел. Асылда, без беркайчан да бернәрсәгә дә әзер булмыйбыз. Бу мөмкин түгел! Без беркайчан да өйләнергә әзер була алмыйбыз, чөнки теләсә кайсы ир-егет үлгәнчегә чаклы малай-шалай булып кала бирә. Шулай да, өйләнмичә торып, ул үзендәге ир булу, әти булу потенциалын ача алмас иде. Эш эшләмичә, эшләп карамыйча, эшмәкәр булып булмый – бу да шул сериядән. Бизнесыгызны башлап җибәрегез дә процесста тәҗрибә туплагыз. Бүген бу өлкәгә кереп китү өчен әллә ни авыр шартлар таләп ителми.

Дөрес, монда бер «әмма» бар. Бизнеста стресс чигендә беренче адымнар ясау тыела. Гандапас шулай кисәтә. Кеше стресс вакытында ашыгычлык белән дөрес булмаган карарлар кабул итә чөнки. Тәҗрибәне минималь ресурсларда туплагыз, ул ресурсларны һәрчак ни белән дә булса туендырып тору зарур. Энергия өчен вакыт сарыф итәргә онытмагыз. Бизнесның колачын эш барышында билгеләгез, акселераторлар белән инкубаторлар кулланып, әлбәттә. Бүген бизнес культурасы, аның механизмнары стресстан сакланып калыр өчен бик күп мөмкинлекләр тәкъдим итә. Кыскасы, сезнең алда – киң тәрәзә, аның артында бик күп төрле маназарлар ачыла. Ә дөнья сезнең беренче адым ясаганыгызны, игътибар юнәлткәнегезне генә көтә.

ТАШЛАМАЛАР, ТАШЛАМАЛАР, ҺӘМ ТАГЫН БЕР КАТ – ТАШЛАМАЛАР...

Маркетинг өлкәсендә гуру саналган, полиглотлыгы белән билгеле булган Гарретт Джонсон публиканы ике телдә сәламли. «Хәлләрегез ничек?» – дип сорый ул рус, ә аннары татар телендә. Аудитория шунда ук сокланудан дәррәү куба. Нәкъ менә соклану уяту, аудиторияне... оргазм хәленә китереп җиткерү – аның чыгышының төп темасы да шул.

«Синергия» сайтында Джонстонның бер фикере бар. Анда сүз менә нәрсә турында бара: күпчелек Россия компанияләре, көн саен дөрес булмаган клиентларга дөрес булмаган рәвештә дөрес булмаган товарлар, хезмәтләр сатып, күрсәтеп, аларны дөрес булмаган кешеләрнең тәкъдименә ышанып сайлап, бик күп акчадан колак кага. «Бер караганда, бу чып-чын фаҗига, – дип нәтиҗә ясый эксперт, – икенче яктан караганда, Россия бизнесын үстерүнең әле берәү дә кереп һәм сөреп карамаган кыр-басуы, рәхәтләнергә була». Бер генә түгел, әллә никадәр компанияне тәэмин иткән һәм лидерлар беренчелегенә чыгарган белгеч Казанга җирле эшмәкәрләрне бизнесны дөрес итеп төзергә өйрәтер өчен чакырылган.

– Хәзер бөтен планета яңарыш кичерә, – ди ул. – Дөньякүләм революция бара – клиентка хезмәтне оргазм кичерә-кичерә күрсәтү буенча революция! Кешеләргә элек бары тик миллионерларның гына куллану мөмкинлеге булган продуктлар белән хезмәтләрне сатып бирү. Дөнья буйлап төп хакимлек нәрсәне дә булса җитештерүчеләрдән һәм сатучылардан шул нәрсәне дә булса сатып алучыларга күчеп бара. Бу нишләп шулай, диярсез. Чөнки тәкъдимнәр драматик рәвештә арта – ел эчендә меңләгән процентка. Ә менә ихтыяҗ исә бик акрын кыймылдый – елга бары тик 2–3 процентны гына тәшкил итә. Шулай булгач, бизнесның уңышы – 90, ә бәлки хәтта 100% сатып алучының соклануы, әсир калуына бәйле хәзер. Безне әле моннан да әкәмәтрәк бер «шартлау» көтә – озакламый һәр продуктны һәм хезмәтне аерым бер заказчы өчен махсус әзерли башлаячакбыз.

Джонстон аудиториягә «клиент оргазм кичерерлек булсын өчен нишләргә кирәк» икәнлеген күрсәтүче мисалларны олавы-олавы белән ташлый. Шундый идеяләрнең берсе – немец компаниясе – Альди дискаунтерының затлылык, зиннәтлелекне күзгә күренердәй итеп демократик кысаларга чыгаруы. Ягъни Альди – ул хәзер арзанлы бәяләр генә түгел, ә шул арзанлы бәяләргә тәкъдим ителгән суперсыйфатлы товарлар да, дигән сүз. Алар кыйммәтле әйберләрнең арзанлы аналогын эшли. Мисал өчен, балаларга да ашарга ярый торган пицца. Ул глютенсыз һәм кремсыз, димәк организмга зарарсыз булып чыга. Сату өлкәсендә рекорд куя бу оешма. Аларның клиентлары – фәкыйрь кешеләр түгел, ә тормыштан даими рәвештә оргазм алып яшәргә омтылучы акыллы затлар.

– Ә Россиядәге дискаунт? – дип сорый ул залдагылардан, шунда ук соравына үзе үк җавап та бирә. – Ташламалар, ташламалар, ташламалар һәм берниндиоргазмсыз, җитмәсә...

Аудитория алкышларга күмелә. Джонстон нәкъ өстенә басты. Әлеге ләззәтсез эш алып бару рәвеше, аңлашыла инде, барысының да җелегенә үткән – хәтта товарлар белән хезмәтләрне җитештерүчеләрнең үзләренең дә. Әмма, кызганыч, Россиядә бу бөҗрадан ничек чыгып ычкынырга икәнен әлегә берәү дә анык кына белми.

– Продуктларны ваклап сату буенча махсуслашкан теләсә нинди кибеткә керегез, – дип тәкъдим итә Джонстон. Һәм мин уемда туган ритейлым филиалына юнәләм. – Анда барысы да продуктлар буенча урнаштырылган, клиентны күздә тотып түгел. Икмәк, ит, сөт... Дөрес түгел! Клиент тирәли корырга кирәк продуктлар әйләнәсен. Монда кергәч, ул үзенә иртәнге аш та, төшке аш та, кичке аш та алсын, моннан тыш, дуслары белән очрашасы ялларын да кирәкярак белән тәэмин итсен. Бу очракта син товар түгел, ә клиент буенча тәҗрибә сатасың – дөрес сырны дөрес шәраб белән янәшә куеп, шунда ук дөрес итне дә өстәп... Бу комбинацияне җиренә җиткереп башкарсаң, син клиентыңа нәкъ менә оргазм бүләк итүче буласың да инде. Сервисның югары дәрәҗәдә булуы хакына кешеләр 10–15%ка кадәр артыграк түләргә әзерләр. Сез шул бер үк товарны сатсагыз да. Күз алдына гына китерегез: әгәр сезнең өлкәгездәге маржа нибары 7% икән, ә сез аңа тагын 15 не өстисез ди. Россиядә 1985 елдан соң туган яшьләр исә клиентка тәкъдим ителгән оргазм өчен урта һәм өлкән буыннан да күбрәк акча түләргә әзерләр!

Джонстонның тагын бер тезисы алкышларга сәбәпче булды: «XXI гасыр банкының бурычы – акча түләмәүчеләрне үрчетеп яту түгел, ә кешеләрне баерак итү». Монысы инде банк хезмәте өлкәсендәге оргазмга кагыла. Монда нәрсә әйтеп була, йә? Тагын нәкъ өстенә басты бит. Гомумән, аның лекциясе конкрет саннар һәм нәтиҗәләр белән шыплап тулган иде, кайсыберләре шул дәрәҗәдә эмоциональ төгәллеккә ия булып чыкты, әйтерсең, бу ирланд кешесе безнең Россиядә туып-үскән. Ә менә уңышлы бизнес алып баруның кайсыдыр мисаллары барыбер дә Россия менталитеты өчен яраксыз булып тоелды миңа. Менә берсе. Заправкага туктагач, без ничек инде башта бензин салып, аннан соң янәшәдә урнашкан шәп кибеткә кереп, аны урап, шуннан соң гына түли алабыз?! Менә заправка хуҗаларының да башына сыймый. Әмма ул арада Көнбатыштагы коллегалар нәкъ менә үз керемнәренең 85%ын шул схема буенча ала.

Бизнес идеядән башлана. Ни өчен яшисең син? Кулланучыңа нинди оргазм тәкъдим итә аласың? Карават сатасыңмы син, әллә тәмле йокымы? Кер юуу машинасымы? Чиста итеп юылган киемнеме? Бары тик клиентка булган ориентация гына күбрәк керем белән тәэмин итә ала, продукт үзе түгел. Джонстон лекциясе, асылда, шушы төп фикердән тора. Ә бит бу гап-гади хакыйкать.

«Бәлки, бу гади булып тоеладыр, ә менә күпләр өчен – карурман...» – дип, үз фикере белән уртаклаша бер коллегам. Һәм күптән түгел генә интерьер дизайнерлары белән булган очрашуы хакында сөйли. Тәҗрибәле белгечләр җитди рәвештә бер мәсьәлә буенча фикер алышты, ди ул: имеш, хәзер клиентлар үзгәрде, алар даһиларга яхшы дизайн ясарга комачаулый, үз идеяләре белән тыкшына, гәрчә бу өлкәдә бернәрсә белмәсә дә. Ат дагалаганда, бака ботын кыстырмый, дигән мәкаль тарафдарлары булып чыга инде бу профилар. Һәм, димәк, бизнес-импотентлар да. Чөнки клиентларының оргазмга лаек булмавын алар үзара инде хәл итеп куйды. Аларны кичекмәстән Джонстонга җибәрергә кирәк – өйрәтсен! Ләкин менә зарядка ясарга теләүләре генә икеле.

Фото: goodfon.ru

Автор:
Сафа Гәрәев

ДИНГӘ БАРУ ЮЛЫ

Ачык, сөйкемле йөзле, заманча күзлек кигән. Чәчләрен яшереп, мөселманча бәйләнгән ак яулык аның яшьлеген һәм матурлыгын тагын да күркәмләндерә. Фәридәгә 18 – өмет һәм бәхет көтү яше. Ышануы кыен: бәхет турындагы хыялларын ул аздан гына югалтмый калды. Үземе?

Беренче карашка, аның тарихы бик шәхси. Ихлас ышанып, Фәридә ислам кануннары кушканча (башка диннәрдәге кебек үк) яшәргә тырыша. Аллаһыны мактап, йолаларны үтәп, яхшылык китереп, кешеләргә усаллык кылмый... Һәм ни өчен әйләнә-тирәдә барысы да шундый миһербанлы түгеллеген, ни өчен яхшылыкка яманлык белән җавап бирүләрен аңламый. Ни өчен иң якын дус кызлары да аның карашларын уртаклашмый, аңламый, ят итә һәм җаваплары кыен сораулар бирә: «Ә Аллаһының барлыгын син каян беләсең?», «Нигә син һәрвакыт яулыктан йөрисең, ул кемгә кирәк?», «Усаллар булгач, ник аларга Аллаһы Тәгалә җәза бирми?»

Әлеге сораулар Фәридәгә тынгылык бирми, ул аларга җавап таба алмый интегә. Ышанырга яисә ышанмаска – һәркемнең үз ихтыяры, монда тирән белемле булу мәҗбүри түгел дә кебек. Ләкин син, мөгаен, иртәме-соңмы үзеңнең рухи эзләнүләреңнең очына чыгарга телисеңдер, ә бу бик җиңел түгел. Яшь кыз дөньяви дәүләттә үскән һәм тәрбияләнгән, дини фәлсәфәнең бөтен нечкәлекләрен начар белә. Ә табигать, кызганыч, бушлыкны яратмый...

ИЗГЕ БУЛМАГАН ГАДИЛЕК

Ул, Фәридәнең үзе әйтүенчә, кызның «исламда үз урынын табарга тырышкан» вакытында пәйда була. Сөйкемле, ачык, аралашучан. Аның белән сөйләшү бик җиңел һәм гади – әллә кайчан белгән һәм ышанган бер иптәшең белән аралашкан кебек. Шундый ук дини, беренче тәэсир – чын мөселман кешесе. Фәридә ни өчен шунда ук икеләнүләрен аның белән уртаклашуын, җавап таба алмаган сорауларның барысын да диярлек аңа юллавын үзе дә аңламый. Һәм гаҗәпкә кала – һәрхәлдә, аңа шулай тоела.

– Ул минем бөтен сорауларыма бик гади һәм аңлаешлы итеп җавап бирде, – дип сөйли кыз соңрак. – Һәм җаваплары ышандырырлык, үтемле иде.

Шуннан соң әлеге иптәшнең Фәридә каршында абсолют диярлек ышаныч казануын сөйләп торырга кирәкме икән. Ул кырыс, каршы әйтүне кабул итми, хаталарны кичерми торган дингә өндәүчегә бөтенләй охшамаган. Барыннан да бигрәк, холкындагы йомшак сыйфатларны кабул итүче һәм сиңа

булышырга әзер дус. Һәм алга таба ничек яшәргә киңәш бирергә әзер кеше дә.

«Иптәшенең» чын исламнан без Марска ерак булган кебек бик ерак Хизб ут-Тәһрир оешмасыннан булуын, әлеге оешма әгъзаларының яхшылык кылу белән шөгыльләнмәвен Фәридә соңрак аңлый.

МИШЕНЬ: ДИНГӘ ЫШАНУЧЫЛАРНЫҢ ХИСЛӘРЕ

Фәриданең Хизб ут-Тәһрир оешмасына ничек эләгүе турындагы тарих, ни кызганыч, уникаль түгел. Ул яңа танышы йогынтысына эләккән вакытларда Ләйсән исемле тагын бер кызны дини белемнәре белән шундый ук ышаныч казана белүче үзенә карата. Һәм шундый ук юл белән.

– Алар миңа бер күрүгә ошадылар, – дип сөйли Ләйсән. – Мин бездәге җәмгыятьнең ничектер дөрес оештырылмаганлыгын тоя идем, әмма дөньяны яхшы якка үзгәртү өчен нәрсә эшләргә кирәклеген аңламадым. Ә алар гади итеп барысына да төшендерделәр. Һәрхәлдә, миңа шулай тоелды…

Менә Татарстаннан тагын бер яшь кеше, Закиров, шулай ук бик дини егет. Яллаучы моны, әлбәттә, белә һәм егетне үзенең дини белемнәре белән кызыксындыра, үзенә тарта…

Төгәл закончалык бар: еш кына актив яшьләр мондый дингә өндәүчеләрнең мишененә әверелә. Күңелләрен ихластан ислам өчен ачкан, әмма дини тәгълимат нечкәлекләренә төшенеп бетмәгән кешеләр. Хизб ут-Тәһрир белгечләре туры мәгънәсендә дингә ышанучыларның хисләрендә уйный. Аларның тирән дини белеме булмау, шул ук вакытта яшьләргә хас дөньяны үзгәртү теләге булудан файдаланып, яхшы өйрәтелгән мондый «белгечләр» катлаулы фәлсәфи сорауларга бик гади итеп (һәм шуңа күрә аңлаешлы) җаваплар бирә белә. Мөһим момент: алар аралашуның беренче сеанслары вакытында үзләрен кем җибәргәнен, кайсы оешмадан килгәннәрен беркайчан да әйтеп салмый. Җәмгыятьтәге проблемаларны ислам тормыш рәвеше аша чишәргә тырышкан, ышанучан кешеләрне иң баштан ук алдыйлар булып чыга…

Һәм Хизб ут-Тәһрир кармагына төрле вакытларда капканнарның барысы да әйтә торган тагын бер мөһим нюанс бар. Әлеге оешма тарафдарлары белән булган беренче очрашулар бер фикерне куәтли: бу кешеләр – иң миһербанлылар, иң яхшылар. Үз корбаннарының абсолют ышанычын яулаганнан соң, алар планнарын алга таба үтәргә керешә. Һәм инде бөтенләй башка ысуллар белән…

ТЫҢЛАУЧАН БУЛ, КОРБАН БУЛ…

Үзләре дә сизмәстән әлеге оешмага кушылып киткән кешеләрне эшкәртүнең алдагы этабы – мәхәллә халкының сайлап алынганлыгы турындагы фикерне сеңдерү: «Бары тик без генә дөрес юлда», «Бары тик без генә дөрес дингә ышанабыз», «Бары тик безнең төркем генә Аллаһы Тәгалә канаты астында», «Безнең белән бергә булган кеше генә – коткарылган»…

Чын-чынлап дингә бирелгән кеше, шундый психологик һөҗүмгә дучар ителгәннән соң, әкренләп сөйләүченең сүзләрен бердәнбер дөрес, шиксез фикер буларак кабул итә башлый, ул инде теләсә нинди күрсәтмәне үтәрлек булып өлгереп җитә, гәрчә ниндидер авырлыклар очрыйсы күзгә күренеп торса да. Һәртөрле шик белдерү – лидерның сүзенә, киңәшенә яисә турыдан-туры боерыгына карата булсынмы ул – тугрылыкның, дингә ышануның йомшаклыгы, хәтта ки бөтенләй читкә тайпылу буларак аңлатыла башлый.

– Ниндидер мизгелдә үзеңне каты кысаларда тоя башлыйсың, – дип сөйли психологик эшкәртүнең бөтен нечкәлекләрен үзендә тойган Евгений Кулагин (Башкортостан). – Ак та юк, кара да юк, бары тик көрәш кенә. Бу кысалардан син инде чыга алмыйсың…

– Син әмиргә берсүзсез буйсынырга тиешсең. Һәрхәлдә, ул нинди генә әмер бирсә дә, – дип, аның сүзләрен куәтли Хизб ут-Тәһрир корбаннарының берсе Алексей Хәмәдиев (Башкортостан).

Шундый психологик басым шартларында кеше үз гамәлләре өчен җаваплы булудан туктый, аларның нинди нәтиҗәләргә китерәчәген аңламый, бәяләми башлый. Кеше әлеге дингә өндәүчеләрнең сүзләренә сукырларча ияреп, тулысынча агым юнәлешенә кушылып, колга, манипуляторларның оста кулларындагы инструментка әйләнә.

Менә хәзер инде үз гамәлләрен исламны чисталыгын саклау, чын ислам кыйммәтләрен яклау лозунглары астына яшергән оешманың ислам диненә нинди мөнәсәбәте барлыгы турында сөйләр вакыт та җиткәндер.

КЕМНЕҢ КЕМЛЕГЕ

Хизб ут-Тәһрир әл-Ислами «Ислам азатлык партиясе» 1953 елда Көнчыгыш Иерусалимда Такиуддин ан-Набхани тарафыннан оештырыла. Штаб-квартирасы Лондонда урнашкан. Әлеге партия гадел ислам яшәү рәвешен һәм ислам дәүләте – хәлифәтне торгызуны үзенең бурычы итеп куя. Ислам азатлык партиясе рәсми рәвештә террорчылык методларын кире кага: аның программасында бары тик Ислам дәүләтен төзергә чакыру гына яңгырый, һәм ул тыныч юл белән тормышка ашырыла ала. Шулай да дәүләт төзелгәннән соң, бөтен дөньяның хизб идеологиясен кабул итүе мәҗбүригә әйләнергә тиеш.

Монда инде мәҗбүриләүләрне инкарь итү юк – әлеге тезис бары

Фото: Ната Смирнова

тик яңа килгәннәр өчен генә. Хәрби хәрәкәтләр оештырылырга мөмкин, хәтта ки алар булмый кала алмый. Ә Хизб ут-Тәһрир администрациясе җитәкчесе Әл Касас, мәсәлән, үзенең фәтваларында тәгәл, ачык иттереп Сүрия территориясендә барган чуалышларда катнашу һәр мөселман өчен мәҗбүри, аның вазыйфасы дип белдерә. Ягъни Хизб ут-Тәһрир әгъзаларына сугышларда катнашу тиеш дигәнгә ишарәли. Партиядәшләре өчен генә түгел, башка барлык мөселманнар өчен дә. Асылда Якын Көнчыгышта Джабхат ән-Нусраны кадрлар белән тәэмин итү белән шөгыльләнеп, Хизб сиздерми генә террорчылыкка чакыру өчен җаваплылыктан кача.

Кайчандыр Хизб ут-Тәһрир кармагына эләккән Евгений Кулагин, Азат Хәсәнов шуны ук раслый: коралллы көрәш кирәк, җихат – ислам дәүләтенең аерылгысыз өлеше – бу турыда аларга гел әйтеп торганнар.

КАНӘГАТЬСЕЗЛЕК ЧӘЧСӘҢ, СУГЫШ УРЫРСЫҢ

Хизб ут-Тәһрир партиясе катгый үзәкләштерелгән структура, вертикаль идарә тәгәл оештырылган. Милли оешмалар гадәттә җирле ячейкаларны контрольдә тотучы 12 кешелек төркем җитәкчелегендә эшли. Хатын-кыз төркемнәре ирләрнекеннән аерым эш итә.

Махсус әдәбият укуны, өндәмә-чакыруларны, пресс-релизларны, видеороликларны тиражлау һәм тарату, оешмага яңа әгъзалар җәлеп итү кебек һәр көн башкарыла торган пропаганда эшчәнлегеннән тыш, партия төрле резонанслы акцияләр дә оештыра. Моның белән ул мөселманнар каршында дәүләт сәясәтен дискредитацияләргә, җәмгыятьтә канәгатьсезлек уятырга, мөселманнарны башка диндәге халыклар белән бәрелештерергә омтыла.

2013 елда Россия Сүриядәге вазгыятьне җайлау буенча илгә чит гаскәрләрне кертмәүне күз уңында тоткан үз планын тәкъдим итүгә, Хизб ут-Тәһрир безнең илдә үз эшчәнлеге чорында иң масштаблы протест акциясен оештырды. Сәбәпләре табылды: әйтик, Коръәннең Эльмира Кулиева башкарган тәрҗемәсенең экстремистик дип табылуын алар гомумән Коръәнне тыю, Ставрополье краендагы мәктәпләрдә хиҗап киюгә рөхсәт бирелмәүне – тулысынча яулык бәйләргә ирек бирмәү, Кавказда хокук яклаучы – Хизб ут-Тәһрир әгъзасы үлемен «үтерү» дип аңлаттылар. РФнең берничә шәһәрендә берүк вакытта «Россиядә Коръәнне тыялар», «Россиядә хиҗап кияргә рөхсәт юк», «Россиядә дингә өндәүчеләрне үтерәләр» дигән баннерлар күтәрделәр. Шул ук вакытта интернетта үз блогерлары аша диндәге кешеләрнең хокуклары бозылуга каршы акция оештырып җибәрделәр.

ХИЗБ УТ-ТӘҺРИР КАРМАГЫНДА

«Изге ниятле» дингә өндәүчеләр белән аралашканнан соң инде безгә таныш булган Фәридә дә Хизб ут-Тәһрир партия ячейкасына эләгә. «Җәмгыять иминлеге өчен» хезмәт итү күп көч һәм вакыт сорый. Әти-әниләргә игътибарлырак булыр, ярдәм итәр өчен вакыт бөтенләй калмый. Хәер, яңа «көрәштәшләре» белән аралашканнан соң пәйда булган фикерләр, тормышка карашлар да өлкәннәргә ошап бетми. Өйдә мөнәсәбәтләр кискенләшә, каршылыклар туа. Өйдәге мондый хәлләрнең Хизб ут-Тәһрир активистларына әйләнгәннәр өчен шактый типик булуын да әйтеп үтәргә кирәк.

– Коръәндә җәннәт – әниләрнең аяк астында диелгән. Без нигәдер әлеге хәдисне онытып җибәрәбез. Әти-әниләрем белән мөнәсәбәтләр кискенләште, – дияр Фәридә соңрак.

Ә Арслан Сәлимҗанов үзенең хата ясаганлыгын бары тик тикшерү изоляторына эләккәч кенә аңлый. Ул шунысын таный: оешмага эләккәч, ул иң кадерле нәрсәләрен җуя. Гаиләдә ызгышлар башлана, аерылышуы да ашык-пошык була...

– Дәү әтием дә: «Син ялгышасың, бу – ислам түгел», – диде. Ләкин мин ишетмәдем, инде башкага әйләнгән идем.

Кызганыч, Хизб ут-Тәһриргә эләккән күпләр, бары тик тоткарлаулар һәм җәза бирүләр башлагач кына, аңнарына килә, киләчәк турында уйлый башлый. Ә бит Россия Федерациясе Җинаять кодексының 205 нче маддәсендә тыелган оешма эшендә катнашкан өчен шактый җитди срокларга иректән мәхрүм итү каралган! Моның нәтиҗәләрен фаҗига дими мөмкин түгел. Яшь, эшлекле ирләр гомерләренең иң яхшы елларын тимерчыбык артында үткәрә, балалар – атасыз, гаиләләр таянычсыз кала.

БИТЛЕК АРТЫНДА КЕМ?

Хизб ут-Тәһрир интернетта видеороликлар урнаштырырга ярата, аларда – янәсе дәүләт тарафыннан кыерсытылган мөселманнар. Ә чынлыкта исә әлеге кешеләрнең фаҗигале язмышына нәкъ менә Хизб ут-Тәһрир партиясе, тагын да тәгәлрәк әйткәндә, ислам битлеге астында яшеренгән затлар гаепле.

Хәтта мөселман дөньясының үзендә дә Хизб ут-Тәһрир партиясе ят структура, нindидер «үз эчендәге әйбер» булып тоела. Аның әгъзалары бары тик партиядәшләре арасында гына үзләрен уңайлы һәм табигый хис итә. Әлеге мохиттән тыш, алар тынычсызлана, үзләрен дошманнар арасына эләккәндәй тоя. Шул ук вакытта алар башка мөселманнарны гөнаһлылар дип саный, чөнки тегеләре төркем тарафыннан уйлап табылган методларны кабул итми. Табигый ки, Хизб ут-Тәһрир традицион мөселман җәмгыятьләре һәм имамнары белән мөнәсәбәтләр урнаштыра алмый. Дини белеме, тотрыклы фикер сөреше, дөньяга карашы өлгереп җиткәннәр, кагыйдә буларак, бу кармакка эләкми һәм провокацияләргә бирешми. Мөселманнарның күпчелегенең хизбуттәһрирлеләр турындагы фикере бер. Бу коткы таратырга, фетнә уятырга яратучы затлар үзләрен табигый тота алмый.

Иртәме-соңмы Хизб ут-Тәһрир тарафдарлары вазгыятькә аек акыл белән карый башлый. Югарыдагыларга юлланып, җавапсыз калган күп кенә сораулар да тынгы бирми аларга. Чөнки партия тәгълиматы каршылыклар һәм мантыйкый туры килмәүләр белән тулы, ә практика, сәяси конъюнктурага ярарга тырышып, еш кына эзлексезлек юлына баса. Күп кешенең түземе югала һәм аларга оешмадан китәргә кирәк дигән уйлар керә башлый, өстәвенә, анда эшләүнең ахыры шактый зур төрмә срогы белән тәмамланырга мөмкин. Чөнки Россия Федерациясендә, башка, беренче чиратта, мөселман илләрендә Хизб ут-Тәһрир

Вадим Козлов, тарих фәннәре кандидаты. «Педагогика, психология һәм социаль проблемалар институты» ФДБФУ директоры:

– Иман мәсьәләләре һәрвакыт катлаулы һәм кешенең шәхси омтылышлары белән бәйләнгән. Әмма шул ук вакытта психологик, социаль һәм мәдәни факторлар дини индоктринация процессына җитди йогынты ясый. «Җаннарны эзәрлекләүчеләр», дип әйтик, төрле яшьтәге, белем, байлык дәрәҗәсендәгеләрне, һәм шулай ук конкрет шәхси проблемасы булганнарны үз оешмаларына тартуга ярдәм итә торган технологияләр белән оста эш итә. Нәкъ менә оешмалар, чөнки дини яисә башка фасад артында төгәл формалаштырылган һәм көйле механизмдай эшли торган структура яшеренә. Псевдо христиан, псевдо мөселман яисә башка төрле берәр формаль антураж булсынмы ул – чынлыкта болар артында һәрвакыт конкрет интеллектуаль һәм оештырылган фундамент яшеренә. Моңа охшаш структураларны төзегәндәге, аларның эшчәнлегендәге максатлар бер-берсеннән аерылырга, әйтик, бары тик коммерцияле яисә, Хизб ут-Тәһрир әл-Ислами очрагындагы кебек, сәяси сәбәпләрне генә күз уңында тотарга мөмкин. Соңгысында аның җитәкчеләре конкрет төбәктә яисә илдә төгәл вакыт аралыгында вазгыятьне тотрыксызландыру, какшату кебек максатны куя. Ләкин иң мөһиме – ялган юл белән игелекле эшләргә дип оешмага җәлеп ителгән кешеләр, чынлыкта барысын да белеп эшләгән җитәкчеләр өчен, еш кына финанс һәм сәяси яклары саналган төгәл максатлар өчен чыгым материаллары булып тора. Сындырылган яңа язмышлар, өзелгән туганлык һәм кешелек мөнәсәбәтләре кабатланмасын өчен, мондый псевдо дини оешмаларның чын асылын төрле мәгълүмати форматларны кулланып, ачык, системалы рәвештә күрсәтергә кирәк.

Алмаз Хәсәнов, 2005–2006 елларда Татарстанда һәм Чувашиядә Хизб ут-Тәһрир филиалының элеккеге җитәкчесе:

– Бездә тыелган Хизб ут-Тәһрир партиясенә җәлеп итү проблемасы ил күләмендә куркыныч янарлык массакүләм характерда түгел. Төркем әгъзаларының үзләренә җәлеп итүнең яхшы алымнарына ия булуларын яшермим, ләкин Пушкин әйткәнчә, «Ах, обмануть меня не трудно!.. Я сам обманываться рад!» Төп проблема – теләсә кайсы деструктив культ йогынтысына эләгергә мөмкин булганнарның санында. Күпләр ислам үзе деструктив, диләр... Проблема исламда түгел, ә аңарга кушылучыларда. Әгәр җәмгыять үзе мораль һәм әхлакый яктан авыру икән, исламга килүчеләр дә үзләре белән бу авыруны ияртәләр. Исламны бит безнең кичәге укучыларыбыз, студентлар һәм кайчандыр урам малайлары булганнар кабул итә. Барлык культларның да проблемасы – җәмгыятьтә тулыканлы шәхесне тәрбияләүнең йомшак булуында яисә аның бөтенләй булмавында. Мәсәлән, күкрәк баласын әнисе яратып бетермәгән – аның тулысынча әнисенә бәйле вакытында. Үскәч, бала «әнисен» сектада эзләячәк. Яратылып бетмәгән балалар проценты бик зур. Әти-әниләр киләчәктә балаларының деструктив культ белән проблемалары булмаслык итеп ничек тәрбияләргә кирәклеген белми. Менә моны мин чыннан да милли иминлеккә янаучы фактор дип саныйм.

террорчылык оешмасы дип танылган, һәм аның эшчәнлеге 2003 елда ук тыелган.

Кызганыч, сайланган сукмакның дин йортына китермәвен аңлау кайберәүләргә бик соң килә. Югыйсә дингә ихлас ышанган, әмма бик тиз йогынтыга бирелүчеләргә моны аңлау өчен бары тик Коръәнне игътибар белән укып чыгу да җитәр иде. Хәер, «дин өчен көрәшүчеләр», үз тарафдарларын махсус рәвештә чын ислам нигезләрен ныклап өйрәнүләреннән саклаганга охшаган.

– Мин төрмәдә генә беренче мәртәбә Коръәнне укып чыктым, – ди Айдар Гарифҗанов (Башкортостан). – Анда психологик эшкәртү бик көчле куелган. Саклыйлар...

– Мин хәдисләрне һәм аятьләрне, Коръәннең тәрҗемәсен укыдым һәм шуны аңладым: без эшләгән эшләр дөрес түгел, – дип, аның фикеренә кушыла Алексей Хәмәдиев та (Башкортостан). – Бары тик шундый «ломкалардан» соң гына, моның секта икәнлеген аңлыйсың...

КИРЕ КАЙТУ КЫЕНЛЫКЛАРЫ

Вербовканың актив методлары, мөселманнарны үзләрендә калдыруга юнәлдерелгән психологик манипуляцияләр, сайлау ирегеннән мәхрүм итү, ә алга таба кешедән тулысынча кол ясау – болар барысы да ХТ куллана торган тоталитар деструктив культ методлары. Ә тоталитар культтан, билгеле булганча, мөстәкыйль генә котылу бик җиңел түгел.

Беренчедән, кешегә көчләп тагылган курку хисе комачаулый: төркемнән чыксаң – хыянәтче, кыйбласын югалткан буласың, Кыямәт көнендә Ходай кичерүеннән, ярдәменнән мәхрүм ителәсең. Кайберәүләр төрмәләрдә мөселманнарга мөнәсәбәтләрнең негатив булуыннан һәм җәзалаулар турындагы сөйләүләрне ишетеп куркалар. Икенчедән, партия активистлары бөтен көчләрен оешма максатларына ирешүгә биргән арада, иҗтимагый, туганлык, дуслык элемтәләре өзелә. Алга таба ничек яшәргә?

Фәридә һәм Ләйсән – оешма белән арасын өзәргә үзендә көч тапканнар исәбеннән. Моңа нәрсәләр бәрабәренә ирешелгәнен алар үзләре генә белә.

– Мин оешмадан китәргә уйлауга, бөтен «дусларымның» миңа карата булган игелекле мөнәсәбәте шунда ук юкка чыкты. Аннан курку, стресс, депрессия килде. Әмма мин боларның барысын да җиңеп чыга алдым, – ди Ләйсән. – Миңа хәзер җиңел.

Ләйсән һәм Фәридә кебек үзләренә тыштан көчләп тагылган карашлардан арынган кешеләр күбрәк була бара. Хизб ут-Тәһрир бик кызу темплар белән тарафдарларын югалта һәм моны яшерергә тырыша. Ә сәламәт социумда үкенгәннәргә һәм үз ирке белән оешмадан чыкканнарга каршы килмиләр. Казанда хәтта төрле радикаль төркемнәр һәм деструктив культларны ташлап чыккан кешеләр өчен социаль-психологик тернәкләндерү дә оештырылды.

– Без белгечләрне берләштергән «Диалог» консультация үзәген ачтык. Уңай нәтиҗәләр бар, безгә рәхмәтләләр шактый, – дип сөйли Фәридә. – Мин хәзер кешеләргә булышам... Моны Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен эшлим. Бу өммәтебезнең савыгуы һәм бердәмлеге өчен кирәк.

Фәриданең һәм аның кебек Хизб ут-Тәһрир кочагыннан ычкына алганнарның бүген Аллаһының ихтыярын үтәр өчен бирелгән бәхетле мөмкинлекләре бар. Бәйләнчекләнеп, яңа адептлар җәлеп итү, ислам хакимиятенең булмавына зарлану өчен түгел, бәлки нормаль тормыш белән яшәр өчен, якыннарына шатлык китерер өчен, мәчеткә йөреп, догалар кылыр һәм Коръән укыр өчен тудырылган ул мөмкинлекләр.

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Реклама 16+

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

WWW.PROTATARSTAN.RU



Автор:
Ксения Сёмина

ИМАН ЯРДӘМЕНДӘ ТЕРЕЛҮ

«12 адым» программасының төп тезисларыннан берсе – кеше гомере белән идарә итүче илаһи көчне тану. «Ярдәм» Татарстан хәйрия фонды каршындагы тернәкләндерү үзәгендә бәйлелеккә эләккән кешеләрне рухи һәм физик яктан терелтү юлында ярдәм итү өчен барысын да эшлиләр.

Иркен бүлмәнең тәрәзәләре ачык, җил тәрәзә пәрдәләре белән уйный, диварларга эленгән кәгазьләрне тузгыта. Шул мотивацион девизлы язуларның берсенә «Миннән куәтлерәк көч бар, һәм ул миңа яхшылык тели» диелгән. Стена буенча тезелгән диваннарда берничә хатын-кыз һәм ир-ат утыра. Алар игътибар белән Рафис хәзрәтне тыңлый. Бу аларның яңадан оештырылган үзәккә күченгәннән соң беренче очрашуы.

– ...Ләкин Ибраһим корбан китерергә җыенгач, пычагының улы Исмәгыйльгә каршы күтәрелә алмавы ачыклана. Шулчак Аллаһы Тәгалә Ибраһимның сынауны үтүе, корбанга улы Исмәгыйльне түгел, ә бәрән чалырга кирәклеген җиткерә.

– Корбан бәйрәме көнне чалынган бәрән сөякләрен җиргә күмү мәҗбүриме? – дип сорый хатыннарның берсе.

– Юк, мәҗбүри түгел. Алар башка азык-төлек калдыклары кебек. Корбанның асылын аңлау зарур: сез корбан чаласыз һәм шуның белән Аллаһы Тәгаләгә якынаясыз. Барлык тиешле догаларны уку мөһим, ә итне, ислам кануннарында язылганча, якыннарыгызга һәм мохтаҗларга бүлеп бирергә кирәк. Кайбер диннәрдә корбан китерү йоласына бөтенләй башка караш. Мәсәлән, тавыкның башын борып ташлыйлар, үзен учакка аталар. Миңа калса, моның мәгънәсе юк... Сүз уңаеннан, сезнең монда булуыгыз да – корбан китерү ул. Терелү хакына корбан. Һәм мин монда утыруыгызның теге тавыкка тиң булуын теләмәс идем...

ЯХШЫНЫ ЯМАННАН АЕРУ

Хәзрәт сүзен тәмамлагач, аңа тагын берничә сорау бирәләр – ни өчен мөселманнарга дуңгыз итен ашарга ярамый, ваһһабчылар кайдан килеп чыккан һ.б. Хәзрәт тәфсилләп аңлата.

– Бу иң еш бирелә торган сораулар, аларны һәрвакыт сөйләшү башланганчы бирәләр, – ди Рафис хәзрәт, үзәктәге эше тәмамланганнан соң. – Миңа калса, үзара элемтә урнаштыра алдык кебек.

Алда әле үзәктә яшәүчеләр белән күпләгән очрашулар көтә – әгәр үгет-нәсыйхәт бирергә җыенасың икән, моны күзгә-күз карап эшләргә кирәк. Бу яктан караганда, Рафис хәзрәтнең тәҗрибәсе зур – рухани буларак ул инде бер-

Фото: Александр Ефремов

ничә ел Татарстан колонияләренә барып йөри.

– Алар белән очрашканда, мин наркотик һәм алкогольнең кеше язмышына нинди йогынты ясавын күрәм. Тәҗрибәм күрсәткәнчә, кеше төрмә субкультурасына тирәнрәк үтеп кергән саен, аңа акыл, яктылык һәм яхшылык орлыкларын чәчү катлаулырак була бара. Төрмәдән кешеләр бик сирәк кенә савыгып чыга, чөнки алар белән ярдәм кулы суза алырлык белгечләр эшләми, – ди хәзрәт. – Биредә исә белгечләр эшли, һәм тайм-аут алырга, уйланырга, үткән тормышыңа башка күзлектән карарга мөмкинлек тә бар. Дөрес карар кабул итәргә булыша торган шартлар тудырылган. Без тернәкләнүчеләрнең тиз арада ислам диненә күчүләренә омтылмыйбыз, үзәктә бит православ дине вәкилләре дә бар, алар янына православие рухание йөри. Атеистлар да очрый. Ләкин «12 адым» программасын үтүчеләрнең күпчелеге иманга, дингә килә. Минем бурыч – аларга бу юлларында булышу. Рухи аталарына әверелмәсәм дә, һичьюгында, яхшы белән яманны аерырга ярдәм итү, әңгәмәләр вакытында үз мисалымда кешенең «чиста» һәм гадел була алуын исбатлау.

Хуҗалык бурычларын хәл итү – тернәкләнү процессының бер өлеше.

БӨТЕН КЕШЕ – БЕР КЕШЕ ӨЧЕН

Үзәктә тернәкләнүчеләр күп вакытларын 12 адымлы программа буенча шөгыльләнә. Дөньякүләм статистикага күз салсак, беренче тапкыр тернәкләнү уза торган ун бәйле кешенең өчесе терелә, өчесе кире юлга китә һәм күпмедер вакыттан соң программага әйләнеп кайта, өчесе җиңелә һәм зыянлы матдәләр куллануын дәвам итә – бу еш кына фаҗига белән тәмамлана, бер кеше билгесез рәвештә юкка чыга. Бәйле булганнарның кайсы категориягә эләгәсе күп очракта алар белән эшләүче белгечләрдән тора. Тернәкләндерү белән шөгыльләнүче консультантларның күбесе – кайчандыр бәйле булып, хәзер озак еллар аек тормыш рәвеше алып баручы кешеләр. «Ярдәм» каршындагы үзәктә – шул ук принцип.

– Кайвакыт сикереп торасы һәм бөтен автобуска сиңа ничек кыен булуы турында кычкырасы килә. Бәйлелекнең барлык стадияләрен үтмәгән аек кеше боларны аңлый һәм, бигрәк тә, бу халәтне уртаклаша алмыйдыр, – ди Илшат. Ул – үзәкнең җитәкчесе, консультант, күпьеллык бәйлелек «стажына» ия, инде менә соңгы дүрт ел буе «чисталыгын» саклый торган кеше.

Бүгенге көндә 10 тернәкләнүче яшәгән үзәктә барысы да дисциплинага буйсынган. Көн тәртибе сәгатьләп регламентлана. Һәр иртә һичшиксез «исәнмесездән» башлана – һәркем аннан алдагы көнне үзендә нинди уңай үзгәрешләр булганын сөйли һәм башкаларга да матур көн тели. Аннан соң дәресләр, тренинглар, психолог белән аралашу башлана. Иртәнге, төшке, кичке аш – шулай ук язылып куелган. 12 адымлы программада «хезмәт итү» – үзләре артыннан үзләре җыештыру да каралган. Биредә «өй кагыйдәләре» принцибы эшли – төкерергә, сүгенергә, башкаларны рәнҗетергә ярамый. Бер-береңә булышырга, ярдәм итәргә кирәк.

– Шикләнү, ярсу, үзеңне җәлләү – болар барысы да авыру нәтиҗәләре. Бәйле кешегә социумга кушылып китү бик авыр бирелә. Әмма савыгу өчен болар кирәк, чөнки ул ялгызы гына булганда куллануга кире кайтачак һәм вакыт-вакыт үз-үзенә кул салу чигенә җитәчәк, – ди Илшат. – Социальләшү җиңел бирелми. Бездә, мәсәлән, мотивация тудыру ысулларының берсе – җиренә җиткереп эшләнмәгән нәрсәләрне уртак итеп, бергәләшеп эшләп бетерү. Кемдер идәнне яхшылып себермәгән икән – эш беткәннән соң бу тикшерелә, аннан соң бөтенесе бергә, болай да аз шәхси вакытларын сарыф итеп, идәнне себереп бетерәләр. Бу синнән тыш бүтән кешеләрнең дә булуын аңларга ярдәм итә…

Спорт, иҗат һәм аралашу – болар буш вакытыңны уздыруның иң популяр төрләре. Шөгыльләнүләр һәм хуҗалык эшләрендә мәшгуль булмаганда, алар әнә шулай «ял итә».

«ФУ» АНДЫЙ БУЛЫРГА...

Никитага – 22 яшь, ул монда иң яше. Февральдә, чираттагы кәеф-сафа корудан соң, аның артыннан ике «абзый» килә һәм машинага утыртып алып китә. Егет үзәктә генә чынлап торып аңга килә, һәм аңа тирә-юньдәгегә ияләшү өчен озак вакыт таләп ителә.

– Мин инде күптән яши башларга теләгән идем, – ди Никита. Җилкәсендә тату ясалган – «Per aspera ad astra» («Каршылыклар аша – йолдызларга»). Егет ачык һәм сөйкемле итеп елмая, әйтерсең лә, һәртөрле кирәкмәгән нәрсәләрне кулланган алты ел аның тормышында бөтенләй булмаган. – Без күптән түгел Яльчикка, Волжскидагы Аноним алкоголиклар төркеме юбилеена бардык. Бу минем тормышымда хәмерсез үткән беренче бәйрәм булды. Һәм миңа бик ошады!

Үзәк ярдәме белән егет эшкә урнашкан, әлегә төрле эшләр башкаручы булып. Аның махсус белеме юк чөнки. Ләкин ул киләчәктә бортпроводник һөнәрен үзләштерергә тели.

– Менә хәзер минем акчам барлыкка килде. Үземә телефон, киемсалым, нәрсә кирәк, шуны алдым. Әле акчам калды да. Һәм бу шулай ук – беренче мәртәбә, минем өчен бик гаҗәп нәрсә. Элек башкачарак иде: акча алам – туздырам. Һәм вәссәлам. Эш шуңа кадәр барып җитте ки, өйдән әйберләр алып чыгып китә башладым. Бирегә килеп эләккән өчен Аллаһы Тәгаләгә һәм әниемә рәхмәтле. Кулланган вакытта мин атналар буе бер киемнән йөри идем. Беркем белән сөйләшмичә. «Минем барысы да супер, бәйләнмәгез», – дия идем. Хәзер исә уйлыйм – «фу» андый булырга. Тартылу бар, әмма биредә бу халәтне җиңәргә өйрәтәләр. Адымнарыңны уйларга, дога кылырга. Әгәр бу үзәкне үзем ачсам, мин аны «Тормыш мәктәбе» дип атар идем. Читтән күзәткәндә бернәрсә дә бармый кебек тоела, «аекларга» моны аңлавы кыен. Асылда син чыннан да яңадан яши башлаган кебек буласың, – ди Никита.

Тернәкләнүчеләрнең үзәккә эләгү тарихы якынча бертөсле. Монда дәвалану программасы өчен акчаны туганнары түли, тиешле документларга кул куя, кешене үзәккә алып китәләр. Бу моментта ул, кагыйдә буларак, алкоголь яисә наркотиклар белән исергән халәттә була. Тернәкләндерүнең тулы курсы ярты елны тәшкил итә. Бу вакыт эчендә тернәкләнүче кешене тренировка фатирына урнаштыралар, ул анда мөстәкыйль яшәргә тырышып карый. Әмма бу вакыт кайчак озагракка сузылырга да мөмкин. Әмма беркайчан да азрак була алмый.

– Кайвакытта, бигрәк тә яшь егетләр белән була ул хәлләр, өч айлап вакыт узганнан соң, әти-әниләр килә, баласының күзләрендә наркотик чаткылары күренмәгәч, рәтләнде, дип, өйләренә алып кайтып китәләр. Бу очракларда «ычкыну» булмый кала алмый, – ди Илшат. – «12 адым» программасы һәр адымны язып баруны, үзеңдә һәм янәшәңдә барган хәлләрне анализлауны күз уңында тота. Ярты ел эчендә максимум өч адымны үтәләр. Әгәр кеше барысын да ташлый икән, барлык ресурслар тикмәгә тотылган булып чыга.

ЕРАККА КАРАП ЯШӘМӘҮ

Үзәккә эләккән кешегә үзе белән нәрсәләр булганын аңлау өчен егерме бер көн таләп ителә. Әзерләнү һәм программаның беренче адымын узу өчен әлеге вакыт җитә: үзеңнең бәйлелегеңне тану, үз авыруыңны ваемлау һәм аның дәваланмавын абайлау өчен. Аннан соң үзең убылып төшкән упкынны язма рәвештә сурәтли башларга, якын-тирәгә китерелгән барлык зыянны дәфтәреңә теркәргә вакыт җитә.

– Мин өйләнгән идем, зыянлы матдәләр куллануымны яшерергә тырыштым. Болар барысы да берничә ел дәвам итте. Әбиләргә, күрәзәчеләргә йөрдем. Бернәрсә дә булышмады. Ниһаять, әни минем өчен шушы үзәкне тапты. Мин дәваландым, әмма күпмедер вакыттан соң тагын «ычкындым», – ди Азат. Профессиясе буенча ул – инженер. Мин Азаттан берничә мәртәбә киләчәге турында сорадым, һәм ул миңа шул ук җавапны әйтте: «Мин еракка карап яшәмим». Аның иң зур теләге – тизрәк өенә кайту. Аңар-

дан тернәкләнү өчен нәрсә таләп ителүе турында сорыйм.

– Аралашу. Хис-тойгылар нинди генә булса да, алар турында сөйләү мөмкинлеге, – дип җавап бирде Азат.

– Минем исемем Александр, миңа 31 яшь һәм мин бәйле, – ди миңа затлы күзлек кигән егет. Һәм үзенең «эчүне, тартуны һәм сөйләшүне» бер үк вакытта башлавы турында шаярта. Александр тумышы белән Йошкар-Оладан, ләкин аны Мәскәүдән «китерәләр», анда ул сөйгән кызы белән яшәргә дип күченгән булган. Әмма бервакыт бер ай туктый алмыйча эч, кызны да өйдән куып чыгара. Бу үзәкне аның өчен әнисе таба.

– Мине төнлә алып килделәр, кая ятарга кирәклеген күрсәттеләр. Иртән бик авыр булды. Алдагы өч көн мин бер кырыйда утырып, төркемнең ничек шөгыльләнгәнен карап тордым. Аннан соң гына кушылдым, нәрсәдер эшли башладым – кирәк икән, димәк, кирәк. Якынча бер айдан соң мин боларның ни өчен кирәк булуын аңлый башладым, – ди Александр.

Сөйгәне белән мөнәсәбәтләр юкка чыга, туганнары белән дә. Шушы көннәрдә Александр елел ярым эчендә беренче мәртәбә әнисе белән кешеләрчә сөйләшкән. Сөйгән кызына шалтыраткан. Ләкин мөнәсәбәтләрне яңарту турында сүз дә була алмый – «нәтиҗәләре начар булырга мөмкин».

– Мин үткән тормышымдагы бернәрсәне дә үзгәртмәс идем, – ди Александр.

– Ә киләчәккә нинди планнар?

– Яшәргә...

ЭПИЛОГ УРЫНЫНА

Илшат горурлык белән телефондагы фотоны күрсәтә: менә дәваланудан соңгы программа этабына чыккан тернәкләнүчеләрнең туганнары һәм психолог белән беренче очрашуы, кибеткә мөстәкыйль чыгулары.

– Без күзәтәбез, хаталар ясамаска булышабыз. Киләчәктә аларның бурычы – АА/АН (алар һәр шәһәрдә бар) төркеменә даими килеп йөрү, спонсор белән эшләү һәм, һәр адымны яза барып, алга таба атлау, – ди Илшат. Ярдәм сорап мөрәҗәгать итәргә беркайчан да соң түгел. Ул үзе «12 адым» программасын яше 40 тан узганнан соң үтә башлый.

– Мин гомерем буе савыгачакмын, – ди Илшат.

Ул – мөселман, аның өчен рухи тормыш бик мөһим. Корбан бәйрәмендә Илшат һәм тернәкләнү узарга килгән тагын ике кеше мәчеткә корбан чалырга һәм итләрне таратырга булышкан.

– Егетләргә бу гамәлләрнең чынлап та тәэсирен күрсәтергә кирәк, үрнәк итеп. Терелү, рухи яктан үсүнең мөмкин икәнлеген, – дип сөйли Илшат. – Көз җитте, мәчет, храм территорияләрендәге яфракларны җыештырырга йөриячәкбез.



ӨМЕТ УТРАВЫ

Татарстанның Питрәч районы Рус Казысы (Казиле) авылында инде берничә ел буе православие общинасы эшли. Биредә яшәүчеләр бертуктаусыз физик һәм рухи хезмәт ярдәмендә бәйлелекнең җимергеч көченә каршы торырга өйрәнә. Әгәр монда бераз тоткарлансаң, игелекнең явызлыкны һаман-һаман җиңүен үз күзләрең белән күрергә мөмкин.

Автор:
Ксения Сёмина

Ял саен общинага килеп, төрле эшләрдә булышып йөрүче Майяның өч яшьлек улы Семен кунак йортыннан каршыбызга йөгереп чыкты да, абынып, тузанга егылды, утырып, елап җибәрә язды. Әмма өлгерә алмый калды: бу вакытта малай янәшәсенә килеп җиткән Казиледәге Изге Ана чиркәве башлыгы һәм община җитәкчесе Силуан атакай кырыс итеп аңа торырга һәм юлын дәвам итәргә кушты. Силуан атакай җитәкчелегендә иркәләнеп ятып булмаячагы шунда ук аңлашылды.

Әмма бик иркәләнәсе килми дә әле. Чиркәү артындагы эскәмиягә утырып, гаять зур яшеллек утравы белән уратылган гыйбадәтханә, общинаның төрле өслүбтәге чуар биналары, алар арасында йөргән вьетнам дуңгызлары һәм казлар көтүе белән хозурланасы гына килә. Кем белә, бу авыл бәлки нәкъ менә алар хөрмәтенә Рус Казысы дип аталгандыр? «Каз иле» бу урынга бик туры килә бит... Хәзер исә казлар иле генә түгел, караңгылыкка баткан кешеләрне кабат якты дөньяга кайтару урыны да бу игелекле җир.

АЕКЛАР БАСКЫЧЫ

– Наркоман – үз якыннарының һәм әйләнә-тирәдәге кешеләрнең җанын суырырга өйрәнгән кеше. Аның башы бик шәп эшли – ул башкалар хисабына әйбәтләп яши. Шуңа күрә наркотик кулланудан туктау гына аз. Башны үзгәртергә, тырай тибүдән туктарга кирәк, – ди Силуан атакай. Ул миңа общинаны күрсәтеп йөри, мин аның адымнары артыннан да, уйлары артыннан да көчкә өлгерәм. – Өч айда «аеклык» халәтенә килергә, бәйлелеккә каршы тору өчен догалар кулланырга өйрәнеп була. Әмма баш үз урынына утырсын өчен, күпкә озаграк вакыт таләп ителә. Минемчә, бер ел буе чиркәүдә яшәп, бөтен кушылганнарны үтәгәндә генә кешене чын тормышка тулысынча кире кайтарып була.

Бүген «Ковчег» общинасында яшәүче 18 кеше – беренче карлыгачлар түгел. Шулай булса да, биредә төзелеш, Силуан атакай әйтүенчә, перманент халәттә. Барлык йортларның һәм ярдәмче корылмаларның төрле вакытта төрле кешеләр тарафыннан төзелүе күренеп тора. Гыйбадәтханәнең йөз ел буе акшар һәм буяу күрмәгән кирпеч диварлары аны җилдә җилфердәгән әләмгә охшата һәм, авылга килеп җиткәнче үк, әллә кайдан күзгә ташлана. Әле моннан берничә ел элек кенә ул ташландык бер бина хәлендә булган. Тернәкләнүчеләр тырышлыгы нәтиҗәсендә хәзер аның эчендә чиста һәм якты. Общинада яшәүчеләр бина эчен үзләре

Фото: Олеся Бондаревская



Силуан атакай бирегә Казаннан җәяүләп моннан тугыз ел элек килгән. Ул вакытта әле ул Силуан түгел, бәлки бизнесыннан һәм аның белән бергә бөтен нәрсәсеннән колак каккан эшкуар Сергей булган.

тәртипкә китергән, яңа тәреләр өчен сырлы рамнарны да үзләре ясый. Гыйбадәтханәне торгызу – общинаның төп «гамәли» максатларыннан берсе. Әмма бик тырышып эшләсәләр дә, иганә акчасына гына торгызу эшләре шактый акрын бара. «Ковчег» общинасындагыларның, чиркәү белән бергә, үзләрен әкренләп, адымлап сихәтләндерүгә дә, гыйбадәтханә бинасын торгызу да – икесе бер үк тизлектә бара, дип әйтеп була.

Бирегә төрле юллар белән килеп эләгәләр. Кемнедер туганнары китерә, кемдер үзәк турында мәгълүматны Интернеттан үзе таба. Силуан атакай үзе исә бирегә Казаннан җәяүләп моннан тугыз ел элек килгән. Ул вакытта әле ул Силуан түгел, бәлки бизнесыннан һәм аның белән бергә бөтен нәрсәсеннән колак каккан эшкуар Сергей булган. Бераз тынычланырга, бер-ике атна общинада эшләргә ниятләгән – аның турында ул «Эфир» телекомпаниясе программасында ишеткән. Ике атна ярты елга сузылган. Аннары ул Нил Столобенский ирләр православие монастырена укырга киткән. Моннан дүрт ел элек Казилегә иеромонах, рухани булып әйләнеп кайткан.

– Мин килгәндә, биредә Вячеслав атакай (Шапоров – ред. иск.) һәм Үзәктән берничә кеше яши иде. Аларның тормышын яшәү дип атап булса. Без бергәләп ярымҗимерек агач йортны кеше яшәрлек хәлгә китердек. Минем бернәрсә дә төзеп караганым юк иде аңарчы. Безгә Ходай ярдәм иткәндер ул чакта. Бүгенге дәваланучылар да әкренләп тырмаша, – ди Силуан атакай.

Без торак йортка керәбез. Беренче катта – кечкенә генә кунак бүлмәләре һәм монда инде өч ел яшәүче Дмитрий бүлмәсе. Бик текә агач баскычтан – Силуан атакай аны аеклар баскычы дип шаярта – икенче катка менәбез. Бүлмәләр кечкенә, карават һәм өстәл сыярлык кына. Шартлар спартаннарча диярлек. «Ковчег» үзгендә яшәүчеләр, иртәнге алтыда йокыдан торып, сигезенче яртыга кадәр чиркәүдә гыйбадәт кыла. Сәгать 8 дән 11.30 га кадәр бина һәм корылмаларны торгызу эшләрендә катнашалар. 12 дә – төшке аш, 14.00 гә кадәр – йокы вакыты. Кичке 5 кә кадәр тагын эшлиләр, аннары гыйбадәт кылалар, ашыйлар. Кичке сәгать 10 да йокларга яталар.

– Буш вакытлары бармы соң?

– Менә бит – кичке уннан иртәнге алтыга кадәр, – дип әллә шаяртып, әллә җитди җавап бирә Силуан атакай.

– Түзәрлек, без бит ирләр. Гыйбадәттә генә озак басып тору авыррак, әмма анысына да күнегергә була, – ди үзәктә яшәүчеләрнең берсе. Гел елмаеп торгангамы, аңа 36 яшь биреп тә булмый. Гомеренең шактый өлешен наркотиклар кулланып әрәм иткән. – Бирегә ничек килеп эләктемме? Ниндидер бер мизгелдә якыннарым алдында бик оят булып китте. Апам бу урынны Интернет аша тапты. Мин китеп тә бардым. Баштарак гел чыгып качасы килеп торды, ниндидер җен куган кебек булды. Сабыр иттем, бер көнгә өйгә кайтып килдем һәм әлегә монда калырга булдым. Минем рәтле һөнәрем дә юк иде – гел әле тегендә, әле монда эшләп йөрдем. Хәзер акылга утырырга телим. Беркайчан да ташчы була алырмын, дип уйламаган идем. Әмма монда килүгә үк, сыер абзарына нигез сала башладык – ярыйсы гына килеп чыкты.

ХЕЗМӘТ ҺӘМ СӨЕНЕЧ БАКЧАСЫ

Ярдәмче корылмалардан тыш, община 30–40 кешелек Хаҗилар йорты төзүне дә планлаштыра. Элек биредә «тәрбияләнүчеләр» дә чиркәү бәйрәмнәренә гаиләләре белән килә, кайвакыт 200 ләп кеше җыела. Гыйбадәтханә янәшәсендә зур бакча бар – 200 төп слива, алмагач, чия, карлыган куагы утыртылган. Барысын да карап өлгерергә кеше җитми.

– Безнең максатыбыз – үзебезне тулысынча тәэмин итүгә кучү. Элеккеләреннән аермалы буларак, районның яңа җитәкчесе безне хуплады һәм 36 гектар җир бүлеп бирде. Безгә сыерларның баш санын 10 га, казларыкын – 600 гә, дуңгызларныкын

Бирегә төрле юллар белән килеп эләгәләр. Кемнедер туганнары китерә, кемдер үзәк турында мәгълүматны Интернеттан үзе таба.

20 гә җиткерергә кирәк. Аннары шул продукцияне саткан акчага без ут, газ һәм җылылык өчен түли алачакбыз, – ди Силуан атакай.

Ишегалдына үзләре спорт тренажерлары да ясап куйган. Бер егет турникта тартыла, димәк, физик тәне тәртиптә. Ә менә җаны ничегрәк икән?

– Наркотиксыз кыен, билгеле. Догалар укып, физик эш белән юанып, төзәргә тырышам. Мин биредә инде икенче тапкыр. Беренчесендә ярты ел яшәп киттем. Ул чакта нәрсәнедер аңлап бетермәгәнмен, күрәсең, – дип елмая егет. Ул Ижевскидан, исеме – Дмитрий. Автоаксессуарлар һәм автокосметика белән шөгыльләнә. Моннан берничә ел элек аның эшләре бик шәп барган. Артыгы белән шәп барганга, шундый хәл килеп чыкты, дип саный Дмитрий. Аның сихәтләнүен өйдә хатыны һәм балалары көтә.

– Минем кайтыр җирем бар. Әгәр гаиләм булмаса, белмим, бәлки мин инде исән дә булмас идем... – дип дәвам итә егет. – Наркотикларны мин әле мәктәптә укыганда ук куллана башладым – чөнки бу сыйныфташларым һәм яшьтәшләрем арасында популяр иде. Хәзер инде аларның күбесе – җир астында...

– Мондый кешеләр өйләрендә һәрвакыт ялганларга мәҗбүр. Биредә исә беркемнән дә бернәрсәне дә яшерергә кирәкми. Койма да юк – телисең икән, кит, беркем дә тотып тормый. Төрле хәлләр була, кабат «ычкынулар» да, сихәтләнергә теләмәү дә. Әмма «ычкыну» ул бер нәрсә, ә ният исә – икенче. Мәсәлән, кеше безгә килгәч тә эчүен дәвам итә. Андыйларны без куып җибәрәбез. Бу – иң куркыныч җәза, – ди Силуан атакай. – Гыйбадәтханә һәм дога – Ходайның рәхмәте ул, бөтен нәрсәне үзгәртергә сәләтле. Биредә беренче айларда кеше айный, үзе өчен дөньяны яңадан ача. Әмма бу гына җитми әле. Ул үзен башкаларга багышларга тиешлеген аңларга тиеш, аны Ходай шуның өчен яраткан. Бары тик шул вакытта гына әфьюн кулланмыйча да рәхәтләнеп яшәргә була. Син шулай хәл иткәнгә яки сине мәҗбүр иткәнгә түгел, бәлки, шундый «сөенечнең» сиңа кирәклеген аңлаганга. Чөнки син, ниһаять, иң мөһим нәрсәгә – гомер, өй, гаиләнең иң зур куаныч икәненә төшенәсең.

БАШКАЛАРНЫ КОТКАРГАНДА, ҮЗЕҢ ДӘ КОТЫЛАСЫҢ

– 1988 елның 23 декабре. Туган көнем. Бу турыда кичә кич чиркәү календарена карагач кына исемә төшердем... Минемчә, бу минем соңгы берничә елда беренче хәсрәтсез һәм сагышсыз туган көнем. Минем туган көнем булуын биредә беркем дә белми, шуңа котлаучы булмады. Аларның моны белмәүләре, шул белмәүләре белән миңа тынычлык бүләк итүләре өчен мин аларның барысына да шулкадәр рәхмәтлемен... – дип кычкырып укый өч монах тормышы турындагы «Пасха Красная» китабын бер дәваланучы. Аш вакытында кычкырып китап уку – община көнкүрешенең аерылгысыз өлеше. Табында бик гади ризыклар. Эшчеләрне ашатканнан соң, Майя безне дә табынга чакыра.

– Аларга, мөгаен, казылык кирәктер, ә синең кысыр ризык кына, – дип шаярта Силуан атакай. Әмма минем общинадагылар ризыгын авыз итәсем килә. Дога укыганнан соң, табынга утырабыз. Итсез булса да, бик тәмле борчаклы аш, карабодай боткасы. Үзләре үстергән һәм тозлаган яшелчәләр. Тәмле итеп пешерелгән чәй...

Сыйланганнан соң Валерия карап үстерә торган яшелчә бакчасына юл тотабыз. Майя кебек үк, ул да дәваланучы түгел, Казаннан үзе теләп булышырга йөри. Теплица, помидор, суган, кәбестә, чәчәк түтәлләре – барысын да карарга кирәк.

– Бакчаның бу өлешендә әле былтыр гына урман кебек кычыткан үсә иде. Эшчеләр утап чыккач, без түтәлләр ясадык. Биредә бик уңдырышлы кара туфрак, – ди Валерия. – Тагын әле бик матур итеп кошлар сайрый. Таң алдыннан мондагы кебек кошлар сайравыннан матуррак нәрсәне ишеткәнем дә, күргәнем дә юк.

Мондый идиллия фонында «кислота», «тозлар» һәм «спайслар» турында, «химиянең» психиканы тулысынча җимерүе хакында сөйләшүе дә кыргый тоела. Общинага андыйлар да эләгә, тик аларга инде берничек тә ярдәм итеп булмый икән.

– Мондый тайпылышлары булган «пациентларны» без психоневрология диспансерына тапшырабыз. Кызганыч ки, нигездә алар барысы да бик яшьләр. Психикалары сакланып калган яшьләрне дә элегрәк үзебездә калдырмый, артык яшь булулары һәм тормыш тәҗрибәләре җитмәү аркасында, программаны аңлы рәвештә үтә алмаслар, дип саный идек, – дип сөйли Силуан атакай. – Әмма мондыйларны да төзәтеп була икән. Менә Ваня Кондратьев бездә берничә ай яшәде. Ул кикбоксинг белән шөгыльләнә, монда чакта да титул яулау турында хыяллана. Һәм яулады да бит – хәзер ул Россия чемпионы. Киләчәге тагын да уңышлырак булыр, дип өметләнәм. Һәм аның кебекләр шактый.

Иеромонах Вячеслав (Шапоров),
Казан епархиясенең наркомания һәм эчкечелеккә каршы тору бүлеге рәисе:

– Россиядә тиңе булмаган «Ковчег» православие психотерапия җәмгыяте моннан 10 елга якын элек безнең бүлек базасында төзелгән иде. Без республика наркодиспансеры һәм СПИД үзәге белән тыгыз хезмәттәшлек итәбез. Әлеге тәҗрибәне файдаланып, 2007 елда «Православная инициатива» конкурсы грантына изге Варсонофий мәхәлләсе Мәгълүматагарту үзәген ачтык, анда теләгән һәркем психолог, катехизатор, консультант ярдәмен һәм киңәшен ала ала. Хәтта медикларыбыз да бар – әгәр кешегә детоксикация таләп ителә икән, без аңа наркодиспансерга урнашырга булышабыз. 2009 елда Митрополит Анастасий Рус Казысы (Казиле) авылында психотерапия общинасы ачылуына фатыйха бирде. Безнең тернәкләндерү эше үзебез үк эшләгән программа нигезендә алып барыла, ул дәүләт наркотикларга каршы комиссиясе, шулай ук Рус православие чиркәвенең Дини белем бирү һәм катехизация бүлеге программасы экспертизасын үтте. «Ковчег» оештырылганнан бирле аның аша 500ләп кеше үтте (общинага ирләр генә кабул ителә), шулардан якынча өчтән бере – башка төбәкләрдән. Хәзер без Татарстанның Кама Тамагы районында хатын-кызлар өчен шундый ук община ачарга ниятлибез. Без Татарстан Хөкүмәтенең берничә грантын оттык, әмма нигездә җәмгыять сәдака, иганә хисабына яши. Гыйбадәтханә төзү – озак вакытка исәпләнгән проект. Безнең «пациентларыбыз» аны үзләре өчен генә түгел, үзләреннән соң киләсе кешеләр өчен дә төзи. Кагыйдә буларак, бәйлелеккә эләккәннәрнең туганнары бөтен булган чаралар – имчеләр, экстрасенслар, кыйммәтле тернәкләндерү программалары өметләрен акламагач кына безгә мөрәҗәгать итә. «Ковчег» – аларның соңгы өмете. Әмма биредә дә савыгу – бик озак һәм катлаулы процесс. Үз-үзеңне җиңү бик кыен, әмма православие чиркәвенең бу өлкәдә гасырлар буена тупланган тәҗрибәсе бар. Наркоманның төп проблемаларыннан берсе – үз-үзе белән мавыгучанлыгы. Безнең тернәкләндерү программасы дөнья рәхәтеннән ваз кичүне таләп итә. Кеше үз янәшәсендәгеләрне, аларның бәлаләрен, проблемаларын күрә, аңлый башлый. Шуңлыктан үз дәртен җиңгәннәр еш кына башкаларга ярдәм итәргә керешә.

БЕР ЧЕЛТӘРГӘ ЭЛӘКӘННӘР

Без үзебезне смартфоннар, мессенджерлар һәм Интернеттагы мәгълүмат ташкыныннан башка инде күз алдына да китерә алмыйбыз. Әмма алгарыш тәкъдим иткән әлеге бүләкләрнең аръягында ни торганын һәрчак ваемлап кына бетермибез. «Татарстан» тормышны «офлайн» рәвештә күзалламаучыларга нәрсәдән шикләнергә, сагаерга икәнен ачыклады.

Автор:
Ксения Сёмина

«Соңгы берничә көн дәвамында мин кайда булдыммы? Оффлайн лагерьга эләктем. Анда барлык телефоннар да сүндереп куелган иде, сәгатьләр дә юк хәтта. Ә нәрсә бар соң, дисезме? Нарат урманы, саф һава, тәмле һәм файдалы ризык, әйбәт компания, балачакка алып кайта торган уеннар, рәсем ясау һәм практикалар, йога, цигун, җанны эретердәй җырлар, ә кичләрен учак каршында утырып сөйләшүләр. Баш миен һәм җан халәтен яңадан үзгәртеп корыр өчен – менә дигән җирлек. Олы булырга, әмма теләгән бөтен нәрсәне дә эшләргә рөхсәт итәргә кирәк үзеңә», – дип яза бу хакта үзенең аккаунтында Казан стилисты һәм арт-продюссеры **Ләйсән Усманова**. Алдагы 4 көнне ул «Все выключено» лагеренда уздыра. Лагерьның төп шарты – программа узганда тулаем Интернет белән гаджетлардан баш тарту. Кунаклар (программа узучылар), килгәч тә, гаджетларын махсус пакетларга салып, пакетны ябыштырып куя. Күпләр, ымсынуын тыя алмам, дип шикләнеп, пакетны оештыручыларга тапшыра. Спорт, иҗади һәм интеллектуаль уеннар, лекцияләр, медитацияләр – болар барысы да килүчеләргә тиздән (дөрес, бөтенләй «ломка»сыз түгел-түгелен) Интернет-аралашуны алыштыра. Ә инде программа ахырына китәргә үк теләмәү башлыйлар.

Проект идеясе Казан эшмәкәре **Дмитрий Никитинның** башында туа. «Все выключено»ның ике ел эшләве дәвамында биредә диджитал-детоксны Татарстанның дистәләрчә яшьләре уза.

– Күпмедер вакыт элек минем эшем яңалыклар контентын тикшереп тору белән тыгыз бәйләнгән иде. Елдан артык вакыт аралыгында үзем аша коточкыч зур мәгълүмат ташкыны уздырдым. Һәм бервакыт ваемлап алдым: «монда һәм хәзер» булуның нәрсә икәнен оныта башлаганмын лабаса. Моннан тыш, бу эшчәнлекнең психикама да начар тәэсир итүен сизә башладым. Шуннан инде мәгълүмати технологияләрнең безнең баш миенә тәэсирен өйрәнергә керештем, теманың шактый киң колачлы булуына төшендем, – ди Дмитрий. – Безнең проектның максаты – кешеләргә бәйлелекне җиңәргә булышу, һәрхәлдә, аның барлыгын таныргa мөмкинлек бирү. Бүген бу бәйлелек бик күп төрле формалар ала – маньякларча «сёрфинг»тан (челтәрдә, эшең булмаса да, чыгып китә алмыйча утыру) башлап, компьютер уеннарына һәм порнографиякарауга кадәр (ничек кенә гаҗәп яңгырамасын, абсурд тоелмасын, гаиләләр җимерелә). Интернетта даими утыручы кеше үзенең фикер киңлеге арта дип уйлый, ләкин, асылда, аның баш миендәге логик һәм эзлекле бәйләнешләр генә җимерелә.

«Все выключено» шикелле проектлар – бүген берән-сәрән генә. Ул арада кешенең дөньяны кабул итү рәвешенә һәм аңына йогынты ясый торган цифра ташкыны турында инде шактый күптәннән сөйлиләр.

БАШ МИЕНӘ КАПКЫН

Интернет-контент булдыру һәм аны таныту буенча «Кобизмедиа» (Kobizmedia) Сеул компаниясе үз кулланучыларына тест үтәргә һәм түбәндәге сорауларга «әйе» йә «юк» дип җавап бирергә тәкъдим итә:

- [ ] хәтеремдә сакланган бердәнбер телефон номеры – өй телефоным яки офисныкы;
- [ ] мин үзем яшәгән шәһәр эчендә навигатор буенча гына йөрим;
- [ ] кулдан язмыйм, бары тик нинди дә булса кәгазьгә кул куярга кирәк булган очракта гына;
- [ ] мин кичә нәрсә ашаганымны хәтерләмим;
- [ ] дусларым белән аралашу, сөйләшүләрнең 80%ы социаль челтәрләр белән мессенджер аша бара;
- [ ] дуслар миңа еш кына «син инде бу тарихны сөйләдең» диләр;
- [ ] мин кешенең исемен таныштырганнан соң ук онытам;
- [ ] соңгы сатып алулардан соң күпме акча түккәнемне абайлау миңа авыр бирелә;
- [ ] атналар буе җырлап йөргән җырымның сүзләрен кисәк искә төшерә алмый интегәм.

Өч яки аннан да күбрәк сорауларга «әйе» дип җавап биргәнсез икән, «Кобизмедиа» сезгә күңелсез яңалык тәкъдим итәчәк: бу нәтиҗә «цифра Альцгеймеры» дигән башлангычка ишарә (аны икенче төрле «цифра деменциясе», «цифра зәгыйфьлеге» дип тә атыйлар). Әлеге терминның киң таралышын алман психиатры Манфред Шпицер тәэмин итә. 2012 елда басылып чыккан «Антимозг» китабында ул, Корея галимнәре хезмәтләренә нигезләнеп, Интернетта туктаусыз утыруның, яңалыклар тасмасын даими карап торуның хәтернең зәгыйфьләнүенә, игътибарны юнәлтү сәләтенең җимерелүенә, аның таркаулыгына, хис-тойгыларның саегуына китерә дип расլый.

«Массакүләм мәгълүмат һәм коммуникация чаралары белән Интернет аркасында безнең кабул итү сәләтебез көннән-көн тирәнлеген югалта бара. Элек текстларны укыйлар иде, бүген аларны өстән-өстән генә карап чыгалар, ягъни «сикереп узалар». Элек теманы аңларга тырышалар иде, бүген, аның урынына, Интернет буйлап «сәяхәт итәләр». Мәгълүматның өслегеннән, дулкын өстеннән шугандай, җилдереп узу махсус терминга да ия булды – «серфить» дип атала ул», – дип яза Шпицер. Китапта «цифра Альцгеймеры» теориясен болай нигезләп аңлата автор: яңа күнекмәне яки мәгълүматны тиешле дәрәҗәдә үзләштергән очракта баш мие яңа нейрон бәйләнешләр хасил итә. Ул бәйләнешләр никадәр күбрәк булса, кеше шулкадәр активрак һәм җитезрәк уйлый, фикер йөртә. Мәгълүмати «серфинг» исә нейрон сукмакларын булдыруга, яңартуга булышмый, киресенчә, инде булганнарының ук җимерелүенә китерә. Чөнки алар кирәгенчә файдаланылмый. Алман психиатрының әлеге теориясе тәнкыйть давылы кубарды, ул әле һаман да фән өлкәсендә һәм фән тирәсендәге җәмгыятьчелектә бәхәсләр уята.

– Билгеле, «деменция» белән «серфинг» арасында билгеле бер корреляция бар. Әмма бу очракта сүз «ялкау» баш мие турында бара, алай гына да түгел, «эшлексез» баш мие дип атарга була аны. Бу кешенең картаюы белән бәйле конкрет морфологик үзгәрешләрдән аерылып тора, – ди Белоруссия дәүләт медицина университетының Нормаль анатомия кафедрасы доценты, медицина фәннәре кандидаты, нейроанатом Андрей Сокол. – «Цифралы» үзгәрешләр, яшь белән бәйле булганнарга караганда, элеккеге хәленә кайтаруга бирешәләр әле. Барысы да конкрет очракның ни дәрәҗәдә катлаулы булуына, процессның никадәр тирәнгә китүенә бәйле.

Шпицер идеясе яклылар арасында атаклы Россия психотерапиясен популярлаштыручы зат – Андрей Курпатов та бар. Аның әйтүенчә: «Яшь кешеләр көнөнә телефон, планшетына, компьютерына йөзләгән белешмә ала. Ә баш мие эшләсен өчен 24 минутлап вакыт кирәк – нәкъ менә шул вакытта гына чын-чынлап игътибарны юнәлтеп була», – ди ул үзенең бер лекциясендә.

«Серфинг»ның төп зыяны, Курпатов әйтүе буенча, баш миенең төп өч нейрон челтәренә җимергеч тәэсир ясавында. Болар – әһәмиятлелекне билгели торган, нәрсәне дә булса үтәүгә бәйле һәм пассив эш режимы өчен җаваплы челтәрләр. Шартлы рәвештә бу болайрак бара: әйтик, сезгә эшегездәге нинди дә булса мәсьәләне хәл итәргә, үтәргә кирәк, ди, ә аннары – концертка юл тотарга. Бар да нормада булган очракта әһәмиятлелекне билгели торган челтәр гамәлләр тәртибен аерып куя, үтәү системасы мөмкин булган кадәр кыска һәм оптималь юллар белән аны үтәү механизмын эшкә җигә, пассив режим исә эшне «тикшерә» һәм, яхшы үтәлгән очракта, «мактый». Шуннан соң инде сез тыныч күңел белән концертка барасыз. Әгәр үтәлеш барышында сез социаль челтәрләрдә утырасыз, Интернетта серфинг белән шөгыльләнәсез икән, эшегез вакытында үтәлмәячәк. Мәгълүмат ташкынында йөзеп йөргәндә сезнең үтәлеш өчен җаваплы челтәрегез активлашып китеп, калган икесе бастырып куела. Игътибарсызлык арта, эшегез хаталар белән эшләнергә мөмкин. «Онлайн» режимда утырганга, сез күп нәрсәне истә калдырмаячаксыз. Пассив режим ул очракта концертта чакта да сезгә музыкадан тәм табарга рөхсәт бирмәячәк.

Ситуациянең җитдилеген фән өлкәсендәге галимнәрнең дә соңгы арада «цифралы аңгыралану» күренешенә зур кызыксыну белдерүе раслый.

– Интернетның баш миенә тәэсире – бүгенге көннең гаять актуаль һәм җитди темаларының берсе. Хәтер белән игътибарны, аның проблемаларын өйрәнә торган кафедралар хәзерге вакытта баш мие белән аңарга

йогынты ясый торган электрон девайслар арасындагы бәйләнешләр процессын актив рәвештә тикшерә. Әйтергә кирәк, девайсларның йогынтысы шактый көчле, алар когнитив процесслар үзгәрешенә кадәр китерә. Электрон гаджетлар куллануның нәкъ менә тормыш дәвамында акыл зәгыйфьләнүгә китерүе турында авыз тутырып әйтмәс идем әйтүен дә. Мисал өчен, үзебезнең совет психологы А.Н. Леонтьевның узган гасырның 30 нчы елларында уздырган бер экспериментын гына алыйк. Ул экспериментта балалар һәм өлкәннәр катнаша, аларның карточкалар ярдәмендә ятлап алу өчен тышкы чаралар (әйтеп җибәрүләр) куллануы тикшерелә. Тәҗрибәдә катнашучыга сүзне әйтәләр дә ул сүз белән ассоциация уята торган сурәт алырга тәкъдим итәләр. Соңрак, сайланган картиналарга карап, тәҗрибәдә катнашучы әйтелгән сүзләрне исенә төшерә. Нәтиҗә мондый була: барлык



яшьтәге катнашучылар да мәгълүматны, сурәткә (тышкы чарага) күчкәннән соң, әлеге дә баягы сурәт аша хәтерләп кала, сурәт сүзләрне искә төшерергә ярдәм итә, – ди МДУ Психология факультеты студенткасы **Арина Шатская**. – Ярдәмчел чаралар булмаса, истә тоту сәләте кими, чөнки хәтернең эшлекле өлешендә тагын да күбрәк урынны бушату таләп ителә. Ә ярдәмчел чара мәгълүматны тышкы чыганакта тотарга мөмкинлек бирә. 2000 нче елларда экспериментны яңадан кабатлыйлар. Бу очракта инде балаларның кече яшьтән истә тотуның ярдәмчел чараларыннан файдалануы ачыклана. Ягъни безнең заманда ирекле хәтернең корал буларак үсешенә таба күчеш булганлыгы тәгаенләнә. Әгәр кешеләр элегрәк шигырьләрне озак вакыт яттан хәтерләсә, хәзер инде без аңлы (ә бәлки, аңсыз да) рәвештә аларны каян да булса табып ала аласыбызны беләбез. Шуңа да артык мәгълүматны башта тотуны кирәк дип тапмыйбыз. Без, мәсәлән, яңалыклар укыйбыз, әмма инде укыган артыннан ук аларны башка яңалыклар күмеп китә. Аның алдыннан укылган яңалык безнең хәтердә укылу факты белән урнашып кала. Безнең аң-фикерләү сәләтебез тирәнлеген һәм җентекләп тикшерү, өйрәнү зарурияттен җуя бара. Бу фәнни телдә Гугл-эффект дип атап йөртелә. Асылда, шул рәвешле без технологияләргә көннән-көн бәйлерәк була барабыз.

ЯЗУЧЫ ҺӘМ КИНО ДРАМАТУРГЫ ЛИЛИЯ КИМНЫҢ МӘГЪЛҮМАТНЫҢ ЦИФРАЛЫ ТАШКЫНЫ БЕЗНЕ ТУЛАЕМ КҮМЕП КИТМӘСЕН ӨЧЕН БИРГӘН КИҢӘШЛӘРЕ*:

1. Спорт белән шөгыльләнә башлагыз. Физик активлыкның баш миендәге нейрон челтәрләрен активлаштыруын инде күптән исбатладылар. Бу исә, үз чиратында, хәтерне яхшырта, мидәге башка функцияләрне дә эшкә җигә.
2. Күзаллауны үстерегез, иҗат белән шөгыльләнегез. Бу инде мәгълүматны пассив рәвештә кулланып утыру гына түгел.
3. Акыл эшчәнлеген математик һәм техник бурычлар чишеп тонуста тотыгыз.
4. Кәгазь китаплар укыгыз. Электрон китапларны гаджетларга тиңләргә мөмкин.
5. Музыка уен коралында уйнарга өйрәнегез.
6. Социаль мохиткә «чыгыгыз» – рухыгызга якын булган кешеләр белән аралашыгыз. Ялгызлык акыл эшчәнлегенә зарарлы йогынты ясый. Шулай ук – негатив эчтәлекле коммуникацияләр дә, шунлыктан комфорт китермәгән аралашуны өзегез, дип киңәш бирер идем.

* Мәгълүмат Лилия Кимның «Фейсбук»тагы битеннән алынды



ОЛЫЛАРЧА УЕННАР

Күпмедер вакыт элек Интернетта Америка яшүсмере төшергән кыска гына ролик зур популярлык казанган иде (2,5 миллион карау җыйды ул). Видеода аны төшергән блогерның олы абыйсы котырына, кычкыра, бүлмә буйлап тәгәрәп йөри, хәтта башын төя. Нәрсә булганмы? Әти-әниләре аның World of Warcraft онлайн-уенындагы аккаунтын япканнар икән. Социаль челтәрләрдәге шәрехләүчеләрнең фикерләре кискен рәвештә икегә аерылды – кемдер малайның психикасы бик борчылды, кемдер әти-әнисен шелтәләде, сүкте. «Кеше берничә ел дәвамында даими рәвештә уйный икән, аның уенга эмоциональ яктан бәйлелеге бик көчле була... Чөнки бу әле – билгеле бер эшнең нәтиҗәсе дә. Әйтик, кеше 5 ел буена уйнаса, ә аңа шартлы рәвештә 14 яшьләр тирәсе булса, димәк, ул гомеренең аңлы өлешендәге күп вакытны шушы уенга багышлаган булып чыга. Бу – аның тормышының гигантларча зур катламы. Әти-әнисе, мәктәбе, һәм башка чынбарлык катламнары шикелле үк», – дип яза Россиянең бер блогеры. Белгечләр мондый очракларда мавыгу турында түгел, ә нәкъ менә җитди бәйлелек турында сүз алып бара. Узган елның ноябрь аенда, мәсәлән, Сеулдагы (Көньяк Корея) Корея университетының нейрорадиология профессоры Юнг Сук Со смартфоннар белән Интернетка бәйлелек кичергән һәм тикшеренү үткән 19 яшүсмернең баш мие күрсәткән нәтиҗәләрне дөньяга яңгыратты.

Галимнәр җитди бәйлелек кичерүче һәм гадәти үсмерләрнең баш мие активлыгының тукталып тору (гамма-аминомайлы кислота) һәм ярсыну (глуатамин кислотасы) нейромедиаторлар дәрәҗәсен үлчәп карыйлар. Гаджетларга кереп чумган үсмерләрнең тукталып тору өчен җаваплы нейромедиаторлар дәрәҗәсе шартлы нормадан күпкә югары булып чыга, бу, үз чиратында, даими йоклыйсы килүгә, борчылуларга китерә. Шулай ук тирә-юньдәге хәлләр, вакыйгалар, күренешләрне кабул итү, эмоцияләр кичерү процессын да җимерә. Тугыз атнага сузылган когнитив-үз-үзеңне тотыш терапиясеннән соң гына бәйлелеккә дучар булган үсмерләрнең гамма-аминомайлар дәрәҗәсе сизелерлек кимеде һәм норма халәтенә кайтты, ди белгечләр. Корея галимнәре кулланган терапия Россия җирлеге өчен дә менә дигән булыр иде.

– Яшьләрнең смартфоннар һәм Интернет белән мавыгуы шулкадәр киң таралган күренеш ки, ул инде нормага әверелеп бара. Әмма яшүсмер күпчелек вакытын «онлайн» режимында уздыра икән, аның башка нәрсәгә вакыты калмаячак та. Хәтта нормаль йокыга, ашау-эчүгә, гигиенага. Спорт турында инде әйтеп тә торырга кирәкми, чөнки ул – бәйлелек капкынында, – ди хәзер Питерда эшләүче, элеккеге Казан психиатр-психотерапевты, Аналитик психологиянең төбәкара укыту үзәге директоры (Санкт-Петербург), Татарстан һәм Россиянең Язучылар берлеге әгъзасы **Валерий Трофимов**. – Бу очракта Интернет һәм социаль челтәрләрне кулланудан тыю – мәгънәсез эш, җавапка бары тик агрессия кубачак та элеккеге тормыш рәвешенә кайтыр өчен алдаулар, хәйләгә барулар башланачак. Шуны аңлау мөһим: яшүсмер өчен Интернетка бәйлелек – еш кына күтәрә алмастай чынбарлыктан качу чарасы. Гаҗәттә аңа чынбарлыкта үзен шәхес итеп санамауларын тоюдан бик авыр. Еш кына кимсетелгән, эзәрлекләнгән балалар челтәргә «китә», чөнки Интернетта ул вакытлыча конфликтлар, кыенлыклар, изоляциядән котыла, үз комплексларыннан арынып тора. Димәк, аны чынбарлыкта аңлаучы,

БАЛАГЫЗДА БӘЙЛЕЛЕК ЧАЛЫМНАРЫ СИЗЕЛСӘ, НӘРСӘ ЭШЛӘРГӘ КИРӘКЛЕГЕ ТУРЫНДА ВАЛЕРИЙ ТРОФИМОВ КИҢӘШЛӘРЕ:

1. Иң башта үзегезгә сорау бирегез: үсмерне әйләндереп алган чынбарлык ни өчен канәгатьләндерми? Гаиләдә аңа игътибар белән аралашу җитәме? Сез вакытыгызны еш бергә уздырасызмы? Уртак кызыксынуларыгыз бармы? Сез яшүсмерне тыңлыйсызмы, аңларга, кыен чакларында ярдәм итәргә тырышасызмы? Аның кадерле икәнлеген әйтәсезме? Әллә нидер таләп кенә итәсез, ачуланасыз, контрольдә тотасыз, кисәтәсез, шелтәлисез, кыскасы, шулай тәрбиялисезме? Үсмер белән гаиләгездәге өлкән буын вәкилләре ачыктан-ачык, күңелләрен бушатып сөйләшеп утырамы? Сез аның карашларын, уй-фикерләрен, үзегезнекен өстен чыгармый гына, тыңларга сәләтлеме? Сез, әти-әниләр, үзегезнең буш вакытыгызны нәрсәгә багышлыйсыз? Яшүсмергә нинди үрнәк бирәсез?
2. Виртуаль чынбарлыкка качарга, модадан, заман таләбеннән кала, нәрсә этәрә сезнең балагызны? Мода ул һәркемгә дә кагыла, әмма нигездә күңеле китек, рәнҗетелгән балалар килеп эләгә аның капкынына.
3. Ул әле аны чишәргә әзер булмаса да, яшүсмерне килеп туган проблемасы белән күзгә-күз калдырмыйсызмы? Әлбәттә, аңарга ярдәм итәргә кирәк, бәлки, махсус белгеч чакырып та. Кайчакта гаиләнең дидактик стилендәге кискен урыннарны, ялгышларны бары тик белгеч кенә күрә дә, күрсәтә дә ала.
4. Сүз түгел, гамәл таләп ителә. Интернетка бәйлелек, башка бәйлелекләр шикелле үк, системалы гаилә проблемасы. Әгәр бөтен гаилә җыйнаулашып аны үз өлешләренә тигән сынау дип кабул итми һәм бу проблема белән эшләргә керешми икән, берни дә килеп чыкмаячак.



буенча Королева җәмгыяте (RSPH) һәм Яшьләр сәламәтлеге хәрәкәтенең (ҮНМ) узган елгы докладларына караганда, әлеге платформаның сораштыруда катнашучы 14–24 яшьлек миллион ярымнан артык яшьләрдә негатив ассоциацияләр уятуы ачыкланды. Әлеге социаль челтәр еш кына кулланучыларында үз тәне, гәүдәсеннән ризасызлык кичерүгә китерә, тынычлап йокларга комачау итә, чөнки «онлайн» булмаганда, мөһим яңалыкны күрми калырмын, дигән уй тынгылык бирми.

– Үз ирешкәннәреңне түбәнсетү эффекты да сизелә, чөнки лентаны караганда башкаларның тормышы күпкә шәбрәк булып күренә. Яшьләр бу капкынга бигрәк тә тиз килеп каба. Ә иң зур иллюзия – социаль челтәрләр безнең дусларыбыз, аралашу даирәбез гаять киң, дигән тәэсир уята, чынлыкта бу дөреслеккә бөтенләй туры килмәсә дә. Чын аралашу ул – бөтенләй үзгә нәрсә. Чынбарлыктагы дуслар, танышлар һәм алар белән мөнәсәбәтләр эмоциональ яктан да, вакыт ягыннан да күбрәк

чыгымнар таләп итә. Бүген күпләр бу төр аралашудан баш тартырга да әзер, – дип ассызыклый психолог **Светлана Берцец** (Казан).

Цифра технологияләренең үсеш тизлегенә күз иярми, без тәүлекнең 24 сәгате буена онлайн режимга күчәргә дә мөмкинбез. Үзебез дә сизмәстән. Бу – киләчәк эше, әмма үткәннең ул киләчәккә гаять күп хәбәрләре бар әле. Мисал өчен, Ницше сүзләре: «Әгәр син упкынга озак вакытлар карап торасың икән, упкын үзе синә карый башлый».

ярдәм кулын сузучы юк, дигән сүз. Ә уенга бәйлелек (ул бүген искиткеч көчле масштаблар алып бара) гадәттә тирәлектәге хәлләргә каршы тору булаpак барлыкка килә – мәктәп, гаилә, дус-ишләр белән аралашуда нидер тәртиптә түгел ягъни.

– Иң гомуми профилактик киңәш – яшүсмернең тышкы дөнья белән бәйләнешләре булсын. Ул бәйләнешләр никадәр колачлырак булса, аралашыр кешеләре ни дәрәҗәдә күбрәк җыелса, бала бәйлелеккә бирешмәячәк. Аның тормышы болай да тулы канлы чөнки, – ди психотерапевт Анастасия Рубцова (Прага, Чехия). – Тирәлегең киңрәк булган саен бәйлелектән чыгу юллары да җиңелрәк табыла. Ләкин шунысы да бар: бөтен яшүсмерләр дә аралашырга атлыгып тормый, күбесенә яңа контактлар бик авыр бирелә. Иң зур кыенлык әнә шуннан килеп туа.

ЧИТ КЕШЕНЕҢ ТОРМЫШ ХРОНИКАСЫ

Инстаграм кулланудан нигә баш тартуы турында сорау биргәч, Варвара исемле бер танышым менә нинди тарих сөйләде: үткән җәйдә аның дус кызы су аттракционында төшкән фото белән видеоларны Инстаграмга урнаштырган. Фото, видеолар Казан янындагы бер ял базасында төшерелгән. Пост бик күп лайклар, шәрехләр җыйган, күпләр аттракционга киләчәкбез, дип, ымсынган. Варвара дустының үзен күреп сөйләшкәч таң кала. Дусты аңа аттракционның уртача булуын да, сервисның аксавын да сөйли, җитмәсә, өйрәнү вакытында кыйммәтле смартфоннары суга төшеп бата. Түгәрәкләп әйткәндә, яллары ял булмый. Диярлек. Әмма Инстаграмдагы модель буенча – барысы да комильфо!

– Мин үз вакытымны фейк-контентка әрәм итәргә теләмим. Мөһим яңалыклар турында иремнән, дусларымнан беләм. Алар белән турыдан-туры аралашырга яратам, очрашмаган чакта исә – телефоннан сөйләшеп. Вацаптагы төрле төркемнәрдә җыелган күпсанлы хәбәрләр дә чәчләремне үрә торырга мәҗбүр итә – алар, әйтерсең, таудан кубарылып төшкән кар өеме, – ди Варвара.

Күпләр өчен бу инде бүген мөмкин хәл булып тоелмаса да. Социаль челтәрләргә бәйсез рәвештә дә яшәп була. Тулы канлы итеп. Бу хәтта үсмерләр өчен дә – мөмкин хәл.

– Буш вакытларда без дуслар белән мәктәп янындагы спорт мәйданчыгына йөрибез. Баскетбол уйныйбыз, тренажерларда шөгыльләнәбез. Урамда тырай тибеп йөрү чорын уздык инде без, – ди 17 яшьлек Егор Морозов. Ул 111 нче санлы Казан мәктәбен тәмамларга җыена, киләчәккә планы – Санкт-Петербургтагы Кинематография институтына укырга керү. – Хәзерге вакытта мин «Архидети» уку-укыту проектын студиясендә фотография белән шөгыльләнәм. Минемчә, социаль челтәрләрдә утырмаганга карап, әллә ни күп нәрсә югалтмыйм, киресенчә, үземә кызыклы булган нәрсәләргә күбрәк өлгерәм.

Сүз уңаеннан, нәкъ менә Инстаграм – көн кадагындагы мәсьәлә. Британиянең иҗтимагый сәламәтлек

ИНСТАГРАМНАН БӘЙЛЕЛЕККӘ ЭЛӘКМӘС ӨЧЕН НӘРСӘ ЭШЛӘРГӘ КИРӘКЛЕГЕ ТУРЫНДА СВЕТЛАНА БЕРЦЕЦ КИҢӘШЛӘРЕ:

- Исегездә тотыгыз: тормышыгыз сез лентаны актарган арада көтеп тормаячак.
- Нинди дә булса публикация астына тәэсирләнеп, хисләнеп, лайк куйганчы, тирәнтен уйлап карагыз: сезгә бу кыйммәтләр чынлап та якынмы? Әллә сез манипуляциягә бирелеп кенә ошый, дисезме?
- Үзең ирешкәннәр – мөмкинлекләреңне бәяли торган төп критерий, корал әнә шул. Шулай ук – позитив пост өчен дә. ■


www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Татар Дөм-Дөме:
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
Реклама 16+

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Көзге «Керәшәләр» **КАЙЛАРГА** чакыра

Солдат өчен эш урыннары **КАЙДА** саклана

«Каз өмәсен» **КАЙДА** күрергә мөмкин

Иң тәмле табикмәкне **КЕМ** пешерә

КӨЗНЕҢ КЫЗУ ЧАГЫ. «КЕРӘШӘЛӘР» КИЛГӘН

Октябрь ахырында Казан күгендә очкан «Керәшәләр» бирегә кунакчыл шәһәрнең җылысын тоеп вә аны җылы якларга охшатып түгел, ә бәлки изге максат белән килделәр – авиация аслары МиГ-29 истребительләрендә Татарстанның яшь кешеләрен армиядә контракт буенча хезмәт итәргә чакырдылар.

Александр Ефремов фотолары

Агитацияне авиаторлар гына алып бармады. Булачак контрактчыларны заманча хәрби техника һәм хәрби форма белән таныштырдылар, җыр һәм биюләр, армиянең Үзәк спорт клубы спортчыларының мастер-класслары ярдәмендә күңелләрен күтәрделәр, тагын әле кыр кухнясында пешерелгән чын солдат боткасы хәстәрләп тә сыйладылар. Тамак ялгап алган һәм кызыксынган егетләрне контракт белән хәрби хезмәткә сайлау буенча мобиль пунктларда һәм шулай ук һава-космос көчләре һәм җәяүле гаскәрләрнең хәрби уку йортлары мәгълүмат пунктларында көтәләр иде.

Гомумән, хәрбиләр бәйрәмгә ихлас күңелдән әзерләнгән иде, шуңа да ул бик җылы булып чыкты. Татарстан Республикасының хәрби комиссары генерал-майор Сергей Погодин әйтүенә караганда:

– Хезмәт итү – ул безнең тормыш рәвеше. Күп кенә контрактчылар сроклары тәмамлангач та алга таба хезмәт итәргә калалар, яңа контракт төзиләр. Һәрхәлдә, бу инде – күңел кушуы буенча. Россиядә яклаучыга һәрвакыт ихтирам белән караганнар. Илебезнең бик бай тарихы бар һәм, билгеле инде, бу безнең яшьләргә тәэсир итмичә калмый.

Яшьләр моны чын күңелдән аңлап, үзенекен сайлый – армиягә җыена. Ә инде яшь булмаганнарга, «Керәшәләр» очышын сокланып күзәтеп, үтеп киткән елларын һәм югалткан мөмкинлекләрен кызганырга гына кала.

Военная служба по контракту – твой выбор!



УРЫННЫҢ САКЛАНУ ЗАКОНЫ

Армиягә алалармы? Бер ел хезмәт иткән арада эшеңне югалтудан куркасыңмы? Ихтимал, якын киләчәктә мондый курку өчен сәбәп булмас. Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов чакырылыштагы егетләр өчен эш урыннарын саклау мәсьәләсен карарга күрсәтмә бирде.

Автор:
Алсу Троицкая

ГОМЕРНЕҢ БЕР ЕЛЫН ҖИЛГӘ ОЧЫРЫРГАМЫ?

Аның тарихы кагыйдәдән чыгарма түгел. Бәлки, киресенчәдер дә әле. Сөйләшә башлаганда Азат Исмәгыйлов берникадәр уңайсызлана да төште:

– Минем кебекләр илдә меңәрләгән ул. Гаҗәпләнерлек хәл юк монда. Мәктәптән соң вузга кердем. Өчлеләрсез тәмамладым, перспективалы фирмага яхшы гына хезмәт хакына эшкә урнаштым. Ә аннары хәрби комиссариаттан чакыру килде. Армиядә хезмәт итүдән качып тормадым. Югыйсә, дусларым да, әти-әнием дә: «Бер ел гомереңне җилгә очырачаксың», – дип тукыдылар. Бәлки аларны тыңларга кирәк булгандыр?

Ул эштән китүдән курыкмаган. Анда, хезмәт итеп кайткач, Азатны һичшиксез яңадан алырга вәгъдә иткәннәр. Алмаганнар... Аның урынында инде ун айга якын башка кеше эшли икән.

Эш эзли башлаган. Тапкан да – берне генә түгел, хәтта бишне үк. Теләгәнеңне сайла гына! Әмма аларның берсе дә элеккесе белән чагыштырырлык түгел – хезмәт хакы ягыннан да, профессиональ кызыклылыгы ягыннан да... Бүгенге көндә, армиядән соң эш эзләп күп айларын үткәргәнгә күрә, республика Президентының башлангычын бишкуллап яклый.

– Минемчә, хәрби бурычларын үтәгән егетләр хезмәттән соң үз карьераларын эзлекле рәвештә дәвам итү мөмкинлегенә исәп то-



Александр Ефремов фотолары

тарга хокуклы. Ә яңа вакансияләр эзләп интегер хәлгә куярга тиеш түгелләр аларны...

ОЗАК ЭШ, СОРАУЛАРЫ ДА КҮП

Җәй көне Россия Федерациясенең Дәүләт Думасында булачак солдатлар өчен, армия сафларыннан кайтканнан соң өч ай дәвамында, үзләренең элекке эш урыннарына кайту хокукын гарантияли торган закон проектын эшли башладылар. Әлегә элеккеге солдатлар өчен закон белән төгәл ныгытылган мондый мөмкинлек юк (әгәр алар дәүләт оешмаларыннан чакырылмаган булса). Барысы да эш бирүченең ихтыярыннан тора.

Моңа кадәр «Хәрби хезмәттәгеләр статусы турында»гы 1998 елның 27 маендагы ФЗ-76 номерлы Федераль законның 23 нче маддәсендәге 5 нче өлешенә һәм РФ Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертүгә омтылышлар булган иде инде. Әмма җаваппларга караганда, сораулар күбрәк булып чыкты. Әгәр чакырылучы армиягә кадәр ялкау булса, армиядән соң мондый «хезмәткәр» нигә кирәк? Яки ул хезмәт иткән арада предприятиедә аның эш урынын кыскарткан булсалар? Мондый очракта аның эш бирүче белән бәхәсен ничек көйләргә? Хәрби хезмәттән кайтучының эш урынын саклау өчен ниндидер шартлар куярга һәм моны

2018 елның көзендә армиягә чакырылган һәм югары, урта һөнәри белеме булган гражданнар турында мәгълүмат

– Ир-ат Ватан алдындагы бурычын үтәргә, үзен һәм якыннарын якларга өйрәнергә тиеш, – дип саный Михаил Бурняшев.

аның хәрби хезмәттәге намуслылыгы белән бәйләп карарга кирәкме?

1 октябрьдән көзге чакырылыш кампаниясе башланды. Хәрби көчләргә республикадан ел ахырына кадәр 3500 гә якын кеше армиягә хезмәт итәргә китәчәге билгеле инде, шул исәптән 800 гә якыны югары белемле яшьләр. Казандагы ТЭЦ-3 тә электр җиһазларына хезмәт күрсәтү буенча электромонтёр булып эшләгән Михаил Бурняшев белән без чакырылыш алдыннан очраштык. Энергетикага ул әтисе эзләре буенча киткән. Казан энергетика колледжын тәмамлаган, Казан дәүләт энергетика университетына укырга кергән. Югары уку йортында уку вакытына кичегү мөмкинлеге алып, көндезге бүлектә бер курсны тәмамлаган, укуын уңышлы рәвештә эш белән бәйләп алып барган. Соңыннан армиягә барырга карар кылган. Бу карарын әти-әнисе дә хуплаган.

– Ир-ат Ватан алдындагы бурычын үтәргә, үзен һәм якыннарын якларга өйрәнергә тиеш, – дип са-

“ – Армиядән соң мин хокук саклау органнарында яисә, барып чыкса, көч структураларында эшләргә телим. Матур сүзләр кебек кенә тоелса да, илебез иминлеге хакына хезмәтемне дәвам итәргә ниятлим, – җыючы-клёпкалаучы Александр Лазарев белән «Туполев» ГАҖ филиалы – С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводына керү урынында очрашуыбыз аның әнә шул сүзләре белән башланып китте.

ный Михаил. – Хәзер гомумән яшьләр арасында армиядән качып йөрү гадәте юк. Һәрхәлдә, минем дусларымның күпчелеге хәрби хезмәткә барырга ниятли. Минемчә, һәркем бу тормыш мәктәбен үтәргә тиеш.

– Армиядән соң мин хокук саклау органнарында яисә, барып чыкса, көч структураларында эшләргә телим. Матур сүзләр кебек кенә тоелса да, илебез иминлеге хакына хезмәтемне дәвам итәргә ниятлим, – җыючы-клёпкалаучы Александр Лазарев белән «Туполев» ГАҖ филиалы – С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводына керү урынында очрашуыбыз аның әнә шул сүзләре белән башланып китте. Александр инде язгы чакырылышта ук армиягә китәргә теләгән, тик сәламәтлеге буенча үтмәгән. Хәзер, бәхетенә, барысы да яхшы. Ул теләсә кайсы ир кеше көчле булырга омтылырга һәм үз гамәлләре өчен җавап бирергә өйрәнергә тиеш дип исәпли:

– Армиядән соң минем тормышым ничек үзгәрер, белмим, тик ул ел минем өчен кай ягы беләндер хәлиткеч булыр дип ышанам.

– Армиядән соң минем тормышым ничек үзгәрер, белмим, тик ул ел минем өчен кай ягы беләндер хәлиткеч булыр дип ышанам, – ди Александр Лазарев.

Михаил һәм Александр кебекләр торган саен арта бара. Егетләр армиягә аңлы рәвештә баралар. Һичшиксез, яшь кешенең армиядә хезмәт иткән булуы аңа эшкә кергәндә өстенлекләр бирә. Чөнки бу егет бер ел элек, әти-әни-әби янындагы уңайлы, рәхәт тормышны калдырып, ихтыярын бер йодрыкка туплый алган. Моннан тыш, армия үзенә ышанычны арттыра, ниндидер ирек бирә – иңнәреңдә шундый тәҗрибә булгач, син каядыр китә, карьераңны, әйтик, Татарстаннан тыш башка җирдә дә башлый аласың. Әмма яшь, ныклы һәм башлы егетләрнең кире кайтырга теләмәүләре республика өчен яхшыдырмы – монысы башка мәсьәлә. Ә инде Татарстанда армиягә чакырылучыларның эш урыннарын саклау мәсьәләсен хәл итү буенча хөкүмәтнең эшче төркеме эшли башлаган икән, бу өмет уята: ихтимал, туган төбәкләренә әйләнеп кайту файдасына булган аргументлар егетләр тарафыннан бәхәссез кабул ителер.

ХЕЗМӘТТӘШЛЕК МЕХАНИЗМЫН ЭЗЛӘГӘНДӘ...

Ләйлә Фазлыева,
ТР Премьер-министры урынбасары:

– Хөкүмәт эшче төркеменең бурычы – хәрби хезмәттән кайткан гражданнар белән эшкә урнашу сораулары буенча эшләү барышында төгәл ведомствоара эшчәнлекне тәэмин итү. Эшче төркем составына Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты, Профсоюзлар федерациясе, Эш бирүчеләр берләшмәләренең Координацион советы вәкилләре, муниципаль чакырылыш комиссияләре, муниципаль районнарның мәшгульлек үзәкләре җитәкчеләре һәм Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча вәкил керә.

«ТОРМЫШНЫ АЛГА ТАБА ДА ТӨЗЕР ӨЧЕН»

Сергей Погодин,
Татарстан Республикасының хәрби комиссары:

– «Хәрби хезмәттәгеләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы ФЗ-76 номерлы Федераль законның 23 нче маддәсенә туры китерелгәнчә, чакырылышка кадәр дәүләт оешмаларында эшләгән гражданнарның хәрби хезмәттән азат ителгәннән соң өч ай дәвамында шул ук оешмаларга эшкә керү хокукы саклана. Чакырылышка кадәргедән түбәнрәк булмаган вазыйфага. Республика Президенты безнең алга шундый бурыч куйды: бездә чакырылышка кадәр эшләгән күпме егетнең хезмәт итүен ачыкларга. Тагын шундый бурыч та бар: барысын да, әйләнеп кайткан чакта, үз эш урыннары көтсен. Хәзерге вакытта Татарстанда чакырылышка кадәр эшкә урнашканнар категориясенә 1 427 кеше туры килә. Алардан 107 егет армиядә хезмәт иткәнче федераль (муниципаль) хезмәттә булган, 1320 се бизнеста эшләгән.

Татарстанда, хезмәт иткән вакытларында эш урыннарын саклап калу юлы белән, булачак солдатларга ярдәм итү чараларын эшләү буенча эшче төркем булдырылды. Республиканың Хәрби комиссариаты вәкилләре дә аның составына керә. Билгеле инде, егетләр хезмәт итәргә китте, һәм алар үзләрен көткәннәрен төгәл белергә тиеш. Аларны – әти-әниләре, кәләшләре һәм үзләренең эш урыннары көтә. Тормышны алга таба да төзер өчен иң мөһиме шул.

БОРЫНГЫДАН КИЛГӘН ГАДӘТ

Фотолар: Солтан Исхаков

Авылларда каз өмәсе гөрләгән чак. Гаҗәп һәм шул ук вакытта сөенечле хәл: каз өмәсе һаман да йола буларак яши әле, димәк. Соңгы елларда район-авылларда бөтен шартын туры китереп оештырылган каз өмәләрендә булырга туры килде. Каз асрау, безнең халык өчен бу кошның дәрәҗәсе, бәһасе хакында да язарга кирәк дип таптык. Каклаган каз – бездә иң зур сыйларның берсе бит.

Автор:
Руфия Фазылова

«КАЗ АЛМЫЙЧА КАЛГАН ЮК»

Төрле авыл, районнарда редакциябезнең җанатарлары бар. Сәфәргә баргач, дуслашып кайтабыз чөнки. Язын Яшел Үзән районының Олы Ачасыр авылында мөлаем, бик тырыш авыл апалары белән танышкан идек. «Тагын күрешергә язсын», – дип саубуллашып кайтып киттек. Һәм менә күрешергә тагын җай чыкты – каз өмәсенә чакырдылар. Дуслар чакырган җиргә бармый калу мөмкинмени?!

Олы Ачасыр – Яшел Үзән районының атаклы авылы. Буа – Казан поездына чиләк-көянтә белән килеп, башкалага катык-сөт сатарга килүче апаларны күпләр хәтерлидер. Бүген халык алай чиләк-көянтә күтәреп Казанга йөрми инде. Беренчедән, апалар картайган, икенчедән, заманы бүтән.

Сүз башы бит каз өмәсе иде. Аны, бөтен шартын туры китереп, Кадрия апа Гарәфетдинова үткәрде. Хуҗабикә һәр нәрсәне алдан оештырган: берәү казларны тота, улы белән кияве суеп тора, ике хатын-кыз түшкәләрне үтүкли, ә мунча эчендә дүрт-биш хатын-кыз аларны йолкый... Хәтта мөнәҗәтләр укырга да аерым кеше бар иде. Мин исә барысын да күзәтеп, сораулар биреп, теркәп тордым.

– Элек безнең әниләр казны йолкыганчы мичкә тыгып ала иде, – дип сөйләде хуҗабикәнең күршесе Сания апа. – Хәзер алай эшләмибез, үтүклибез генә. Бик җайлы. Кайбер җирләрдә каз түшкәләрен башта суга тыгалар, тик алай эшләсәң, аның мамыгы юешләнә. Мамыкны киптерү тагын бер эш була.

– Каз мамыгын нишләтәсез? – дим.

– Җыеп йөриләр, тапшырабыз. Хәзер бит йон мендәрләрдә йокламыйлар. Аллергия, дип, балаларны да йоклатмыйлар...

Өч сәгать дигәндә, 20 казның эшен бетерделәр. Һәм ул шундый тиз, күңелле үтте ки, бер мизгел кебек кенә тоелды. Ә Кадрия апа, чын хуҗабикәләрчә, эшне тәртипкә салып, йөреп кенә торды: «Гүзәл, үтүкләп бетергәч, казның баш-аякларын чистарта тор...», «Сания, әйдә, җайлырак итеп утыр әле...», «Эчәсегез килмиме?..»

Каз өмәсенә Кадрия апа иң якыннарын гына җыйган – ике кызы, килене, кодагые, күршеләре, үзе белән бергә «Зөбәрҗәт» ансамбленә йөрүче хатын-кызларның берничәсе. (Олы Ачасырда өч ел элек «Зөбәрҗәт» җыр ансамбле оештырганнар. Анда авылның сигез хатын-кызы җырлый.)

Кызларыбыз җырлый-җырлый каз йолкыган арада гармунчы егет тә килеп җитте. (Үзен шулай дип таныштырды.) Әллә гармунны, әллә Әнвәр абыйны күреп, хатын-кызлар тагын да моңлырак җырларга кереште. Аннан, каз түшкәләрен көянтәгә асып, чишмә буена кузгалдылар. Монысы тагын бер манзара булды: юлда очраган һәркем тизрәк кесәсеннән телефон алып, казлар аскан кызларны төшерә башлады. Гаҗәп тә түгел: авылда мондый күренешкә көн саен юлыкмыйсың! Кызлар исә, каз түшкәләрен тотып, әле камераның берсенә, әле икенчесенә елмайды. Шулай итеп, борынгы йолага заман төсмере өстәлде.

Арттан килгән Кадрия апа каз каурыйларын чишмә буена чәчә барды...

– Ырымы шундый, – диде хуҗабикә. – Быел 20 бәбкә сатып алган идем, Аллага шөкер, барысы да үсте. Каурыйларның да «шифасы» тигән дип уйлыйм, су буена чәчкәч, киләсе елга да бәбкәләр була, үсеп җитә, дигән ышану бар.

– Түшкәләрне юарга бөтен кеше чишмә буена төшәме? – дим.

– Әйе, без хәтта бозау суйгач та, чишмә буена төшәбез. Электән шулай килгән, эчәгеләрне юып, эшен бетереп кайтасың.

– Элек өйләргә су кермәгән иде, шуңа да бөтен кеше дә чишмә буена төшкән. Хәзер бит һәр йортта су бар, – дим.

– Булса да, чишмәгә төшәбез. Өйдә кысынкырак, чишмә буенда җайлырак. Бездә бит чишмәләр күп, барысын да карап, тәртипләп торалар.

Кадрия апаның Олы Ачасырга килен булып төшкәненә 34 ел тулган. Төп йортта каената, каенана белән яшәгән. Ул белгәннән бирле бу нигездә каз асрыйлар. «Бер генә ел да каз алмыйча калган юк», – диде Кадрия апа. Зурлап, бөтен шартын китереп, каз өмәсе үткәрүе икенче тапкыр гына икән.

– Каз йолкырга балалар да кайта, күршеләрне дә чакырасың, – дип сөйләде Кадрия апа. – Түшкәләрне юарга чишмә буена да төшәсең. Каз йолкучыларга тәм-томын, бер казны да пешерәсең. Гомер буе шулай итәбез. Тик бүгенгә кебек бәйрәм формасында түгел, гадирәк уза иде ул. Бүген тәмам бәйрәм ясадык бит. Кызларга рәхмәт, булдырдылар!

Хатын-кызлар чишмә буеннан кайтканчы табын инде әзер иде. Иң төп сый – әлбәттә, яңа гына суелган, мичтән чыккан каз. Табын артында янә җыр, уен-көлке, рәхмәт сүзләре ишетелде...

ТЕАТРГА ӘЙЛӘНГӘН ГАДӘТ

Бүген каз өмәләрен театральләштереп үткәрү бик популяр. Күп районнарда махсус шундый конкурслар уйлап чыгарганнар: зоналарга бүленеп, авыл мәдәният йортларында каз өмәләре уза. Авылның иң уңган хуҗабикәләре бәйрәмгә каз каклап алып килә, милли киемле егет-кызлар сәхнәдә җырлый, бии, уйный... Аннан зона буенча җиңүчеләрне ачыклап, аларны район мәдәният йортына чакыралар. Шулай итеп төбәкнең иң уңган хуҗабикәсен, иң җор телле коллективын ачыклыйлар.

Каз өмәсе – борынгы йола, дибез. Элек ничек узган соң ул? Бу хакта Традицион мәдәниятне үстерү үзәге җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты Фәнзилә Җәүһәрова белән сөйләштек.

– Сакланып килгән традицияләр арасында безнең өмәләр системасы бар, – диде Фәнзилә ханым. – Шулар арасында иң киң таралганы, популяры – каз өмәсе. Күпләр аны «йола» дип атый. Ләкин бу очракта әлеге сүз бик үк туры килеп бетми, «гадәт», дисәк, дөресрәк булыр. Исем кушу, килен төшерү – менә алары йола. Гадәт – тотрыклы күренеш түгел. Ул, ниндидер шартларга бәйле рәвештә, үзгәрүчән була. Без аны, ничек кенә тырышсак та, аерым бер заманга бәйләп куя алмыйбыз. Һәр заманның үз гадәтләре бар. Мисал өчен, бүген күп авылларда июнь аенда уңган хуҗабикәләрнең беренче партия тавык-чебешләре өлгереп җитә. Һәм чебиләр йолкырга да кеше чакыралар, чөнки аны аның эшен бер көнне бетерсәң, җайлырак. Менә бу – өмәләр традициясе.

Каз өмәләренең хәзер вакыты күчте. 60–70 нче елларда ноябрь башында инде кар ята иде. Каз өмәләре нәкъ шул вакытка туры килде. Халык, берьюлы күмәкләшеп, үстергән казларын тиз генә суеп, урнаштыруны ка-

Бөтен шартын туры китереп, Кадрия апа Гарәфетдинова (уртада) каз өмәсе үткәрде.

Гармунчы Әнвәр абзый.

рады. Каз, гомумән, безнең татар өчен төп ризыкларның берсе: кыз бирсә дә, зурлап кунак җыйса да, хәтта печән өстенә дип тә махсус каз каклап куйганнар. Каз ул – кунакка карата булган кадер-хөрмәт, дәрәҗә...

Фәнзилә Хәкимовна белән сөйләшеп утырган арада минем дә балачактагы хатирәләр яңарды. Җәен, чорма башына менеп, кәгазьгә төрелгән каклаган казларны санап: «Кайчан дәү әни боларны ачар икән?» – дип көтеп йөрисең. Әтиемнең әнисе аларны аеруча тәмле итеп каклый иде. Шунысын да әйтергә кирәк: ул чорларда бүгенге кебек зур-зур туңдыргычлар юк бит. Көннәр суыткач, кош-кортларны суеп куялар да язга кадәр келәт кебек җиргә кертеп асалар. Бүген исә декабрь азагында да ит тышта җебеп утырырга мөмкин. «Әле ярый зур туңдыргычлар бар», – дип сөенеп куясың...

– Ул заманнарда һава торышы да әйтерсең кешеләргә илтифат күрсәткән, – ди Фәнзилә апа да. – Көннәр бер суыткач, бүгенге кебек кире җебетми иде. Хәзер климат үзгәреп бара. Ни өчен каз өмәләре ноябрь башында узган? Казларны йолкып эшкәртер өчен вакыт кирәк. Белгәнебезчә, дистә еллардан бирле ноябрь башында октябрь бәйрәмнәре уза, ягъни халык ял итә. Димәк, эш эшләргә дә вакыты була. Каз өмәләре тәмамланганнан соң, мөгезле эре терлекне суеп, эшен бетерәләр. Авыл кешесе кышка тынычлап, муллыкка туенып керә.

Татарда һәр күренешне махсус исем-атама белән атыйлар. «Аллага шөкер, казларны эшкәртеп туңдыргычка аттык», – димиләр. «Шөкер, урнаштырдык», – диләр.

Минем тагын бер нәрсәгә игътибарны юнәлтеп узасым килә: бүген һәр нәрсәнең үз бәясе бар. Кош-кортларга ашлык мәсьәләсен күздә тотам. Элек мал-туар асрау, каз, тавык-чеби үстерү бүгенге кебек чыгымлы түгел иде. Иген колхоз амбарыннан хуҗалыкларга машиналап кайтты, эш көненә дә бирәләр, болай да. Бүген исә игеннең һәр килосы исәптә, чөнки аны сатып алалар. Авыл кешесе игеннең бәясен белә: ярты капчык икмәгең калган икән, ике көн ашатырга ризык бар, дигән сүз. Кош-кортларны вакытында суймасаң, иген сатып аласы була.

«ЙОРТ ХУҖАСЫ»

Казны сую вакыты үзгәргән кебек, бүген аларны үстерү рәвеше дә үзгәрде. Авылдан чыккан һәркем хәтерлидер: көннәр язга таба авышып, җылыта башлауга, өйдә «хуҗа» барлыкка килә – ана каз. Әле берәү генә дә түгел. Ул өйгә кергәч, бала-чагага йөгереп йөрмәскә кушыла, «хуҗа»ны борчымаска кирәк. Ялгыш онытылып китеп, аягыңны караватт өстендә тибрәтеп утыра башласаң, «шалт», ана каз шунда ук эләктереп ала. Фәнзилә Хәкимовна да ул хакта бик тәмләп сөйләде:

– Безнең балачак, үсмер чаклар казлы дәвергә туры килде. Аның тәртибе болай иде: бер ояөч ана казга бер ата каз калдыралар. Көннәр җылыта башлагач, ата казга аерым тәрбия күрсәтәләр: тәм-томнар бирәләр. Яңасе, шулай итсәң, йомыркалар аталанган була. Ана каз йомыркалар өстенә утыргач, игътибар аңа күчә. Шулай итеп утыз көн дәвамында хуҗабикә могҗиза, ягъни бәбкәләрнең чыкканын көтә. Кыш буе дүрт каз асрап чыгу хуҗа өчен – шактый чыгымлы эш. Шуңа да кайбер кешеләр ана каз гына калдыра. Ә аннан язга таба ана казын «кунакка» ата казлы йортка илтеп тора. Бу кадәр тырышып та бәбкәләр чыкмаса, бик кызганыч, әлбәттә. Ләкин төрле чаклар була иде.

Бүген бу гадәт тә үткәндә калды. Хәзер инде беренче яшел чирәм шытып чыккач, анасы белән йөргән сап-сары бәбкәләрне бик очратмыйсың. Халык бәбкәләрне сатып кына ала. Әле анда да зуррагына өстенлек бирәләр, мәшәкате булмасын, дип...

– Элек бер хуҗалыкта йөз, йөз илле баш каз бәбкәсе асрау мөмкин хәл түгел иде, – дип сүзен дәвам итте Фәнзилә ханым. – Чөнки казлар аның кадәр бәбкә чыгармый, берничә оя булса гына. Тик кышка унлап каз калдырмыйсың инде. Элек аны хуҗалыкларда хуҗалар үзләре, якыннары ашар өчен асраган. Бүген исә каз үстерүне бизнес иткән кешеләр дә шактый. Мин моның начарлыгын күрмим, киресенчә, бик әйбәт. Заман үзгәрсә дә, казга ихтыяҗ, мәхәббәт кимеми. Шунысы сөенечле. Каз бит ул – чын-чын татар ризыгы...

Фәнзилә Җәүһәрова – Кукмара кызы. Туган авылында бик күп тапкырлар каз өмәсендә катнашкан. Ул вакытларны менә ничек искә алды ул:

– Каз йолкырга һәркемне чакырмыйлар иде. Үткен, эшкә булган кызларны гына әртилгә алалар. Без исә, биш-алты кыз, алдан сөйләшенгән исемлек буенча, өмәгә йөрибез. Әртил ел саен үзгәреп тора, өлкәнрәк кызлар кияүгә чыгып китә, яшьрәкләр кушыла. Каз йолкуның барлык нечкәлекләрен яңа килгән кызга аңлатасың. Бер казны чистартып, эчен алгач, хуҗабикә каз маен эретеп, коймак пешерә тора. Аннан кызларны чәйгә чакыра. Эш беткәч, (казны мунчада йолкыйлар), яңадан өйгә керәсең. Анда инде кайнар шулпа ашыйсың, тәм-томнар белән чәй эчәсең. Тамак ялгагач, түшкәләрне юарга чишмә буена төшәсең. Кичен тагын шул йортка җыеласың. Хуҗабикә инде тәмле итеп каз пешергән була, төрледәнтөрле ризык әзерли. Уен-көлкеле (кызның йөргән егете булса, ул да килә), күңелле мәҗлес була. Безнең якларда каз өмәләре хәзер дә уза. Әлбәттә, заман үзгәрү белән табынга чыгарыла торган ризыклар да төрләнә. Ә асылы шул: каз үскән, эше беткән, инде күңелле итеп бәйрәм итсәң дә ярый.

...Татар авыллары булганда, каз өмәләре югалмас. Монысына шик юк. Гадәтме, йоламы, ничек аталуы халыкка әллә ни мөһим түгел, иң әһәмиятлесе – кешеләрне берләштерүче, очраштыручы бер мәҗлес, чара ул. Менә шунысы кыйммәтле аның.

«КӨН ДӘ ӨМӘ!»

Марат Гыйбадуллин, Әлки районы Яңа Чаллы авылы:
– Ун ел инде: мең баш каз алып үстерәбез. Ульяновск өлкәсеннән китереп бирәләр. Без 40–45 көнлек бәбкәләрне алабыз, үстерергә җиңелрәк. Быел бер бәбкәне 380 сумнан сатып алдык, узган ел 360 сум иде. Үзебезнең 4 гектар җиребез бар, шунда ясалма күл ясаттык. Кошлар чыгып китмәсен өчен кырыйларын тотып алдык. Төнгә бер каравылчы сакта тора. Төлкеләр күп, явыз ниятле кешеләр дә булырга мөмкин, шуңа күрә казларны сакламый мөмкин түгел.
Файдасы, әлбәттә, бар. Булмаса, асрамас идек. Саннарда исәпләгәндә, бәбкәне 380 сумга сатып алсак, чистартылган түшкәне 1400–1500 сумга сатабыз. Инде казларны суя башладык, ярминкәләргә йөрибез. Бер көнгә 50 ләп каз суела, эшкәртергә кеше чакырабыз. Көн дә өмә бездә! Бер хатын-кыз унлап каз чистарта. Шуның өчен аларга казларның эч-башын, маен биреп җибәрәбез, акча да өстибез. Каз йолкырга кеше табылып тора, проблема юк. Авылда хатын-кызлар күп бит!

ТАТАРСТАН
ВЕСТНИК

Редакция кухнясы

«Татарстан» журналы өчен МАХСУС

ТАБИКМӘК – ТАБЫН ЯМЕ...

Аш-су әзерләгәндә, кайбер хуҗабикәләргә аеруча сокланып, пешергән ризыгына ис китеп кайта. Апас районының Кече Болгаер авылына баргач та, шундыйрак хис-тойгылар кичердек. Редакциябез кунагы – Зәйтүнә апа Закирова. Фәкать ул якларга гына хас булган рецепт белән табикмәк әзерләде ул.

«ӘНИ «ЛАЙК»ЛАРНЫ МИННӘН КҮБРӘК ҖЫЯ»

Табикмәкне төрле якларда төрлечә атыйлар. Балтач ягында ул – бәрәңге пәрәмәче, Азнакай ягында – дучмак, дурычмак. Апаста исә табикмәк дип атала икән. Ни өчен икән, дим, чөнки мин үзем дә Апас ягыннан. Тик бездә бу ризыкны пешерү түгел, белмиләр дә. Бактың исә, табикмәкне Кама Тамагы, Тәтеш районнарында яратып әзерлиләр булып чыкты. Кече Болгаерның әлеге районнарга орынып торганын исәпкә алсак, гаҗәпләнәсе юк. (Алай гына да түгел, 1932 елга кадәр авыл Тәтеш районына кергән.)

Зәйтүнә апа – Инстаграм йолдызы. Кызы – журналист, язучы Гөлүсә Закирова әнисенең мичтә табикмәк пешерүен төшереп, Интернетка да куйган. Санаулы көннәр эчендә видео 40 меңгә кадәр карау җыйган.

– Иң кызыгы шул: әнинең табикмәк пешерүен Инстаграмга куйган саен видео әллә никадәр «лайк» җыя, – ди Гөлүсә Закирова. – Белмим, кеше учакта пешкән ризык булуына кызыгып карыймы, әнигәме, тик элгән башка видеоларымны аның кадәр күп карамыйлар.

Сөйкемле шул Зәйтүнә апа. Гадилеге, самимилеге белән үзенә тарта. Тормыш иптәше Рәүф абый белән алты бала тәрбияләп үстергәннәр. Тик берсе фаҗигале рәвештә вафат булган. Хуҗабикәгә киләсе елда 70 яшь тула.

– Без ятим үскән балалар, – диде Зәйтүнә апа, тормышы белән кызыксынгач. – Әти мин тугач үлгән. Әни дә әллә ни озак яшәмәгән – миңа дүрт яшь тулгач, вафат булган. Берсеннән-берсе кечкенә дүрт бала калганбыз. Сугыштан соңгы авыр заманнар – 1949 ел. Урыны җәннәттә булсын, безне ачлыктан, ялангачлыктан алып калган кеше – әтинең сеңлесе Миңнегөл апа. Кияүгә чыкмаган яшь кыз була ул. Курыкмыйча дүрт баланы үз өстенә алган бит. Аның тырышлыгы, мәхәббәте саклады: без ятимлек ачысын татымадык. Ул безне эшкә дә өйрәтте, тәрбия дә бирде. Кызганыч, дүрт туган арасыннан мин генә исән инде хәзер.

– Миңлегөл апа исән түгелме? – дим.

– Юк, вафат, житмеш бергә кадәр яшәде. Аның язмышы гаҗәеп. Безне үстереп, тормышка озаткач, хатыны үлгән иргә кияүгә чыкты. Сигез бала өстенә килде. Аларны да безнең кебек кадерләп үстерде. Ул балалар Миңнегөл апаны бик җылы итеп искә алалар. Иң мөһиме – кырык яшендә ул үзе дә кыз бала тапты. Ятим балаларны сыендырган өчен Аллаһы Тәгалә аңа әҗерен бирде: мул, әйбәт тормышта яшәде. Унөч баласы да гомер буе хәлен белеп торды...

«МИЧНЕ СҮТТЕРМИМ!»

Кече Болгаер авылында мич өч кенә йортта калган. Шуларның берсе – Закировлар гаиләсендә. Зәйтүнә апаның горурлыгы ул мич.

– Бүген кешене әллә нәрсә белән шаккатырып булмый, ә менә мичтә пешкән камыр ризыгы һәркемгә тансык. Балалар кайтасы булса, тизрәк камыр куям: мич коймагы, катлама пешереп алам. Мактый-мактый ашыйлар. «Мондыйны

Автор:
Руфия Фазылова

ЗӘЙТҮНӘ ЗАКИРОВАДАН ТАБИКМӘК РЕЦЕПТЫ:

Кирәк булачак:
1. Су – 1 стакан
2. Йомырка – 2 данә
3. Шикәр комы – 2–3 аш кашыгы
4. Сыек май – 0,5 стакан
5. Он – 0,5 кг
6. Юеш чүпрә – 50 г
7. Тоз – тәменчә

Эчлек:
1. Бәрәңге – 1 кг
2. Сөт – 1 стакан
3. Сыер мае – 100 г
4. Йомырка – 3 данә

Фото: Лилиана Вәлитова

бүтән берәү дә пешерә алмый», – диләр. Югыйсә камыр ризыгының бөтен сере – ялкында, мичтә пешүдә. Шуңа да исән чагымда мичне сүттермәячәкмен.

Табикмәкнең камыры бик җиңел әзерләнә икән. Җылы суга сыек май, күкәй, шикәр комы, тоз саласың да яхшылап болгатасың. Аннан юеш чүпрә өстәп, камыр басасың.

– Элек камырны сөткә баса идек, – диде Зәйтүнә апа. – Хәзер суга эшлибез. Сыек майны күбрәк салгач, камыр бик тәмле була, кетердәп тора.

– Юка камырына охшамаган икән, – дим аш-су остасына.

– Юка бит ул икенче ризык. Каймак, май белән әзерләнә. Аны күбрәк чәй табыннарына чыгаралар. Ә табикмәк туклыклы, тамак туйдыра торган ризык. Әгәр аның камырын юка шикелле йомшак итсәк, бәрәңгене тотып тора алмас иде. Монда бит төп хикмәт – өстенә ягылган бәрәңгедә.

– Камыр тиз кабара, – дип эшен дәвам итте Зәйтүнә апа. – Өстен тастымал белән ябып, җылы урынга куеп торабыз да, бер сәгать дигәндә әзер дә була.

Ул арада бәрәңге пешеп чыкты. Зәйтүнә апа аны газ плитәсеннән алып, суын түкте. Аннан төйде. Һәм бәрәңгегә сөт, эретелгән сыер мае салып болгатты. Янә өч күкәй сытты.

– Кемдер пешкән юка өстенә бәрәңге җәйгәч, йомырка сарысы белән майлый, – ди Зәйтүнә апа. – Мин алай эшләмим. Йомырка бәрәңгенең эчендә бар бит, шул җитә. Ялкында ул күпереп, ялтырап китә.

АТАКЛЫ ДИРЕКТОР

Камыр кабарган арада, дип, Закировларның күршеләрендә генә яшәүче авылның хөрмәтле кешесе – Илдар абый Миңнебаев янына кереп чыктык. Егерме алты ел Кече Болгаер мәктәбендә директор вазыйфасын башкарган ул. 2015 елда Илдар абый эшеннән киткән, һәм мәктәп тә ябылган. Югыйсә уку йортында 40 укучы белем алган әле ул чакта.

– Лаеклы ялга чыктым да эштән китәргә дигән карарга килдем, – диде Илдар абый. – Безнең балалар хәзер күрше авылга – Борнаш урта мәктәбенә йөреп укый. Укытучылар коллективы бик көчле иде, алар да Борнаш мәктәбенә китте.

– Эштән китмәгән булсагыз, мәктәп тә ябылмас иде, – дим Илдар абыйга. (Бу атаклы директорны районда яхшы беләләр, санлыйлар.)

– Бәлки... Тик икенче кызыксынуларым барлыкка килде. Мин хәзер Буа мәдрәсәсендә укыйм, дин гыйлеме алам. Безнең Кече Болгаер атаклы авыл булса да, аңа игътибар аз, җитәкчеләр тарафыннан, диюем. Хәер, халык та авыл өчен бик янып тормый. Шул ук мәктәпне япканда бер ата-ана да каршы чыкмады. Ә бит мәктәптә Татарстан Республикасының ике атказанган укытучысы, биш «Россия Федерациясе халык мәгарифе отличнигы» күкрәк билгесе алган һәм башка дәрәҗәле исемнәре булган мөгаллимнәр эшли иде. Район, республика күләмендәге Олимпиада, ярышларда җиңгән укучыларыбыз бар. Аннан да бигрәк, мәктәп булмау авылны ятим итте. Сөйләсәң күп инде... Шуңа гына сөенәм: безнең мәктәптә эшләгән талантлы укытучылар бүген дә балаларга белем бирә. Берсе дә эшсез калмады. Аралашып торабыз. Коллективны, мәктәпне сагыналар...

Әйе, Кече Болгаерның мәктәбе бүген ятим булып моңсу гына утырып тора. Ул нәкъ Зәйтүнә апа Закировалар каршында. 1926 елда ук башлангыч мәктәп булып ачылганлыгы билгеле. 1981 елда сигезьеллыкка әйләнгән. 1991 елда, Илдар Миңнебаев тырышлыгы белән, урта мәктәп буларак эшли башлаган.

– Без үскәндәге гөрләп торган авыл юк, шуңа бик моңсуланам, әрним, – диде Илдар абый. – Шәһәргә дип чыгып китәләр. Ни өчен? Аңламыйм... Күбесенең фатиры да юк, кеше торагында яшиләр. Ә барыбер шәһәрдә көн итә дигән исем алу өчен шунда интегеп яталар. Элеккеге укучыларымны күрсәм дә, гел әйтәм: «Кайтыгыз авылга. Монда да тормыш бар бит!»

Илдар абыйның Кече Болгаерда сүзе үтә икән: зират коймалары тотарга, өмәләр ясарга булсынмы, башлап йөри. Ул әйтсә, халык җыела.

Тагын шушы урында Кече Болгаер өчен күңелле вакыйганы – авыл тарихын, бүгенгесен яктырткан китап турында да әйтми кала алмыйм. Аның авторы – Гөлүсә Закирова. 624 биттән торган калын китапта язучы, журналист, архив документларыннан тыш, авылдагы йолалар, урам, елга, күл атамаларын да бар-

лый. Ризык рецептларына кадәр бирә. Мисал өчен, Кече Болгаерда гомер-гомергә, табикмәктән кала, бодай бәлеше, эремчек пилмәне, юка, сөтле аш әзерләгәннәр. Ә мөтлек ашы (кыр суганы белән пешерелгән итсез аш), ышти (яңа суйган терлек эчәгесен яки картасын чүлмәккә салып, төнгегә мичкә куялар, аннан борчак салып пешереп бетерәләр) аеруча кызык тоелды.

ЯШИ-ЯШИ КАДЕРЛЕ

Ашыга-ашыга Зәйтүнә апа янына кайтып кердек. Камыр инде кабарган иде.

– Эшне башларга, дип, сезне көтәм, әйдәгез, тизрәк, – диде хуҗабикә.

Табикмәкне пешерү тәртибе юканыкы сыман. (Узган ел без аны Кайбыч районының Кошман авылында әзерләгән идек. Камырны юка гына итеп җәеп ялкында пешерәләр). Зәйтүнә апа башта камыр җәймәләре җәйде. Аннан кайнар майлы табага аларны җәеп салды. Һәм табаларны мичкә – ялкынга таба шудырды.

– Ә нинди утын кирәк? – дим, шарт-шорт янган учакка карап.

– Туйра агачы. Гадәттә мич өчен юкә, туйра тотам, башкалары чәчри чөнки. Ялкынны карап кына торам, уттан бик куркам. Йөрәккә кереп калган...

Закировларның йорты 1990 елда янып көлгә әйләнгән икән. Авылдашлары, колхоз ярдәме белән яңадан шул ук нигезгә йорт салганнар.

– Мин гел колхозда эшләдем, – диде Зәйтүнә апа. Сыер да саудым, сөт тә җыйдым, склад мөдире дә булдым. Шуңа район, колхоз җитәкчеләре дә ташламады. Авыр еллар иде бит. Әле балалар да кечкенә. Ашатырга, киендерергә кирәк, дигәндәй. Башта бер кечкенә йортта яшәп тордык. Алланың рәхмәте, йортны тиз эшләп чыктык. Барысы да җайланды. Инде шушы йортта картаерга язсын.

Хуҗабикә, хисләргә бирелеп, игътибарын безгә юнәлткән арада мичтәге камыр күпереп менде.

– Ай-ай, – дип, Зәйтүнә апа җәймәне әйләндерде.

Монысы да гаҗәп тоелды: ялкында камыр әйләндермичә дә пешә?! Һәр эшнең үз җае, дигәндәй, моның үз сере бар икән:

– Әйләндергәч, камырның ике ягы да кетердәп тора. Бөтен хикмәт шунда, – диде аш-су остасы.

Аларны янә мичкә тыкты Зәйтүнә апа. Бу юлы инде тизрәк алды. Кайнар табаны өстәлгә куйды да җәймәгә бәрәңге сылады. Һәм яңадан мичкә озатты.

– Бәрәңге кызара башлагач, кире алабыз, – диде хуҗабикә.

Ул арада сыер маен эретергә куйды. Аннан каз канатыннан ясаган тегәчне юып алды.

– Яңа тегәч ясаган идем, журналга матур чыксын әле... – диде.

Табикмәк әзер булды. Камырлы җирләре кызарыбрак та киткән, бәрәңге яккан өлеше саргаеп, ялкында ягымлы бер алтынсу төскә кергән. Моннан бигрәк, өйгә таралган хуш ис борынны иркәләде. Әйтерсең, ул һәр күзәнәккә кереп, балачакка алып кайтты. Төтен катыш камыр исе... Болар инде сагынып сөйләргә генә калып бара. Әйе, утын миченең ямен, көчен бернинди заманча электр, газ мичләре дә алыштыра алмый. Мөмкин түгел! Шушы вакытта күңелгә бер уй килде: үз йортың булса, һичшиксез, мич ясарга кирәк! Әллә ни күп урын алмый бит ул. Ә нинди зур файда: телеңне йотарлык ризык әзерләү бер булса, ул йортта үскән балалар өчен – гомерлек балачак хатирәсе. Яши-яши, анысы да бик кадерле була икән шул...

Зәйтүнә апа яңа тегәч белән табикмәкнең өстен майлап алды. Ризыгыбыз ялтырап китте, ашыйсы килү теләгеннән көчәйтте генә.

Икенче җәймәне мичкә куйгач, хуҗабикә яңа пешкән табикмәкне кисә дә башлады:

– Табикмәкне кайнар килеш ашыйлар, бәрәңге ризыгы, суынгач, тәмен югалта. Әйдәгез, җитешегез, – диде.

Авыз итәбез... Гаҗәп. Мондый тәмле камырны күптән авыз иткән юк иде. Югыйсә су белән йомырка, сыек майга гына басылган. Төп хикмәт, ахрысы, әлеге дә баягы мичтәдер. Камыр кетердәп торса да, өстенә ягылган бәрәңге аны йомшарткан. Хәтта төелгән бәрәңгегә дә үзенә бер төрле тәм кергән, төтен тәме, димме.

– Табикмәкне газ мичендә дә пешереп буламы? – дим.

– Буладыр, – ди Зәйтүнә апа. – Тик мичтә пешергән кебек булмый инде. Бик ашыйсы килсә, безгә кайтыгыз, пешерермен. Аны әзерлисе авыр түгел. Димәк, аппетит уянгач, Кече Болгаерга тагын кайтып киләсе булыр... ■

1. Салабыз!

2. Сытабыз!

3. Бутыйбыз!

4. Каплыйбыз!

5. Түгәрәклибез!

6. Җәябез!

7. Тигезлибез!

8. Куябыз!

9. Әйләндерәбез!

10. Җәябез!

11. Алабыз!

12. Майлыйбыз!

facebook.com/protatarstan

Реклама 16+

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН TATARSTAN

twitter.com/protatarstan

instagram.com/protatarstan

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ
РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Казан ханлыгының беренче ханы **КЕМ** булган

Композиторлар язган китаплар **НӘРСӘСЕ** белән үзенчәлекле

Шагыйранә мәхәббәт **НИНДИ** була

Күн **НИЧЕК** Коньга әверелгән

«Татарстан» журналы өчен МАХСУС

ОЛУГ МӨХӘММӘД ҺӘМ АНЫҢ УЛЫ МӘХМҮД

Автор:
Фаяз Хуҗин

Олуг Мөхәммәд – Алтын Урданың соңгы, Казан ханлыгының беренче ханы дигән караш тарих фәнендә XVIII–XIX гасырларда ук ныклап урнаша һәм әле бүген дә яшәвен дәвам итә. «Татар энциклопедиясе»нең 4 нче томында да Олуг Мөхәммәд «Казан ханлыгына нигез салучы һәм аның беренче ханы» буларак күрсәтелгән. Соңгы елларда аңа башкалабызда һәйкәл куярга кирәк, дигән фикерләр дә ишетелә башлады. Әмма Казан ханнарының исемлеген Олуг Мөхәммәдтән түгел, ә аның улы Мәхмүдтән башлап җибәрүче тарихчылар да байтак. Соңгы вакытта аларның тавышы көчлерәк яңгырый башлады. Хакыйкать кайда? Шул сорауга җавап табарга тырышыйк.

Фотолар автордан алынды

КАЗАН ЕЛЪЯЗМАЧЫСЫ, ЯКИ ШОВИНИЗМ ҮРНӘГЕ

Россия тарих фәненә нигез салучыларның иң элгәреләреннән берсе Андрей Лызлов үзенең 1692 елда тәмамланган «Скифлар тарихы» дигән хезмәтендә Олуг Мөхәммәдне Казан ханлыгына нигез салучы дип атый. Бу фикерне ул билгесез авторның «Казан тарихы» исемле китабыннан алынган мәгълүматларга таянып әйтә. «Билгесез автор» дигәнебез (аны «Казан елъязмачысы» дип тә йөртәләр) 1530 еллардан башлап ике дистә елга якын Казанда әсирлектә булган урыс кешесе. Укымышлы, киң карашлы шәхес булгандыр, күрәсең: ханнарга хезмәт итә, буш вакытларында болгарлар һәм татарлар тарихына караган мәгълүматлар җыю белән шөгыльләнә. 1552 елда, Казан басып алынгач, ул иреккә чыга, кире Мәскәүгә кайта һәм 1564–1565 елларда мәгълүм әсәрен яза.

«Казан тарихы» – матур әдәбият әсәрләренә тартым публицистик хезмәт, биредә Казан җирлегендә чынбарлыкта булып узган кызыклы фактлар, тарихи вакыйгалар белән бергә ривәять-легендалар, мифлар, автор фантазиясе белән тудырылган уйдырмалар да урын алган. Әмма аноним-автор башлыча рәсми рус елъязмаларына таяна, максаты – денсез, бозык («поганый») татарларга каршы озак елларга сузылган «изге» көрәштә Явыз Иванның 1552 елгы җиңүенә дан җырлау була. Максатына ирешү юлында тарихи фактларны аңлы рәвештә бозып күрсәтүләрдән дә баш тартмый. Шуңа күрә дә XIX йөзнең атаклы шәрык белгече, археолог һәм нумизмат, академик В.В. Вельяминов-Зернов «Казан тарихы»н шовинистик рухлы авторның төрле уйдырмалардан җыелган, тарихи дөреслектән ерак торган публицистик әсәре дип атады, галимнәрне анда китерелгән фактларга тарихи чыганак итеп караудан сакланырга чакырды. Ә бит «Олуг Мөхәммәд – беренче Казан ханы» дигән фикер нәкъ менә «Казан тарихы» уйдырмаларына нигезләнгән. В.В. Вельяминов-Зернов үзенең «Касыйм ханнары һәм солтаннары турында эзләнүләр» исемле хезмәтендә (СПб., 1863 ел), әлеге фикер тарихи чыганаклар белән расланмый, дип язып чыга. Әйдәгез, тарихи чыганакларга мөрәҗәгать итик.

Казан бүреге. Казан ханнарының алтын таҗы.

КӨТЕЛМГӘН ҖИҢҮ

Олуг Мөхәммәд – Җәлләлетдин ханның улы, Туктамыш ханның оныгы – Алтын Урда тәхетенә 1420 елда, Идегәй мирза үтерелгәннән соң утыра. Ике ел да үтми, хан тәхетен Сәмәрканд әмире Аксак Тимернең оныгы Олугбәк ярдәме белән Коерчак ханның улы Барак яулап ала. Олуг Мөхәммәд гаскәрләре Литва чикләренә килеп тукталалар. Бөек Литва кенәзе Витовт аңа Барак ханга каршы көрәштә ярдәм кулын суза, нәтиҗәдә Олуг Мөхәммәд Алтын Урданың көнбатыш өлешендә хакимиятен яңадан торгыза. 1426–1427 елларда ул Витовтның Псков һәм Рязань шәһәрләренә оештырган яуларында катнаша, 1428 елда Төркия солтаны Морад II белән дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыра, 1429 елда Дәүләтбирде ханга каршы көрәштә җиңүгә ирешә. Олуг Мөхәммәднең хакимиятенең көчәюен күреп торган дошманнары аңа каршы көрәш башлый. Озак елларга сузылган көрәш Олуг Мөхәммәднең Алтын Урда тәхетеннән куылуы белән тәмамлана. Бу хәл 1437 елда була. Тәхеткә Тимер ханның улы Кече Мөхәммәд утыра, ә Олуг Мөхәммәд исә 3 мең чамасындагы гаскәре белән Бөек Мәскәү кенәзлегенең көньяк-көнбатыш чигендә урнашкан Биләү (Белёв) шәһәрчеге янына килеп туктый (11 меңләп халкы булган бу шәһәр административ яктан хәзер Тула өлкәсенә карый).

Мәскәүнең бөек кенәзе Василий II көтелмәгән кунакны, гәрчә ул әле берничә атна элек кенә Алтын Урда ханы булса да,

Олуг Мөхәммәд

Мәхмүд

шат йөз белән каршы алмый, әлбәттә. Алда торган көрәшне сизеп, Олуг Мөхәммәд Биләү шәһәрчеген ныгытып калырга омтыла – салкын кыш булудан файдаланып, сугышчылар кальга-шәһәрчек урнашкан тау битен бозга катыралар, калын боз кантарларыннан яңа ныгытмалар төзиләр. Бөек кенәз Василий II, «боз шәһәрчеген» һәм анда тупланган гаскәрне тиз генә юкка чыгару, буйсындыру өчен бертуганы Юрийның уллары Дмитрий Шемяка һәм Дмитрий Красный җитәкчелегендәге 40 мең сугышчыдан торган гаскәрен Олуг Мөхәммәдкә каршы җибәрә. Бу кадәр гаскәрне күреп, Олуг Мөхәммәд башта каушап кала, кенәзләргә берничә тапкыр солых килешүе тәкъдим итә. Тәкъдим кире кагыла. Сугышудан башка чара калмый. 1437 елның 5 декабрендә Олуг Мөхәммәд атлылары тау башындагы «бозлап катырылган ныгытма» эченнән очып дигәндәй чыгып, күз ачып йомган арада Василий II гаскәрләре өстенә ябырыла. Берничә сәгать аралыгында русларның алдынгы отрядлары юк ителә, калганнары куркып чигенә һәм кача. Бу Олуг Мөхәммәднең үзе дә көтмәгән зур җиңүе була.

ЧЫГАНАКЛАР НИ СӨЙЛИ?

Биләү янындагы сугыш уңышлы тәмамланса да, Олуг Мөхәммәд бирелә артык тоткарланырга кыймый. 1438 елның башында ул Түбән Новгородка юнәлә һәм бирелә төпләнеп кала. 1439 елда ул нәкъ менә Түбән Новгородтан Мәскәүгә яу чаба. Шәһәргә керә алмый, әмма шул тирә-калаларны талый, яндыра, елъязмачы сүзләре белән әйтсәк, «зла многы учини земли Русскои».

1444–1445 елның кышында Олуг Мөхәммәд Түбән Новгородтан Муромга яу чаба. Василий II татар гаскәрләрен тар-мар итә һәм Олуг Мөхәммәд бернинди табышсыз диярлек кире Түбән Новгородка әйләнеп кайтырга мәҗбүр була.

1445 елның язында Олуг Мөхәммәднең Якуб һәм Мәхмүд исемле уллары Василий II гаскәрләре белән кабат Суздаль янында очрашалар. Бу юлы алар рус гаскәрләрен тар-мар итеп кенә калмыйлар, олуг кенәзнең үзен дә әсирлеккә алалар. Аннан соң алар Владимирны кулга төшермәкче булалар, әмма көчле ныгытылган шәһәргә үтеп керә алмыйлар, Муром аша әтиләре янына – Түбән Новгородка кайтып китәләр.

Шул ук елның 25 августында Олуг Мөхәммәд «үзенең бөтен балалары һәм бөтен урдасы белән [Түбән] Новгородтан Курмышка килә, үзләре белән бөек кенәзне [Василий II не] дә алалар» («з детьми своими и со всею ордою своею поидоша из Новгорода к Курмышу, а князя великого с собою поведоша»), – дип хәбәр итә XV гасыр ахырында яшәгән рус елъязмачысы.

Шушы вакыйгадан соң Олуг Мөхәммәд исеме тарихи чыганакларда бер тапкыр да телгә алынмый. «Казан тарихы»-ның билгесез авторы язганча, ул кече улы Якуб белән Казанда өлкән улы Мәхмүд тарафыннан үтерелә, имеш («умре в Казани с юнейшим своим сыном Ягупом: оба ножем зарезаны от болшого сына своего Мамотяка»). Тарихчылар бу хәбәрне кеше ышанмаслык хәл буларак бәялиләр. Шулайдыр дип фаразлыйк. Әмма Олуг Мөхәммәднең 1445 елда Курмыш шәһәрендә вафат булуына ышанырга мөмкин. Бу турыда күренекле дин галиме һәм тарихчы Ризаэддин Фәхреддин дә язган иде.

Югарыда китерелгән фактлардан чыгып, шуны кистереп әйтә алабыз: Урта Иделгә күчеп килгәч, Олуг Мөхәммәд күпмедер вакыт Биләүдә, Түбән Новгородта, Курмышта яшәгән, әмма аның Казанда булуы бер генә тарихи чыганак белән дә расланмый һәм бер генә документ та аны Казан ханы дип атамый.

Шулай булуга да карамастан, без Олуг Мөхәммәдне халкыбыз тарихының иң атаклы шәхесләре рәтенә куярга тиешбез. Чөнки без аны, беренче чиратта, урта гасырлар чоры төрки-татар дөньясында искиткеч зур роль уйнаган Алтын Урда дәүләтенең мәшһүр ханнары арасында күрәбез. Алтын Урданың тулысынча таркалуы чорында тәхеттән куылып, Урта Иделгә килеп төпләнүенең сәбәбе дә, безнең фикеребезчә, яңа җирләр яулап алу түгел, бәлки Алтын Урданың иң алдынгы бер төбәге җирлегендә, аның дәвамчысы буларак, яңа дәүләт – Казан ханлыгы төзү булгандыр. Тик бу проектны ул үзе тормышка ашырырга өлгермичә кала. Проект аның улы Мәхмүд тарафыннан тормышка ашырыла.

2017 елның 19 маенда Казан Кремле территориясендә, Сөембикә манарасы янында, Казан ханнары Мәхмүд һәм Мөхәммәд-Әминне, һәм шулай ук аларның ике гаилә әгъзасын күчереп күмү церемониясе үтте.

ДИНАСТИЯЛӘР АЛМАШЫ

Казан ханлыгының әүвәлге ханы – Олуг Мөхәммәднең улы Мәхмүд. Без моны шикләнмичә әйтә алабыз. Бу турыда русларның Воскресение һәм Никон елъязмаларыннан укып беләбез. 1445 елның көзендә, диелә Воскресение елъязмасында, Олуг Мөхәммәднең улы Мәхмүдәк Казанны сугышып ала һәм Казан кенәзе Либейне үтереп, тәхеткә үзе утыра («царь Мамотяк, Улу-Магметов сын, взял город Казань, вотчича казаньского князя Либея убил, а сам в Казани сел царствовати»). Никон елъязмасында да шул ук хәбәр урнаштырылган, бары тик Мәхмүдәкнең Казанга Курмыштан килгәнлеге турында гына өстәмәсе бар («царь Мамутяк, пришед ис Курмыша...»).

Биредә телгә алынган Казан кенәзе Либей (Алибей) – Алибәкнең русча әйтелеше генә. Алибәк – Аксак Тимер заманында үтерелгән соңгы болгар ханы Абдулланың улы булырга мөмкин дип фаразлаучы галимнәр бар. Ягъни мәсәлән, Мәхмүд Казанны яулап алганчы ук инде биредә тәхет буш тормаган, димәк, Казан дәүләте булган. Мәхмүд исә бары тик шул дәүләт хакимнәренең җирле (болгар) династиясен өзеп, Җучилар династиясенә нигез салучы гына, имеш. Әлеге фаразда мантыйк бар, әлбәттә. Чыннан да, Идел Болгары дәүләте яшәүдән туктагач, XIII–XIV гасырлар чигендә, монгол яуларыннан Казан тирәсенә качкан болгарлар мөстәкыйль Казан дәүләте төзергә омтылалар. Казан әмирлеге барлыкка килә (Мир-Мәхмүд улы әмир Хәсән-бәкнең Архирей дачасында, элеккеге Кабан шәһәрлегендә табылган каберташын исегезгә төшерегез), әмма ул XV йөз башларына кадәр Алтын Урда составына керә, аннан соң тагын мөстәкыйльлеккә ирешә. Кайбер фаразлауларга караганда, 1420–1430 елларда Казанда Җучилар нәселеннән чыккан Гыясетдин идарә иткән булырга тиеш. Ул үз исеменнән акчалар да суктырган, әмма аларның берсе дә әлегә кадәр Казанда табылмаган. Димәк, Гыясетдиннең Казан идарәчесе булуына шикләнеп карарга нигез бар. Ә менә Олуг Мөхәммәд улы Мәхмүдне хаклы рәвештә Казан тәхетенә утырган һәм бөтенләй яңа шартларда Җучилар династиясен дәвам иттергән беренче хан дип әйтә алабыз.

Мәхмүд ханның Казанда кайчанга кадәр тәхет хуҗасы булып торуы билгесез. Тарихчыларның бу хакта төгәл фикере юк: 1445 елдан башлап, 1461, 1462, 1464, 1467 елга кадәр идарә иткән булырга тиеш диләр. 1467 ел датасы дөрес түгел, чөнки бу елда инде тәхеткә Мәхмүднең икенче улы – Ибраһим хан утыра. Ә бит аңа кадәр әле хан тәхетен Хәлил хан – Мәхмүднең өлкән улы биләп тора. Ул озак идарә итми, хатыны Нурсолтанны тол калдырып, гүр иясе була. Шушы фактларны истә тотып, Мәхмүд ханның идарә иткән чорын 1445–1464 еллар белән чикләү дөресрәк булыр кебек.

Мәхмүд хан идарә иткән еллар ханлык тарихына иң тыныч еллар буларак кереп калган. Бары тик бер тапкыр, 1447 елда гына Владимир һәм Муром шәһәрләренә яу чабыла. Мәхмүд хан Мәскәү кенәзлеге белән тыныч сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырып, үзенең бөтен көчен яңа корылган дәүләтнең икътисади куәтен ныгытуга юнәлтә. Рус кенәзлекләреннән, Себердән, Урта Азия шәһәрләреннән, Кавказдан һәм Шәрык илләреннән Казанга сәүдә кәрваннары агыла. Казан тиз арада халыкара сәүдә үзәгенә әверелә. Хан казнасын баетуга 1445 елдагы солых килешүе нигезендә Василий II тарафыннан җибәрелә торган салым да үз өлешен кертә.

Мәхмүд ханның абруе гади халык арасында да зур була, чөнки илдә игенчелекнең үсүе, Казанда һәм башка кечерәк шәһәрләрдә һөнәрчелекнең чәчәк атуы халыкка мул тормыш алып барырга мөмкинлек тудырган, хан һәм аның хөкүмәте тарафыннан үткәрелә торган эчке һәм тышкы сәясәт күпләрдә хуплау тапкан.

Мәхмүд хан үлгәннән соң, аның җәсәден, Алтын Урдада кабул ителгән йолага туры китереп, махсус төрбәгә урнаштыралар. Археологлар тарафыннан 1977 елда казып тикшерелгән ханнар төрбәсендә аның каберлеге табылды. Мәскәү антропологы Т. Балуева, Мәхмүд ханныкы дип ачыкланган баш сөяген өйрәнү нәтиҗәләренә таянып, аның скульптур портретын ясады. Узган ел исә Мәхмүд ханның моңарчы Кремльдә, археологик музей фондларында сакланып яткан сөякләре яңадан борынгы төрбәгә кайтарып күмелде. ■

«АКЫЛДАН ЯЗГАН ДӨНЬЯ», ЯКИ ЛОГИК ХИССИЯТ

Без сәнгатьнең коммерция рельсларына бастыргач кына популярлык казана, иҗат кешесенең дә абруе шулай гына формалаша, урнаша алуы нормага әверелгән чорда яшибез. Һәм моңа һаман да ияләшеп җитә алмый интегәбез. Югыйсә, капиталистик җәмгыятьтә бу рельслар инде бик күптәннән анык тәгаенләнгән дә, «иҗади вагоннар» һәрберсе үз расписаниесе буенча йөреп тора. Һәм һәр вагонның – үз классы.

Автор:
Луиза Янсуар

Бүгенге музыка сәнгате кино индустриясе белән гаять тыгыз бәйләнгән. Академик музыка тудыручы композиторларның да күпчелеге нәкъ менә кино өчен иҗат иткән әсәрләре аша барып ирешә, иң беренче чиратта, тыңлаучыга. Бу очракта барлыкка килгән иҗади тандемнарны да яхшы беләбез (мәсәлән, Федерико Феллини, Лукино Висконти – Нино Рота; Эдуард Артемьев – Андрей Тарковский; Анджело Бадаламенти – Дэвид Линч; Клинт Мэнселл – Даррен Аронофски һ.б.). Аннан инде композиторның исеме популярлаша. Һәм торабара бу исем иҗатчының үзенә эшли башлый. Ә менә бу очракта ничек тиражга чыкмаска – монысын инде һәр иҗатчы үзе генә хәл итә ала.

Бүгенге Голливуд һәм автор киносы вәкилләреннән булган режиссерлар даими мөрәҗәгать иткән композиторларның иң танылганнары арасында, һичшиксез, Эннио Морриконе, Томас Ньюман, Джеймс Ньютон Ховард, Джеймс Хорнер, Говард Шор, Ханс Циммер, Ян Тьерсеннар бар. Музыка белән киноны, академик сәхнәне, гастрольләрне дә берләштерүче Людовико Эйнауди, Макс Рихтер, Yiruma, Джо Хисаиси, Олафур Арналдсларны да атап үтү кирәктер. Бу исемлеккә тагын берәү бар. Һәм бүген безнең фокуста ул булачак.

КИРТӘЛӘР ҺӘМ МӨҺЕРЛӘР

Петербургта Иван Лимбах нәшриятында дөнья күргән һәрбер китап – затлы басмаханәнең зәвыклы укучысына чираттагы бүләге ул. 1995 елның 2 августында нигез салынган әлеге басмаханә гуманитар юнәлештәге материалларга йөз тота. Коммерцияле проектлардан тулаем баш тартып, беренче көннәреннән үк элитар басмаларга өстенлек бирә. Шактый чуар, үзгәрүчән һәм анык кына ориентирларсыз Россия китап базарында аның үз урыны һәм репутациясе бар. Бу нәшрият архивларга, моңарчы басылмыйча яткан мемуарларга, кульязмаларга гаять зур кызыксыну белдерүе, сак һәм җентекләп якын килүе белән дә билгеле. Китап гурманнары өчен – чын мәгънәсендә «Әбүгалисина мәгарәсе», кыскасы.

Агымдагы елда Лимбах нәшрияты безне көтелмәгән бер басма белән сөендерде. Филип Глассның «Слова без музыки. Воспоминания» тупланмасы шәхсән минем өчен зур сюрприз булды. Бездә бу композиторны халык Европада, Америкадагыча ук белмәсә дә, музыка сәнгатен сөючеләргә ул яхшы таныш. Россиядә еш кунак булган Гласс хәтта иң билгелеләрдән берсе, дияргә дә мөмкиндер. XX гасырның икенче яртысындагы һәм бүгенге заман авангард музыкасын аның фигурасыннан башка күз алдына китерү кыен. Кайчандыр кыю, тәвәккәл экспериментлардан башлаган Гласс бүген инде үзен классик-академик юнәлеш белән бәйли. «Кабатлана торган структуралы музыка» дип тәгаенләнгән иҗаты да еллар эчендә, билгеле, күзгә күренерлек эволюция кичерә. Гласс: «Мин хәзер гармония һәм контрапункт белән виртуозларча эш итәмен, моңа мин Шуберттан, Бахтан, Моцарттан өйрәндем», – дип кабатларга ярата.

Фотолар: philipglass.com сайтыннан алынды.

Шулай да, парадокс: Гласс музыкасын кайбер академик музыка тарафдарлары, музыка тәнкыйтьчеләре «киң масса өчен», «лохлар өчен» дигән тамга салып, әлегәчә «классика перифериясендәге эзләнүләр» дип мөһерләвен дәвам итә. Шулай ук автор киносы вәкилләре, Голливуд белән хезмәттәшлеге, төрле эксперименталь мәйданнарга чыгудан йөз чөермәве, бөтенләй көтелмәгән жанрдагы музыкантлар һәм башкаручылар белән синтезга омтылуы өчен дә даими тәнкыйтьләнеп тора ул.

Филип Гласс Балтиморда яһүдләр гаиләсендә 1937 елның 31 гыйнварында дөньяга килә. Әти-әнисе, Сталин репрессияләреннән качып, Литва территориясе аша Америкага чыккан иммигрантлардан була. Филипның әтисе Балтиморда грампластинкалар кибете тота.



«Эйнштейн на пляже» операсыннан күренеш.

Когда кто-нибудь говорил, что не занимается коммерческим искусством, я думал: «Ну, значит, у тебя уже есть деньги, и ты можешь себя прокормить». Идея «торговли музыкой» никогда не вызывала у меня отторжения. Мы с братом с 12 лет работали в отцовском магазине – торговали пластинками. Я с раннего детства видел, как покупатель дает папе 5 долларов и получает взамен пластинку. Не счесть, сколько раз я видел этот обмен: деньги – музыка, музыка – деньги. В моем понимании это было нормально. Мне никогда не казалось, что в этом обмене есть что-то аморальное.

XX йөз музыкасын үзгәртүчеләрнең берсенә әверeләчәк егет озакламый Чикаго университетына юл тота: фәлсәфә һәм математика дисциплиналарын үзләштерер өчен укырга керә. Әмма хыялы һаман тартып тора. Музыка буенча иң яхшы белемне үзенә, Джульярд исемендәге музыка мәктәбеннән тыш, Парижда француз педагогы Нади Буланже бирде, дип исәпли. Шулай ук икенче бөек остазы дип ул ситарда уйнау виртуозы, һинд композиторы Рави Шанкарны атый. Нәкъ менә һинд музыкасы йогынтысы аша музыкаль әсәр иҗат иткәндә этәрелү ноктасы итеп ритмны ала Гласс.

Бу икәү-остаз һәм укучы – тудырган иҗат – үзе бер уникаль мәдәни катлам. Көнчыгыш белән Көнбатышның, медитатив көйләнеш белән мантыйкый төзелешнең кушылмасы, очрашуы, синтезы. Ул әсәрләр Европаның һәм Американың иң шәп музыкаль сәхнәләрендә, шул исәптән Бродвей, кайбер эксперименталь мәйданнарда да яңгырады. Гласс үзенең тәүге остазы Рави Шанкарга гомере буена тугры кала – алар 1990 елда уртак альбом да чыгаралар.

Когда я жил в Париже, оказался рядом с двумя большими профессионалами – музыкантами Нади Буланже и Рави Шанкаром. Я всегда представлял их себе так: одного сидящим на моем правом плече, другую – на левом. И каждый нашептывал мне на ухо что-то свое. Я пытался объединить ясность и точность техники, которой научился у Буланже, с эмоциональной силой, найденной в музыке Рави. Работал над этим девять лет...

Композиторга чын-чынлап танылу (аңарчы ул инде эре-эре әсәрләр тудырса да) 1983 елда килә. Годфри Реджионың «Каци» сериясен тәшкил иткән һәм бүген инде монументаль классика саналган «Койяанискаци» («Акылдан язган дөнья»), «Поваккаци» («Тормыш сихере»), «Накойкаци» («Сугышка әверелгән тормыш») фильм-трилогиясенә саундтрек иҗат иткәннән соң аны, ниһаять, белә һәм таный башлыйлар.

Акрынайтылган төшерү техникасында эшләнгән бу картина заманында бик күпләрне тетрәндергән иде. Фильм тулысы белән диктор текстыннан һәм актерлар катнашыннан мәхрүм, әмма аңардагы видеорәт белән музыкаль гәүдәләнеш шул дәрәҗәдә керешеп китә ки, син үзеңне экрандагы молекулалар, атомнар рәвешендә хис итә башлыйсың.

Я с самого начала понял, что изображение и музыка не должны совпадать на все сто процентов, поскольку тогда у зрителей не останется простора, чтобы вообразить что-то своей головой. Рекламный ролик – инструмент пропаганды, зрительный ряд и музыка слиты в нем нераздельно, чтобы довести до зрителя четкую мысль типа «Купи эти ботинки» или «Сходи в это казино». Стратегия же искусства в том, чтобы оставлять зрителю широкий простор. В этом путешествии ты, зритель, лично взаимодействуешь с музыкой и изображением. Если этого процесса нет, произведение никак не затрагивает лично. Идея личной интерпретации возникает, когда мы «путешествуем», преодолеваем эту дистанцию.

Филип Гласс эш вакытында.

Исеменә килгәндә, «койяанискаци» (ko yaa nis qatsi) гасырлар дәвамында Аризонаның төньяк-көнчыгышында яшәгән һәм үзара инде югалып барган юта-ацтек сөйләшендә аралашкан хопи индеецлары телендә берничә мәгънәви вариацияне белдерә: «акылдан язган дөнья», «тигезлеген һәм тәртибен җуйган тормыш», «җимерелү алдында торган һәм яңа шартларга яраклашуны таләп иткән халәт». Сүз уңаеннан, 2000 елда алынган җан исәбе буенча, хопилар резервациясендә 6 мең ярымлап кына кеше калганлыгы теркәлә. Фильмга музыка иҗат иткәндә, режиссер белән композитор Җир шарының әнә шундый почмакларында күп булалар: алтын юа торган шахталарга да төшә алар, афәт туздырып узган тулы бер кабиләләрне дә барлый, Көньяк Американың югалган цивилизацияләренең эзләреннән дә уза. Кешеләрнең күзләренә карап, язмышларын тыңларга, аннан аларның халәтен чагылдыра алырдай аһәң табарга кирәк була Гласска.

Мы с Годфри ездили вместе на все натурные съемки: в Южную Америку, в Африку, куда угодно. Я ездил в эти киноэкспедиции, потому что Годфри хотел, чтобы я участвовал в работе, и уговаривал составить ему компанию. Музыка получалась именно такой, какой получалась, благодаря тому, что я бывал на местах съемок. Я мог бы все домыслить, но тогда я бы, определенно, что-нибудь упустил. Если бы я не увидел, каково там, увидел не только на экране, но и собственными глазами, я не догадался бы добавить детские голоса. Я старался сочинить саундтрек, который пульсировал бы в крови, мускулах и сердцах людей, побывавших в тех местах.

Кеше белән технологияләрнең бәйләнешен күрсәтүне максат итеп куйган фильм-трилогиягә, лицензия буенча чикләүләр куелганга күрә, дистә еллар дәвамында киң прокатка чыгу бәхете тәтеми. Әмма Филип Гласс 1968 елда үзе туплаган Philip Glass Ensemble ансамбле төркемендәге музыкантлар белән, видеорәтне экранга куеп, дөньяның төрле сәхнәләрендә музыканы тереләй уйный башлый. Аларны кайларга гына чакырмыйлар.

Тора-бара Гласснең саундтреклар коллекциясен берсеннән-берсе үзенчәлекле, кайсыберләре «Оскар»га номинант яки лаек дип тә табылган фильмнар тулыландыра: «Шоу Трумена», «Тонкая голубая линия», «Кундун», «Иллюзионист», «Часы», «Забирая жизни», «Апостол», «Левиафан» һ.б. Ул 50 дән артык фильмга музыка иҗат итә. 1984 елда Лос-Анджелестагы Олимпия уеннары ачылышы тантанасына музыканы, заказ биреп, аңардан яздырталар.

ЙӨРӘК ТИБЕШЕННӘН ТОРА...

Лимбах нәшрияты чыгарган китап безгә мәтрнең мәтр булганчыга кадәр үткән юлын, кыюлыгын, тәвәккәллеген күзалларга менә дигән мөмкинлек бирә. Музыкаль белем алыр өчен ул кайчандыр ялланып төнге эшләрдә эшләсә, соңрак, гаилә корып, олы тормышка аяк баскач, заводларда, складларда хезмәт куеп, сантехник, таксист булып акча юнәтеп, музыкасын төннәрен яза торган була. Гаиләсенә комачауламас өчен, еш кына – төнге кафеларда утырып. Шундый төннәрнең чираттагысында аңа кафеда фортепиано өчен квинтет иҗат итеп утырган 60 яшьләрдәге берәү очрый. Гласс әлеге беркемгә дә билгеле булмаган композиторның үзенә нинди көчле тәэсир ясавын әңгәмәләрендә дә еш искә ала, ошбу китабында да кабатлый. «Әйтерсең, мин үземне күрдем анда», – ди.

Китаптагы истәлекләрдә иҗат итәр өчен башка өлкәләрдә тир һәм көч түгәргә, вакытын сарыф итәргә кирәк булуы турында язса да, Гласс бернәрсә өчен дә тамчы да үкенече юклыгын ассызыклый. Киресенчә, нәкъ әнә шул елларда ул үзенең тәмам ныгуын, дөньяга карашының аныклануын, шулай ук сайлаган кыйбласына инануы артуын да тоя. Тормышны төбеннән өйрәнеп, бар ракурстан күреп кенә сфералар югарылыгының кадерен тоеп буладыр, бәлки.

Аның фирма стилен бар масштабында «бөек кешеләргә багышланган опералары» аша тоемлап була: «Эйнштейн на пляже» (1975-1976), «Сатьяграха» (Махатма Ганди турында) (1978-1979), «Эхнатон» (1983), «Галилео Галилей» (1990), «Кеплер» (2009). Икенче операсы уңыш казанып, киноиндустриянең аңа булган кызыксынуы ачыкланганнан соң, ул, ниһаять, үз иркендә иҗат итү мөмкинлегенә ирешә. Акчага туктаусыз кытлык кичерми башлый.

Европа һәм Азия буйлап озаклап сәяхәткә чыгып китә. Хатыны белән бергә Испания аша – Төркиягә, Иранга, Әфганстанга, Пакыстанга, Һиндстанга юл тота. Төньяк Америка белән Африка да даими урап кайта торган җирләренә әверелә аның. Шуңа да, мөгаен, музыкаль кызыксынулары чиксез – ул дөнья музыкасының барлык тарафлардагы үзенчәлеген бердәй күрә, барлык илләрнең музыкантлары

белән теләсә нинди жанрда экспериментлар ясарга, чыгышлар хәстәрләргә ачык һәм әзер тора. Юкка гына аның музыкасы турында «космополитик палитра» димиләр. Гласс үзе барлык халыклардагы музыканың бер уртак Чыганакка барып тоташуы турында кат-кат ассызыклый. Ә чын музыканы танудагы иң алдамый торган критерий буларак йөрәкне күрсәтә: «Әгәр яңгыраган аһәңнәрдән йөрәгең тынгысызлана, катырак тибә, җилпенә башлый икән, димәк, бу – ул, дөрес музыка».

Китапның визуаль хәл ителеше дә Гласс очрагында искиткеч символик: ап-ак минималистик тышлыкта – буш нота ыстаны. Дизайнерлар метафораны сурәтли алган, яхшы тоем белән эш йөрткән: бу үзенә тиешле урыныннан махсус кубарылып төшеп, яңа колач һәм яңгыраш кырына омтылган музыка. Үтә күренмәле линияләр аның безгә бик яхшы таныш, беренче карашка, гаҗәеп аңлаешлы булып та, барыбер ваемлап бетерелек түгел икәнлегенә ишарә ясый. Глассны, композитор буларак, бер генә тапкыр ишетеп карамаган укучы да (хәер, миңа калса, бүгенге сәнгати барышны азмы-күпме ваемлаган кеше өчен бу мөмкин түгел!), китапны укыгач, аны, һичшиксез, беләсе, тыңлыйсы киләчәк.

Тарихи-автобиографик яссылык – Гласс очрагында бу аеруча әһәмиятле. Чөнки ул искиткеч социаль сизгерлеккә ия композитор. Шулай да Гласс, үз истәлекләренә бирелеп китеп, киң контексттан читләшми, вакланмый, субъективлык сазлыгына кереп батмый. Хәтта югарыда искә алганча, заводта эшләгән чактагы хәлләре, такси йөрткәндәге юлыккан очраклары турында сөйләгәндә, аларны сурәтләгәндә дә, контрапункт белән виртуозларча идарә итә. Ахыр чиктә, без, каршысына (бәлки, янәшәсенә) утырып, китап битләре аша ни турында гына гәп корсак та, сүзнең барыбер дә үз магистраленә – музыкага килеп тоташуын аңлыйбыз.

60 нчы елларда, әле анда туристлар эз салганчы ук, Һиндстанга ничек барып эләгүләрен, кырыс-шомлы Әфганстанны ничек кичүләрен бәян иткәндә дә Гласс кызыклы, ирониялe һәм объектив сөйләүче булып калырга тырыша. Ул, күкрәк кагып, ирекккә омтылыш, җан яңарту, нирванага ирешү, инициацияләр кичерү турында гәп куертмый, гуру булып күренергә дә теләми, ә бары тик үз юлын, үз тормыш пунктирын гына тасвирлый. Контекстны, тарихи фонны син, белемең һәм эрудицияң мөмкинлек биргәнчә, үзең «укып аласың».

Бервакыт Калимпонг шәһәрендә ул Томо Геше Ринпоче белән очраша. Аның ярдәме һәм җиңел кулы белән мантраларга, борынгы изге текстларга якыная, аутентик музыка кораллары белән таныша. Бу дөньяга баштанаяк кереп күмелә, Тибет традициясендәге өйрәнүләрне үзләштерә. Хисси тоемлауга корылган традицияләрнең чагылышы белән берртән, Глассның логик аек акылын, математик белемен, Буланжедан үзләштергән техник төгәллеген дә исәптә тотсак, әлеге композитор музыкасының берләштереп булмастайны берләштерергә омтылуын да ваемлый алабыз. Гласс аны шулай аңлата да: «Аң, хәтер һәм күзаллау киңлеге, хисләр спектры бердәй эшли торган модальлек ул – музыка», – ди.

Китап 60–80 нче еллардагы Нью-Йорк культурасын, андагы агымнарны, юнәлешләрне тулырак күздән кичерергә дә мөмкинлек бирә. Шәхесләр һәм аларның үзара бәйләнешләре, хезмәттәшлекләре, дуслыклары аша, билгеле. Менә алар – Аллен Гинзберг, Чак Клоуз, Ежи Гротовский, Ричард Серра…

В Париже со мной по соседству жил знаменитый ирландский писатель и драматург Сэмюэль Беккет. Неожиданно для себя я занялся экспериментальным театром. Затем Годар начал снимать фильмы каждые три месяца. Вы представляете себе, какой сумасшедший замес! Вот время-то было! Нужно было быть глухим, тупым, слепым, чтобы не замечать, что прямо у тебя под носом вершатся великие дела.

И сейчас жить не менее интересно. Да, общество распадается на части, но именно в такие моменты случается все самое интересное. Когда общество сходит с ума, искусство развивается в ускоренном темп.

Истәлекләрдә балачакка, үсмер елларга, кешенең ничек формалашуын аңларга тырышуга, гаиләгә, тәрбиягә, туганлык мөнәсәбәтләренә, дуслыкка… – тормыш сүрүен тәшкил иткән тагын бик күп әһәмиятле өлешләргә дә урын мулдан бирелә. Композиторның ни өчен билгеле бер темаларга, мотивларга өстенлек бирүен дә яхшы аңлыйсың. Менә ул, репрессияләрдән, Холокосттан качып киткән нәсел, токым баласы, 1940 нчы елларда Балтимордагы кинотеатрга йөри. Көнгә ике кино карый идем, ди: берсе – нәфис фильм булса, икенчесе – кинохроника. Нәфис фильмнардан аның күңел киштәсенә Рене Клер, Ингмар Бергман, Витторио де Сика, Жан Кокто һ.б. үз чорының кабатланмас даһилары кереп урнашса, документаль фильмнарда сайлап тору мөмкинлеге булмый. Һәм, бәлки, нәкъ менә шулар, ничек кенә аяныч булмасын, без белгән Глассны укмаштырып, оештырып биргәндер дә. Бәлки, ул хроникалар булмаса, «Койяанискаци»ның симфониясе дә булмас иде…

Именно в кинозале мы узнавали о войне. Я, восьмилетний, отчетливо запомнил, как после разгрома немцев американские солдаты вошли в концлагеря. Кадры, отснятые этими солдатами, демонстрировались в кинотеатрах по всем штатам. Никому и в голову не приходило, что эти материалы следует, так сказать, профильтровать, не было никаких предупреждений типа: «Впечатлительным людям просмотр фильма не рекомендуется». Смотришь кино и видишь груды человеческих костей. Видишь черепа. Видишь то, что увидели солдаты, войдя в ворота концлагерей, потому что кинооператоры шли прямо по пятам солдат.

«Җир тавышы» – әнә шундый билгеләмә бирүчеләр дә бар аның музыкасына. Филип Гласс истәлекләре аша, әйтерсең, төен төйнәп куя: безгә кадәр болай иде, ә менә монда, без яшәгәндә, шушылай булды, дип. Аның музыкаль полотносы, асылда, үзе яшәгән чорның хәтер полотносына тәңгәл. Ә ул хәтер белән алга таба безгә нәрсә эшлисе – анысына бары прогнозлар гына бар. Һәм кисәтү. Дөньяның көннән-көн югаларак, инде үз вәкилләре дә, әйтик, инглизчәгә алыштырып, кулланмый башлаган бер телендә: ko yaa nis qatsi.

Ә андыйлар – арта гына…

ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ: ТУГАН ЯК ҖИЛЕ...

Фотолар Галиевларның гаилә архивыннан алынды

Журналистлар белән аралашырга бик яратмый иде ул. Аны якыннан белмәгән кешеләргә бу бик аңлашылып та бетмәгәндер. Мин исә аның серен тыйнаклыкта күрәм. Берәр җөмлә белән мактап җибәрсәң: «Күпертмә, кирәк түгел», – дия иде. Сүзем – Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт абый Галиев турында. Исән булса, 20 ноябрьдә туксан яшь тулган булыр иде. Әмма Шәүкәт абыйның арабыздан китүенә дә җиде ел инде...

Автор:
Руфия Фазылова

ТУГАН ҖИРНЕ САЙЛАМЫЙЛАР...

Шәүкәт Галиевның «Шәвәли», «Камырша»ларын белмәгән кеше юктыр дип уйлыйм, инде берничә буын бала аның шигырьләрендә үсте. «Үлгәннәрнең каберен бел, исәннәрнең кадерен бел» кебек гыйбарәләре халыкның даими куллана торган канатлы сүзләренә әйләнде. Тик мин бу олуг шәхеснең иҗатына бәя бирергә алынмыйм, заман аның кем булуын инде үзе күрсәтте. Язмамда Шәүкәт абыйны, иң беренче чиратта, кеше буларак, туган җиренә бәйләп ачарга телим.

...Мөгаен, сүзне шуннан башларга кирәктер: Шәүкәт абый – минем авылдашым. Шуңа да минем хәтеремдә халык шагыйре белән бәйле истәлекләр шактый күп саклана. Шуларның берничәсенә тукталып узам.

Шәүкәт абый белән якыннан танышу 10 нчы сыйныфны тәмамлагач булды. Республика басмаларында мәктәп, авыл тормышына кагылышлы язмаларым басылып килә иде. Шәүкәт абый шуларны укыган булып чыкты. Авылның мәдәният йорты директоры

Шагыйрь Шәүкәт Галиев (Шәүкәт Галиулла улы Һидиятуллин) 1928 елның 20 ноябрендә Татарстан АССРның хәзерге Апас районы Олы Бакырчы авылында крестьян гаиләсендә туа. 1943 елда Олы Бакырчы җидееллык мәктәбен тәмамлый. Ике елга якын колхозда гади колхозчы, аннан бригадир ярдәмчесе һәм учетчик булып эшли. 1945–1949 елларда Кайбыч район бүлегендә – статист, аннары учет мөдире булып эшли. 1949 елның мартында «Колхоз бригадасы» район газетасы редакциясенә җаваплы секретарь итеп күчерелә, соңрак газета мөхәррире вазыйфасын башкара.

1953 елның көзендә Казанда – «Чаян» журналында башта – әдәби хезмәткәр, соңыннан бүлек мөдире була.

1954 елда «Яңа көйләр» исемле беренче китабы дөнья күрә. 1956 елда Эшче яшьләр кичке урта мәктәбен тәмамлый.

1958 елда СССР Язучылар берлегенә кабул ителә. 1959 –1961 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларны тәмамлый. «Яшь ленинчы» газетасы белән хезмәттәшлек итә. 1971–1984 елларда Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясенә җитәкчелек итә.

1972 елда «Шәвәли», «Кызык», «Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр», «Тәмле йорт», «Котбетдин мәргән» исемле җыентыклары өчен Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнә.

1982 елда рус теленә тәрҗемә ителгән «Заяц на зарядке» («Физзарядка ясый куян») китабы өчен Г. Х. Андерсен исемендәге Почетлы дипломга лаек дип табыла.

1995 елда күпкырлы иҗаты өчен «Татарстан Республикасының халык шагыйре» исеме бирелә.

1996 елда Татарстан Язучылар берлегенең А. Алиш исемендәге әдәби бүләгә тапшырыла.

Шәүкәт Галиев – балалар өчен егермедән артык китап авторы. Алар арасында «Камырша» (1962 ел), «Көлке булмәсе» (1967), «Шалт, Мөхәммәтҗан!» (1970), «Мыеклы бозау» (1973), «Тылсымлы көзге» (1974), «Камырша» (1962) кебек китаплар бар.

Ун китабы рус теленә тәрҗемә ителгән. «Витаминлы хәрефләр» – башкорт, «Тылсымлы көзге» инглиз телләрендә дөнья күргән.

1

1. Шәүкәт Галиев иҗатташлары белән.

2. Гаиләсе белән. 1995 ел.

Гөлфия апа Идиятуллинага (шагыйрьнең туганы): «Руфия минем янга килсен әле», – дигән. (1998 елда, 70 яшьлек юбилее уңаеннан, Олы Бакырчыда шагыйрьнең туган нигезе янәшәсендә иҗат йорты төзеделәр. Шәүкәт абый, мәрхүм булганчы, ел саен җәйләрен шунда кайтып яшәде). Мин инде, Гөлфия апа сүзләреннән соң, очып диярлек килдем Шәүкәт абый янына. Юл буе ничек исәнләшергә, сүзне кайдан башларга дип уйлап барган идем, Шәүкәт абыйны күргәч, җиңел сулап куйдым. Дәү әтиләрчә, гади генә, әмма рәхәт, тәмле итеп сөйләште. «Мәкаләләр дә, шигырьләр дә язам» – дип, аңа бер дәфтәремне суздым, баргач. Аеруча менә шул сүзләре истә калган: «Ә кайсын язу җиңелрәк?» – дип сорады шагыйрь абый. «Мәкаләне, – дим. – Шигырь теләсә кайчан тумый, илһам килгәнен көтәргә кирәк, ә менә мәкаләне утырам да язам». «Сиңа алайса журналистикага барырга кирәк, көчләп шигырь язып булмый...» Шушы сөйләшүне хәзер кайта-кайта уйлыйм: шигырьләрем чиле-пешле булса да, үземә бу хакта әйтмәгән, ә җайлап кына дөрес юлга бастырган. Шәүкәт абыйның киңәшен тоттым – журналистика факультетына укырга кердем...

Истә калган тагын бер вакыйга, дөресрәге – сабак. Университетның өченче курсын тәмамлап, җәйге

2

1. А.Алиш музеенда укучылар белән очрашу. 1982 ел.

практика узарга район газетасы «Йолдыз»га кайттым. Шунда «Елар иде һәйкәлләр!» дип исемләп, авыл егетләренең клубтан соң һәйкәл янында кәеф-сафа коруларын яздым. Озак та үтмәде, сөйләшәсе бар, дип, Шәүкәт абый үз янына чакырды: «Руфия, сеңлем, туган авылыңны пычрату килешми. Син аны соңрак, олыгая башлагач, аңларсың әле, – диде. – Син ул егетләрнең үзләренә әйт, ләкин газета аша бөтен районга кычкыру бер дә матур әйбер түгел. Гаиләдә дә төрле хәлләр була, шулай да өйдәгесен тышка чыгармыйлар. Аннан, нинди генә булсалар да, алар синең авылдашларың. Әти-әнине сайлап алмаган кебек, авылдашларны, туган җирне дә сайлап алмыйлар. Ике-өч егетнең һәйкәл янында кәеф-сафа корулары ул бит әле барлык егетләр дә шундый диген сүз түгел».

Ул вакытта шагыйрь алдында оят булган иде. Шәүкәт абыйның ни өчен болай әйтүен соңрак аңладым. 1970 нче елларда ул туган авылына бер дә кайтмаган. Үзе исән чагында бу турыда сорарга кыенсындым. Шагыйрьне якыннан белгән авылдашлары Шәүкәт абыйның Олы Бакырчыга дистә еллар кайтмавын төрле сәбәпләргә бәйли. Ничек кенә булмасын, туган авылына хәтере калган була, монысы хак. Шагыйрьнең авыл китапханәсе турында шигыре бар. Ул анда саргаеп яткан китапларны кызганып, китапханәне кеше йөрми торган урын, дип атый. Шигырьдә Олы Бакырчы китапханәсе турында сүз бара, диләр. Шәүкәт абыйның: «Авылыңны пычрату килешми. Син аны соңрак, олыгая башлагач, аңларсың», – диюе дә, бәлки, шуның белән бәйле булгандыр...

ШАГЫЙРАНӘ ЯРАТУ

«Инеш буенда бер кыз каз бәбкәләре саклап утыра. Оялудан, каушаудан йөгереп киттем». «Минем беренче гомерем» китабында Шәүкәт абый Фәридә апа белән тәүге очрашуы турында шулай дип яза. Күрәсең, шагыйрәнә мәхәббәт шулай башланырга тиештер. Алар бер-берсен биш яшеннән бирле белә. Сигез ел бер парта артында утыралар, аннан яшьлек еллары, сугыштан соңгы авыр заманнар бәйли аларны. Бик күп тормыш сынауларын узып, ике йөрәк барыбер кавыша һәм соклангыч гомер итә.

Шәүкәт абыйларның дүрт бүлмәле фатирларында еш була идем. Бу нигезнең әйтеп бетергесез җылы нуры барлыгын хәтерлим. Шәүкәт абый сине ишек төбенә үк чыгып каршы ала. Аннан ипләп кенә кулыңдагы сумкаңны алып куя, өс-башыңны салырга ярдәм итә. Аягыңа чүәкләр суза. Ул да түгел, аш бүлмәсеннән кояш кебек балкып Фәридә апа килеп чыга. «Әйдә, уз, сагындык...» Син үзеңне иң якын кешеләреңә килгән кебек хис итәсең! Монда икейөзлелек, ясалмалык юк, алар нинди бар, шундый – зыялы, итагатьле, ачык күңелле.

Бер мин генә яңалык ачмам, Шәүкәт абыйларда булган һәркем Фәридә апаның гаять уңган хуҗабикә икәнен искә ала. Аның өстәлендә ризыгы гел әзер булыр. Алай гына да түгел, ул ризык һәрчак үзенә бер төрле, башкаларныкына охшамас. Савыт-сабага аерым бер мөнәсәбәт иде аларда: аш тәлинкәсе белән чынаяклар да бер, шикәр савыты да шундый ук. Кашык, чәнечкеләрне шул затлы савыт-саба янына кафе-рестораннардагы кебек тезеп куя хуҗабикә.

Тагын бер күзәтү: ир белән хатын, теге яки бу вакыйга турында сөйләгәндә, һәрвакыт бер-берсен хөрмәт белән телгә ала. Гади генә мисал. Яшь гаилә Казанда башта бер тулай торактан икенчесенә күченеп йөри. Фәридә апаның сөйләгәне истә калган: «Уналты квадрат метрлы бүлмәдә Шәүкәтнең әнисе, сеңлесе, балалар – барыбыз бергә яшәдек. Әле бит авылдан әллә никадәр кеше килә, кунарга безгә керәләр. Барыбыз да идәнгә тезелеп ятабыз, аяк атларга урын да калмый. Тик барыбер шул чаклар сагындыра...»

Шәүкәт абый исә тормыш иптәшенә тирән бер соклану белән карап ала да, шулай ук сүзгә кушыла: «Мин Фәридәгә бик рәхмәтле. Егерме алты ел әни белән яшәдек, Фәридә аны карады, тәрбияләде. Мәктәптә балалар укытса, өйдә үз балаларыбызга белем, тәрбия бирде. Кем генә килсә дә, берәүгә дә караңгы йөз күрсәтмәде. «Олы Бакырчыдан без», – дип, бер күрмәгән кешеләр килеп керерләр иде. Фәридә аларны кунак итеп, кундырып чыгара. Болар бит барысы да хатын-кыздан тора. «Йөрмәсеннәр», – дисә, ир-ат бер нәрсә дә эшли алмый.

«БЕР-БЕРСЕ ӨЧЕН ТУГАННАР...»

Шәүкәт абый белән Фәридә апа дүрт бала – ике ул, ике кыз тәрбияләп үстергән. Җәмил абый белән Алсу апа – хәзер Казанда, гаиләләре белән яшиләр. Җәүдәт абый – Американың Миннесота штатында, Җәмилә апа Уфада төпләнеп калган. Балаларына язучылык сәләте күчмәсә дә, әти-әниләреннән затлы сыйфатларны алганнар. Барысы да укымышлы, белемле. Алсу апа Яр Чаллы шәһәрендә яшәгән, белгечлеге буенча биолог, лаборант булып хезмәт куйган.

Шагыйрьнең әтисенә фронка язып, кире әйләнеп кайткан хаты:

«...Әти, үзебез исән-сау, килгән хатларыңнан укып, сине дә исән-сау дип беләбез. Исән-сау кайтып, бергә тигезлек, шатлык белән күрешүне Аллаһтан сорап калабыз. Әткәй, моннан алда хат белән карточка җибәрдем, насыйп булса, алырсың.

Әткәй, быел сыер кысыр калды. 14 тавыгыбыз бар. Бер сарыгыбыз бар, берсе зарарланган иде, суйдык. Аның ике бәрәне калды. Ике тәкәнең берсен иткә бирдек. Үзем 2 мең кирпеч суктым, әле дә эштән туктамадым. Хәзер ясмык чыгабыз. Быел игеннәр яхшы. Әнкәй умарта иле җыйган иде. Бүген карадык, балы күп чыкты, җиде рамына «бала салган», калганнарын алдык.

Их, әткәй, син генә юк. Синең өчен генә кайгырабыз. Әнкәй инде сиңа дип бал алып куйды. Анысына тимибез, сине көтә.

Әткәй, үзең нишләп ятасың? Мин укуны дәвам итәргә телим. Син дә шулай дия идең. Әткәй, хуш, сау бул. Сәлам белән, улың Шәүкәт.

7 июль, 1943 ел».

Җәмилә апа да – биолог. Җәмил абый белән Җәүдәт абый – физиклар. Җәмил абый күп еллар Казан дәүләт химия-технология институтында лаборатория җитәкчесе булып эшли, күп фәнни хезмәтләр авторы. Җәүдәт абый Миннесота тикшеренү университетында укыта, зур дәрәҗәләргә ирешкән шәхес.

Казанда булганлыктан, Җәмил абый белән күрешкәлибез. Мин аны нәкъ Шәүкәт абыйга охшатам. Шундый ук тыйнак, акыллы, зыялы. Әти-әнисен ул һәрвакыт бер җылылык, ихтирам белән искә ала:

– Әти кырыс кеше түгел иде, безгә карата да артык катылык күрсәтмәде. Иҗат кешесе булгач, иҗатына игътибары зур иде. Дөньядагы иң мөһим хәбәрләрне, ил-көн хәлләрен, әлбәттә, әти белә иде. Ә өй-мәктәп тирәсендәге борчулар, проблемалар, булса да, әнидән узмады. Күрәсең, тынычлап иҗат итсен, дип, аның әтине борчыйсы килмәгәндер. Әти безгә беркайчан да кул күтәрмәде, сирәк кенә ачулана иде. Мәктәптә барыбыз да яхшы укыдык. Дүртебез дә Казанның 89 нчы татар мәктәбен (хәзер Галимҗан Ибраһимов исемендәге 17 нче татар гимназиясе. – Авт.) тәмамладык. Классташларыбыз, дус-ишләребез әтинең шагыйрь икәнен белсә дә, үзебез моның белән беркайчан да масаймадык. Дәү әниебез генә, тормышта берәр гаделсезлек күрсә: «Минем улым «Чаян» журналында эшли, әйтеп яздырам әле», – дия иде. Сүздә генә кала иде инде ул, билгеле.

Җәмил абый белән Алсу апа ел саен, Олы Бакырчыга Шәүкәт абыйның музеена кайталар. (Шагыйрьнең вафатыннан соң иҗат йорты музейга әйләнде). Олы Бакырчы төп белем бирү мәктәбе Шәүкәт Галиев исемен йөртә, балалары, кайтканда, анда да керми калмый.

– Әти соңгы елларда Олы Бакырчыда гына шигырь яза алам, – дия иде. – Шуңа да җәй саен туган авылына ашкынды. Иртән-иртүк торып, Дымбылат чишмәсе буйларын урый. «Көч алып кайтам», – дип әйтә иде. Олы Бакырчы туган авылыбыз булмаса да, якын ул безгә. Тамырлар шунда бит...

2. Тормыш иптәше Фәридә ханым белән.

Ни кызганыч, Шәүкәт абый вафатыннан соң, бер генә китабы дөнья күрде. «Шәвәли шуклыгы» дип атала ул. Анда шагыйрьнең балалар өчен язган соңгы шигырьләре тупланган. Тагын шунысы кыйммәтле: монда Фәридә апаның да күңел җылысы кергән. Эш менә нәрсәдә: Шәүкәт абый вафат булганнан соң, аның кулдан язган дистәләгән шигырьләре, истәлекләре калган. Фәридә апаның хыялы – шуларны китап итеп бастыру була. Шуның өчен ул компьютерда җыярга өйрәнә. Бу хакта Алсу апа бик озаклап сөйләде:

– Әни әтине бик сагынды. Алар бит кибеткә дә икәү йөргән кешеләр, берсеннән берсе калмадылар. Сагынуын басар өчен, дипме, бурычы санапмы, әтинең кулдан язган шигырьләрен җыярга утырды. Сиксән өч яшендә бит, күзләре дә бик яхшы күрми. Алны-ялны белми, шуларны җыйды. Аш бүлмәсенә чыгып тамак ялгый да яңадан әтинең эш бүлмәсенә кереп китә. Язмышмы, башкамы, әйтә алмыйм: эшен тәмамлаганнан соң, берничә көннән әни якты дөньядан китеп барды.

Әни әтине яратты гына түгел, ул аны күкләргә чөйде. Гел аны саклады, кайгыртты. «Әтиегез эшли, тыныч кына торыгыз!» – шушы сүзне ишеткәч, өйдә чебен очкан тавыш та чыкмый иде. Ул чагында әти халык шагыйре дә түгел, «Чаян» журналында эшләп йөрүче гади бер хезмәткәр. Акчасы

1. Рәшит Гыйльметдинов, Шәүкәт Галиев музее җитәкчесе, шагыйрьнең туганнан туган энесе: «Шагыйрьнең вафатыннан соң туган авылына кайтарылган шәхси әйберләре – өс киеме һәм стена сәгате».

2. Олы Бакырчыдагы Шәүкәт Галиев музее.

да әллә ни булмагандыр. Әмма әни әтинең бөеклеген, даһилыгын шул чагында ук күргән. Иҗат итәр өчен аңа барлык мөмкинлекләрне тудырган...

...Кая гына барсам да, горурланып: «Мин Шәүкәт Галиев туган авылдан», – дим. Әйе, ул безнең якның зур шәхесе. Безнең якның гына да түгел, ә татар дөньясының күренекле улы. 1998 елда, шагыйрьнең 70 яшьлек юбилее алдыннан авылда ике катлы мәдәният йорты төзелеп бетте, асфальт юл керде. Соңрак, 2011 елда, ике катлы заманча мәктәп төзелде. Бала саны аз дип, мәктәпне япмауларын да бакырчылылар Шәүкәт абый исеме белән бәйли. «Әле ярый Шәүкәт абый булган», – диләр. Аның шигърияте, туган ягына багышлап язылган кадерле юллары турында әйтеп торасы да юк. Аларны без яттан беләбез.

«ОСТАЗЫМ ИДЕ»

Роберт Миңнуллин, шагыйрь:

– Шәүкәт Галиев белән танышуым бик кызык булды. «Яшь ленинчы» газетасында бер кочак шигырьләрем басылган иде. Шул көнне Матбугат йортына килдем. Каршыма Шәүкәт абый очрады: «Роберт, энем, шигырьләреңне укыдым, бик шәп. Киләчәгең өметле», – дип аркамнан сөйде. Миңа гүя канатлар үсте. Менә шуннан Шәүкәт Галиев исемле безнең чорның бөек шагыйренә сыенырга тырыштым.

Балалар шагыйре булу – бик зур җаваплылык. Моны һәркем булдыра алмый. Тукай, Барый Рәхмәт – һәр заманның үз бөекләре булган. Безнең заманда, һичшиксез, Шәүкәт абый Галиев булды. Ул миңа буй җитмәслек шагыйрь кебек иде. Якыннан аралаша башлагач, тыйнаклыгын, зыялылыгын күреп янә хөрмәтем артты. Ул минем беренче китабымны нәшер итәргә, Язучылар берлегенә керергә тәкъдим иткән кеше.

Гәрчә Шәүкәт абый әдәбиятка балалар шагыйре булып кереп калса да, аның олылар өчен дә бик затлы шигырь, тирән фәлсәфи мәгънәле афоризмнар җыентыклары бар. Үзе атаганча, «канатлы сүзләр»ендә никадәр тирән мәгънә ята...

Шәүкәт абыйны әтием урынына күрдем. Шулай да шагыйрьнең иң якын дусты – Илдар Юзиев иде. Моны тәгаен әйтә алам. Ә мин аның өчен укучысы, дусты, соңрак, бәлки, ярдәмчесе дә булганмындыр. Гаиләләр белән дус булдык. Фәридә апага чын татар хатыннарында була торган сабырлык, тугрылык, кунакчыллык сыйфатлары хас иде. Бу ике кеше, һичшиксез, бер-берсе өчен туган, бер-берсенә чынлап торып гашыйклар иде. Юксынам Шәүкәт абыйны...

«КАЙТАМ, ВӘГЪДӘ!»

Рәшит Гыйльметдинов, Апас районы Олы Бакырчы авылындагы Шәүкәт Галиев музее җитәкчесе, шагыйрьнең туганнан туган энесе:

– Шәүкәт абыйның әнисе белән минем әти – бертуганнар. Шул истә калган: 1961 елның 12 апрелендә, Гагарин космоска очкан көнне, Казанда Шәүкәт абыйларда идем. Ул көнне телевизордан гел шуның турында гына сөйләделәр. Без бит авыл балалары, телевизорны көн саен карамыйсың, чөнки ул һәр кешедә юк. Ләкин телевизордан бигрәк мине икенче нәрсә кызыктыра: Җәүдәт белән Җәмилнең велосипеды бар. Казанга килгәч, миңа да биреп торалар. Гагарин урамы буйлап тимер атта җилдерә идек. Аның рәхәтлеге! Шәүкәт абыйның безгә бер тавышланып эндәшкәнен хәтерләмим. Фәридә апаның исә кунакчыллыгы истә калган. И сыйлый иде...

1980 нче елларда безнең аралар өзелеп торды. Телефоннан аралашсак та, бик күрешелмәде. 1982 елда Җәүдәт белән очраклы гына поездда очрашып, Шәүкәт абыйларга киттек. Минем бертуган абыем Фарук Казанда хастаханәдә ята иде, аның хәлен белергә Шәүкәт абый да барды. Таң атканчы, Шәүкәт абый белән сөйләшеп утырдык. «Бер дә авылга кайтмыйсың», – дигәч: «Тормыш басты шул. Туган якны онытырга ярамый, кайтам, вәгъдә», – дип калды ул. Гаеп бездә дә булгандыр: төп нигезе юк бит, чакырмагач, үзе кайтырга яхшысынмагандыр... Шуннан мин аны үземнең юбилеема чакырдым. Фәридә апа белән кайттылар. Шул рәвешле аралар якынайды.

Бүген Шәүкәт Галиев музеен җитәкләү минем өчен шатлык та, зур җаваплылык та. Монда керәм дә стенадагы дистәләгән туганнарымның портретларына текәләм. «Нәселне сакла, йөзгә кызыллык китермә», – дип әйтәләрдер төсле тоела...

Хәлдән килгәнчә, тырышам. Әле менә Шәүкәт абыйның юбилеена, дип, музейны яңарттык. Бакча тирәләрен тоттык. Үз акчама сатып алып, йортның стеналарын буядым...

«ЗУР КЕШЕ ЧЫГАР, ДИП УЙЛАДЫК...»

Вәгыйзь Вилданов, шагыйрьнең классташы:

– Шәүкәтнең әтисе Галиулла абый бик укымышлы кеше иде. Авыл кибетендә сату итте. Шәүкәт, әтисенә охшаптыр, бик башлы малай булды. Гел китаплар укыды. Шул вакытта ук аннан зур кеше чыгар, дип уйладык. Бүтәнчә, бездән аерылып тора иде ул. Без 5 нче сыйныфны бетергән елны сугыш башланды. Мәктәпкә, авылдагы һәр гаиләгә окоп казучыларны керттеләр. Шулай да укуны тәмамладык. Әтиләр, абыйлар сугышка киткәч, ат та җиктек, җир дә сөрдек. Шул исәптән Шәүкәт тә. Аннан Галиулла абыйның «хәбәрсез югалган» дигән хәбәре килде. Шәүкәт шул вакытта боегып калды. Тормыш йөге аңа төште, әнисе, сеңлесе яшь малай карамагына калды. Менә шул вакытларда Шәүкәт шигырьләр яза башлады да кебек.... т

МАХСУС ПРОЕКТ

— 36нчы чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

Алексей Песошин,
ТР Премьер-министры, декабрьдә 55 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Фото ТР Хөкүмәте сайтыннан алынды

Альберт Шиһабетдинов,
«ТАИФ» АҖ
генераль директоры

Хөрмәтле Алексей Валерьевич!

Һәрбер кеше туган республикасы, ягъни безнең уртак йортыбыз тарихына үз өлешен кертә. Сезнең кебек талантлы, инициативалы, җәмгыять иминлеге хакына армый-талмый хезмәт итәргә әзер кешеләр күбрәк булган саен, «вакыт китабы»ның онытылмаслык сәхифәләре дә арта бара. Истәлекле юбилеегыз көнендә «ТАИФ» Компанияләр төркеменең күпсанлы коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне туган көнегез белән ихластан котлыйм һәм иң изге теләкләремне җиткерәм! Татарстанда һәм аннан читтә дә Сезне абруйлы дәүләт эшлеклесе, югары класслы һөнәр иясе, социаль тормыш һәм икътисад кебек өлкәләрдә белемле, эрудицияле, интуицияле, мөһим бурычларны хәл иткәндә перспективаларны күрә торган кеше буларак беләләр. Озак еллар буена җаваплы вазыйфаларда эшләп, Сез үзегезне оста оештыручы итеп танытгыгыз, республика үсешенә, татарстанлыларның тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлтелгән эшчәнлегегездә зур уңышларга ирештегез. Сезнең шәхси һәм эшлекле сыйфатларыгыз: актив гражданлык позициясе, кат-кат уйлап, дөрес карарлар кабул итү осталыгы, командада эшли белү, идарә итүдә алдынгы тәҗрибәләрне өйрәнеп, куллана алу сәләте. Әлеге күркәм сыйфатларның алга таба да олы планнарыгызны һәм уй-ниятләрегезне тормышка ашырырга ярдәм итәчәгенә ышанам.

Алексей Валерьевич, Сезгә чын күңелдән озак елларга сузылган ныклы сәламәтлек, шатлык һәм рух ныклыгы, гаилә тормышында иминлек, игелек һәм тыныч күк йөзе телим! Сезгә хас энергия, тормышны ярату, хезмәт сөючәнлек сыйфатлары беркайчан да кимемәсен, алдагы уңышларыгызга һәм өзлексез шәхси үсешегезгә һәрвакыт этәргеч булып торсын.

Бөек рус язучысы һәм акыл иясе Федор Михайлович Достоевскийның мондый сүзләре бар: «Бәхет – бәхетнең үзендә түгел, ә аңа ирешү юлында». Сезнең бәхетле кеше булуыгызны телим! Ирешелгәннәрдә туктап калмыйча, республика һәм илебез иминлеге хакына яңа үрләр яулап, алга баруыгызны дәвам итегез!

Реклама

Фото «ТАИФ» АҖннан алынды



Уңышлы эшләүне тәэмин итеп



Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго» АҖ
генераль директоры

Реклама

Фото «Татэнерго» АҖ матбугат хезмәтеннән алынды

– Хөрмәтле Алексей Валерьевич! «Татэнерго» АҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз белән ихластан котлыйм. Сезнең хезмәттәшләрегез, депутатлар корпусы һәм муниципаль берәмлекләр белән бердәм команда булып, җиренә җиткереп эшли белүегез, анык нәтиҗәләргә йөз тотуыгыз республика Хөкүмәте эшчәнлегенең уңыш нигезе булып тора. Сез бар эштә алдыгызга югары максатлар куясыз, һәм бу Сезгә Татарстан икътисадының алга таба тотрыклы үсешен тәэмин итү, республикада яшәүче һәрбер кешенең тормыш сыйфатын күтәрү буенча катлаулы бурычларны нәтиҗәле итеп башкарырга мөмкинлек бирә. Нәкъ шундый эшлеклелек республикабызны ил төбәкләре арасында алдынгы итә дә. Һичшиксез, республика Президенты бүгенге җиңел булмаган икътисадый шартларда Хөкүмәт алдына куйган амбицияле максатларга ирешер өчен килеп чыккан проблемаларга һәм тәвәккәллекләргә үз вакытында, зур уяулык белән җавап бирергә кирәк. Шуңа да без хакимиятнең барлык буыннарының җайлы, төгәл эшләвен оештыруның ни дәрәҗәдә катлаулы булуын күз алдына китерәбез. Һәм Сез, Хөкүмәт җитәкчесе буларак, бу эшне искиткеч яхшы итеп башкарасыз!

Әлеге уңышлар Сезгә киләчәктә дә һәртөрле башлангычлар вакытында юлдаш булсын! Сәламәтлек, иминлек һәм илһам телибез!

Үсеш энергиясе



Ринат Ханбиков,
«Газпром межрегионгаз Казан» АҖ
генераль директоры

Реклама

Фото «Газпром межрегионгаз Казан» АҖ матбугат хезмәтеннән алынды

– Көндәлек ыгы-зыгы эчендә туган ягыбызның иминлеге һәм чәчәк атуы хакына бөтен көчен, егәрен һәм белемнәрен биргән кешеләргә лаеклы бәя һәрчак үз вакытында бирелми калырга да мөмкин. Юбилей – моның өчен менә дигән форсат. Алексей Валерьевич, Сезне чын күңелдән 55 яшьлек бәйрәмегез белән тәбрик итәм! Республиканың Премьер-министры буларак, Сез Татарстанның икътисади үсешенә кагылышлы бик күп актуаль мәсьәләләрне хәл итәсез, дәүләт предприятиеләре һәм бизнес үсешенә өзлексез рәвештә булышлык күрсәтеп торасыз. Дәүләтнең максатлы программаларын эшләүдә һәм аларны гамәлгә ашыруда актив катнашасыз. Мондый күләмле эшләрне Сез идарәчелек эшендәге олы тәҗрибәгезгә таянып башкарасыз.

Бүген республика Хөкүмәтенең тырышлыгы нәтиҗәсендә Татарстанда сәнәгать шәһәрләренең купструктуралылык проблемасы уңышлы хәл ителә, Яр Чаллы, Түбән Кама, Яшел Үзән, Чистайдагы алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре уңышлы эше күзәтелә. Без Сезнең газ хезмәткәрләре проблемаларына игътибарлы булуыгызны аеруча югары бәялибез. Газ куллану буенча түләү тәртибен ныгыту мәсьәләләрен хәл итүдә даими ярдәмегезне тоеп торабыз – бу исә Татарстан Республикасын табигый газ белән тотрыклы рәвештә тәэмин итү өчен гаять мөһим. Алексей Валерьевич, Сез кешеләрне алга әйдәүче көчкә ия. Алга таба да ныклы сәламәтлек, алдыгызга куйган планнарны тормышка ашырганда уңышлар һәм көч-куәт юлдаш булсын!

Тулаем бирелгәнлек таләп итә торган эш

– Хөрмәтле Алексей Валерьевич, күркәм бәйрәмегез көнендә Сезне үз исемемнән һәм «Аммоний» АҖ коллективы исеменнән чын күңелдән котлыйм. Сезгә бөтен өлкәдә дә иминлек телим!

Сезнең бай идарә итү тәҗрибәгез, максатчанлыгыгыз, заманча икътисадый процессларны тирәнтен аңлап эш итүегез, республиканы үстерү буенча төрле өлкәләрдә башкарган гамәлләрегез тотрыклы алгарышка китерер, дип ышанабыз. Моңа ачык дәлил – Татарстандагы территорияләр белән тармакларның балансны рәвештә камилләшүләре. Махсус икътисадый зоналардагы инфраструктураның үсеше белән беррәттән, индустриаль парклар һәм технопарклар да үсеш кичерә. Урта һәм кече эшкуарлык та бүген җитди үсеш потенциалы күрсәтә. Төбәкара тулай продуктның күләме күзгә күренеп үсә, икътисадый һәм иҗтимагый күрсәткечләр – шулай ук. Әлбәттә, биредә Сез җитәкләгән республика Хөкүмәтенең өлеше чиксез зур. Бу олы җаваплылык һәм көч, тулаем бирелгәнлек таләп итә торган көндәлек четерекле эш. Аның нигезендә Сезнең татарстанлылар тормышын яхшыртырга тырышуыгыз ята.

Сезгә чын күңелдән ныклы сәламәтлек, бәхет, тормыш иминлеге телим. Һәрбер көн Сезгә яхшы хәбәрләр генә алып килсен! Яңа проектлар һәм перспективалар насыйп булсын!

Тимур Алиев, «Аммоний» АҖ генераль директоры

Фотолар «Аммоний» АҖ матбугат хезмәтеннән алынды

Реклама

Республиканың яңарышы һәм алгарышы хакына

Гадел Хөснетдинов,
«Татинвестгражданпроект» ДУП генераль директоры

Хөрмәтле Алексей Валерьевич!

«Татинвестгражданпроект» ДУП һәм шәхсән үз исемемнән Сезне 55 яшьлек юбилеегыз белән тәбрик итәм!

Татарстан Республикасы соңгы елларда, яңа сынауларга таба йөз тотып, үсеш ноктасын билгеләде һәм аңа иреште дә. Төбәкнең тотрыклы иҗтимагый-икътисадый үсеше, гражданнарның яшәү шартлары һәм сыйфаты яхшыру нәтиҗәсендә нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте халык алдында да зур ихтирам казанды.

Төбәктә эре төзелеш проектлары тормышка ашырыла, инвестицияләр эшчәнлеге өчен уңай шартлар тудырыла, эшлекле һәм иҗтимагый инфраструктура яңарыш кичерә, кешеләрнең яшәү сыйфатын яхшыртуга зур игътибар бирелә.

Хөрмәтле Алексей Валерьевич, Сезнең эшкә булган искиткеч сәләтегез, перспективаны тулаем күрә белүегез һәм, иң катлаулы проблемалар килеп туганда да, аларны хәл итәр өчен, булган ресурсларны эшкә җигә белүегез туган Татарстаныбыз үсеше хакына башкарылган актив һәм уңдырышлы эшчәнлекнең тотрыклы нигезе булып тора!

Сезгә алдыгызга куйган планнарны һәм үтәләсе бурычларны тормышка ашыруыгызны теләп калабыз. Ныклы сәламәтлек һәм иминлек Сезгә!

Реклама

Фото «Татинвестгражданпроект» ДУП матбугат хезмәтеннән алынды

Планнарыгыз тормышка ашсын!

Газинур Әхмәтов,
«Ак таш» ЖЧЖ директоры

Фото «Ак таш» ЖЧЖнннән алынды   Реклама

– Хөрмәтле Алексей Валерьевич! Сезне «Ак таш» ЖЧЖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз белән тәбрик итәм! Бу Сезгә булган рәхмәтебезне һәм хөрмәтебезне җиткерү өчен менә дигән форсат. Сез республиканың социаль-икътисадый үсешенә бәһасез өлеш кертәсез, халык мәнфәгатьләрен яклап, зур тырышлыклар куясыз.

Сәнәгать, төзелеш, авыл хуҗалыгы предприятиеләренең җитәкчеләре һәм эшчеләре, бизнес вәкилләре белән даими рәвештә очрашып торуыгыз Сезгә аларның мәнфәгатьләре һәм перспективалары белән танышып бару мөмкинлеге бирә. Республиканың премьер-министры боларның барысын да ишетеп кенә түгел, ә үз күзләре белән күреп белә икән, димәк, ул вазгыятьне объектив рәвештә анализлый, төбәк икътисады үсешен нәтиҗәле планнар һәм конструктив эшләр белән тәэмин итә ала дигән сүз. Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең партнеры буларак һәм даими рәвештә дәүләт программаларын гамәлгә ашыру эшендә катнашып, безнең предприятие һәрвакытта да Сезнең белән уңышлы хезмәттәшлек итә. Алга таба да өстенлекле бурычларны бергәләп чишәрбез, республика халкы тормышы имин-мул булсын, туган ягыбыз икътисады гөрләп үссен өчен дөрес карарлар кабул итәрбез, дип ышанам.

Алексей Валерьевич! Сезгә планнарыгызның тормышка ашуын телим, җаваплы эшегезнең нәтиҗәләре бары тик уңай хисләр генә китерсен. Иминлек, илһам, ныклы сәламәтлек һәм бәхет юлдаш булсын!

Яшәү урыны туган йортка әверелсен, дисәң

Александр Поливин,
«Совет районы Район торак идарәсе» Идарәче компаниясе» ЖЧЖ җитәкчесе

Фото «Совет районы Район торак идарәсе» Идарәче компаниясе» ЖЧЖ ннән алынды   Реклама

– Хөрмәтле Алексей Валерьевич, Сезне «Совет районы Район торак идарәсе» Идарәче компаниясе» ЖЧЖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз белән котлыйм! Юбилей – игелекле эшләрегез өчен рәхмәтебезне һәм хөрмәтебезне белдерү өчен менә дигән форсат. Сезгә хас булган максатчанлык һәм перспективага эшли белү сәләте алга таба да республика тормышын яхшырту өчен кыю һәм киң күләмле проектларны гамәлгә ашырырга ярдәм итсен. Сез Татарстан өчен, анда төзелеш, сәнәгать, сәламәтлек саклау, мәгариф, спортны лаеклы үстерү өчен бик күп эшләр башкардыгыз...

Сезнең тырышлыклар һәм Хөкүмәт командасының эше җавапсыз калмый. Соңгы елларда торак микрорайоннарының, юлларның ничек үзгәрүен, спорт һәм мәдәният объектларының күпләп ачылуын күреп, татарстанлылар үзләре яшәгән йортларга һәм ишегалларына башкача карый башлады. Ул хәзер алар өчен яшәү урыны гына түгел, ә туган йорт! Озак вакыт җитәкче урыннарда, шул исәптән үз вакытында Совет районы хакимиятендә эшләп, Сез шәһәр территорияләрен комлексы төзекләндерүнең ни дәрәҗәдә мөһим булуын яхшы беләсез. Республика башкаласы өчен генә түгел, ә башка шәһәрләр өчен дә әһәмиятле мәсьәлә бу. Бүген боларга ишегалларын төзекләндерү буенча Президент программасы гамәлгә ашырылуы нәтиҗәсендә ирешелде. Программаны тормышка ашыру – Сезнең зур казанышыгыз.

«Татарстан Республикасының Үзәк депозитарие» АҖ – республиканың Җир һәм милек мөнәсәбәтләре министрлыгы карамагындагы барлык кыйммәтле кәгазьләрне номиналь рәвештә саклаучы.

ВАКЫТ БЕЛӘН СЫНАЛГАН ЫШАНЫЧ

Финанслар базарындагы уенчыларны һәрвакыт ышанычлылык җәлеп итте, итә һәм итәчәк. Бу ышаныч белән аларны «Татарстан Республикасының Үзәк депозитарие» АҖ 25 ел дәвамында тәэмин итә. Әлеге оешма дәүләт кыйммәтле кәгазьләр портфеле белән идарә итү процессының мөһим һәм аерылгысыз өлеше булып тора.

25 ЕЛ: КӘГАЗЬДӘН – ЦИФРГА

90 нчы еллар... Ул вакыттагы билгесезлек, акчасызлык һәм гомуми бартер чорын кем генә хәтерләми икән? Нәкъ шул чакта, 1993 елның октябрендә, Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Указына ярашлы рәвештә ТРның исәп-депозит системасы нигезе булган Үзәк депозитарий оештырыла. Депозитарийга республикада хосусыйлаштыру процессында акцияләргә шәхси милек хокукын рәсмиләштерү һәм кыйммәтле кәгазьләр әйләнешен исәпкә алуның бердәм системасын оештыру бурычы йөкләнә. Россиянең кыйммәтле кәгазьләр базары оешканда, бу республиканың тотрыклылыгын һәм иминлеген тәэмин итү буенча төп коралларның берсе була. Ул социаль яктан әһәмиятле предприятиеләрне генә түгел, тулаем республиканың икътисадый базасының милек активларын да саклап калырга булыша. Соңрак кыйммәтле кәгазьләрнең документ булмаган формасына күчү тәэмин ителә.

НОН-СТОП РЕЖИМЫНДАГЫ ЭШ

Рөстәм Сәгыйть улының кыйммәтле кәгазьләр базарындагы эш тәҗрибәсе 15 елдан артыграк. «Татарстан Республикасының Үзәк депозитарие» АҖ командасына Харьков югары хәрби авиация училищесын тәмамлаган очучы егет 2009 елның маенда килеп кушыла. Республиканың Үзәк депозитарие барлыкка килгәндә, кайчан да булса кыйммәтле кәгазьләр базарына килеп чыгармын дип уйламаган да ул – 1991–2004 нче елларда РФ Хәрби һава көчләрендә хезмәт иткән. 2004 елда Ибраһимов республиканың дәүләт милеге белән идарә итү системасында Казан шәһәре хакимиятенең Коммуналь милек белән идарә итү комитетында мәгълүматлаштыру бүлеге башлыгы булып эшли башлый. 2006 елдан Казан Башкарма комитетының җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты рәисе урынбасары вазыйфаларын башкара. 2007 елда Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте институтын тәмамлый.

– Хәзерге заман – югары технологияләр дөньясы ул. Һәм ул технологияләр, шул исәптән бездән – Үзәк депозитарий хезмәткәрләреннән дә, үз өстебезгә элеккегә караганда да күбрәк йөк тартуны һәм өзлексез рәвештә бурычлар хәл итүне таләп итә. Чирек гасыр дәвамында акцияләрнең дәүләт пакетын номиналь рәвештә тотучы буларак, без бик мөһим миссия башкарабыз: дәүләтнең һәм республика гражданнарының шәхси милек хокукларын югары дәрәҗәдә яклангланлыгын тәэмин итәбез. Соңгы елларда хезмәткәрләрнең югары һөнәри осталыгы һәм белемлелеге арту нәтиҗәсендә, без бик күп әһәмиятле һәм күпбаскычлы бурычларны үтәп чыктык. Россия Федерациясе законнарының масштаблы рәвештә реформалаштырылуы кыйммәтле кәгазьләр базарының инфраструктурасы үзгәрүгә дә йогынты ясады һәм, әлбәттә, безнең төп эшчәнлектә – депозитарлыкта чагылыш тапты. Төп көйләүчебез алышынды – хәзер ул Россия Федерациясенең Үзәк банкы. Шул рәвешле, хисап бирү дә, көйләү принциплары да үзгәрде. Без финанслар буенча хисап бирүнең халыкара системасына күчтек. Бөтен нәрсә дә бик тиз үзгәрә! Һәм зур канәгатьлек белән шуны билгелисем килә: безнең коллектив заман таләпләренә лаеклы рәвештә җавап биреп бара. Бу Депозитарийга Россиянең кыйммәтле кәгазьләр базары инфраструктурасында элеккечә алдынгы булып калу һәм республика икътисады үсешенә саллы өлешен кертү, халыкара мәйданда аның имиджын күтәрү мөмкинлеге бирә.

Рөстәм Ибраһимов,
«Татарстан Республикасының Үзәк депозитарие» АҖ генераль директоры

Александр Ефремов фотосы

Реклама

1 062 069 860 сум –
депозитарийның устав капиталы

Акционерларның 150 реестры.
Аларда номиналь тотучыларның счетлары ачылган

Депо счетларында **80 миллиард кыйммәтле кәгазь бар**

Әлеге бүләкне алу хөрмәтенә хуҗалык эшчәнлегендә катнашучыларның ил икътисади үсешенә, аның халыкара мәйданда ил имиджын күтәрүгә саллы өлеш кертүчеләр генә лаек була. ТР Үзәк депозитарие хезмәтләре лаеклы бәя алган, Россияне хокукый һәм икътисади үсешкә ия ил икәнен раслауга булышлык итә торган сыйфат һәм нәтиҗәлелекнең югары стандартлары үрнәге булып тора.

ДАИМИ ҮСЕШ – ДӨРЕСЛЕК БИЛГЕСЕ

Алга барыр өчен үткәннәр белән вакытында хушлаша белергә, җәһәт өйрәнеп, дөнья хәлләренә тиз арада җавап бирә белергә кирәк. Депозитарий хезмәткәре булу – бүгенге чынбарлыкта җаваплы вазыйфа, чөнки аның эше үзенчәлекле. Акционерлык җәмгыятенең күпчелек хезмәткәренең кыйммәтле кәгазьләр базарының депозитар эшчәнлеге буенча белгечлеккә квалификация аттестаты бар. Җитәкче сүзләренә караганда, Депозитарий коллективы зур түгел – нибары 20 кеше, әмма ул тотрыклы. Хәзерге вакытта «Татарстан Республикасының Үзәк депозитарие» АҖ хезмәткәрләре исемле кыйммәтле кәгазьләр ияләре реестрларында номиналь тотучының 150 дән артыграк шәхси исәбен хезмәтләндерә, аларны махсуслаштырылган 10 теркәүче алып бара. Ул теркәүчеләр депозитарий клиентларына кыйммәтле кәгазьләргә шәхси милек хокукларын яңадан теркәү һәм теркәүчегә үз вәкилләрен җибәрми генә реестрдан мәгълүмат алу мөмкинлеге бирә. Белгечләрнең югары компетентлыгы нәтиҗәсендә аның алдынгы партнер-предприятиеләре бүген кыйммәтле кәгазьләр базарында «Татарстан Республикасының Үзәк депозитарие» АҖнең күзгә күренеп торган өстенлекләрен күрә:

– нормативларның шактый өстенлеге белән лицензия таләпләренә ярашлылык;

– хәтәр очраклар белән даими рәвештә идарә итү һәм кыйммәтле кәгазьләргә хокуклар югалтуны булдырмый калуга юнәлтелгән чараларны камилләштерү;

– югары финанс тотрыклылыгы;

– клиентларның сер итеп саклана торган һәм шәхси мәгълүматларын ышанычлы саклануын тәэмин итү;

– клиентларның корпоратив бурычларын хәл итүгә юнәлтелгән электрон сервислар һәм яңа хезмәтләр эшләп, аларны кулланышка кертү;

– технологияләрне камилләштерү;

– компаниянең мәгълүмати ачыклыгы:

– компания турында актуаль мәгълүмат, финанс күрсәткечләрен бастырып чыгару;

– акционерлар, депонентлар һәм кызыксынучылар өчен мәгълүмат бирү.

Татарстан Республикасының Үзәк депозитарие офисының диварын менә шушындый раритетлар бизи. Бүген ул, кыйммәтле кәгазьләрнең документар формасы тулаем цифрга күчеп беткәннән соң, акция һәм облигацияләрнең элек нинди булуын искә төшереп тора.

2017 елда Эшкуарлар милли ассоциациясенең «Бердәм милли бизнес-рейтингы» кысаларында «Татарстан Республикасының Үзәк депозитарие» АҖ Әйдәп баручы продукция һәм хезмәтләр җитештерүче буларак танылган. Клиентларга йөз тоту сәясәте өлкәсендәге «КУЛЛАНУЧЫ САЙЛАВЫ. ЕВРАЗИЯ СЫЙФАТ МАРКАСЫ» Халыкара тармакара иҗтимагый программа кысаларында ТР Үзәк депозитариена Югары сыйфат культурасына ия предприятие исеме белән Мактау грамотасы тапшырылган.

4 октябрьдә «Татарстан Республикасының Үзәк депозитарие» АҖ 25 еллыгын билгеләде, ә 15 декабрьдә аның җитәкчесенә 50 яшь тула. Хезмәттәшләре Рөстәм Сәгыйть улы Ибраһимовны 50 яшьлеге белән котлыйбыз! Иң ихлас теләкләрне кабул итеп алыгыз! Ныклы сәламәтлек – Сезгә һәм якыннарыгызга!



Ул намус һәм вөҗдан кешесе, көчле һәм корыч ихтыярлы, тәвәккәл һәм принципларында торучан, шул ук вакытта нәфис һәм нәзакәтле. Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары, Арча район Советы рәисе урынбасары Любовь Михайловна Осина – әнә шундый ханым. 2018 елның декабрендә ул 60 яшьлек юбилеен билгеле.

Илшат Нуриев,
Арча муниципаль районы башлыгы, Арча район Советы рәисе

Хөрмәтле Любовь Михайловна!

Арча районы халкы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән тәбрикләргә рөхсәт итегез! Хезмәт эшчәнлегегез туган районыгыз белән бәйләнгән, 40 елга якын аның иминлеге хакына көч куясыз. Һәм Сез кайда гына эшләсәгез дә – китапханә системасы яки район хакимияте булсынмы – үз эшегезне башкарып кына калмыйсыз, ә аңа бөтен күңел җылыгызны саласыз, алга куелган бурычларны хәл итү өчен табигать биргән оештыру сәләтегезне, һөнәри осталыгыгызны эшкә җигәсез, башкарган вазыйфагызга кыюлык һәм җаваплылык белән якын киләсез. Районның китапханә системасында эшләгән чорыгызда Сезнең индивидуальлегегез, энтузиазм рухы һәм бетмәс-төкәнмәс энергиягез ачылды. Мәдәният өлкәсендә уңышлы эшләрегез өчен 2000 елда Сезгә «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде. Менә 16 елдан артыграк Сез район хакимиятендә җитәкче вазыйфаларда эшлисез, 12 ел район башлыгы урынбасары эшен башкарасыз. Шушы җаваплы вазыйфада Сез район иминлеге хакына катлаулы бурычлар хәл итәсез, һәм район тормышындагы уңай үзгәрешләр Сезнең исем белән бәйле дип, тулы ышаныч белән әйтергә була. Сезнең район территориясендә җирле үзидарә үсешенә, өстенлекле бурычларны хәл итүгә, халыкның тормыш сыйфатын күтәрүгә керткән өлешегез дә бәяләп бетергесез.

Хөрмәтле Любовь Михайловна! Районда Сезне булдыклы җитәкче, Арча җиренең чын ватанпәрвәре, сүз һәм эш кешесе буларак беләләр. Сезнең бөтен тормышыгыз һәм хезмәт баскычларыгыз Арча белән, туган җиргә сак мөнәсәбәт, тамырларга тугрылык белән бәйләнгән. Сез – бик күпләр өчен үрнәк булырлык шәхес. Сезнең хезмәт казанышлары лаеклы бәһасен алган һәм күпсанлы бүләкләр белән билгеләнгән, әмма иң зур бүләк – коллективтагы абруегыз һәм ихтирам, якташларыгызның хөрмәтләве. Кешеләргә карата кылган игелекләрегез үзегезгә өчләтә кайтсын, уңыш һәм иминлек Сезнең тугры юлдашларыгыз булсын. Чын күңелдән Сезгә сәламәтлек, күп шатлыклар һәм бәхетле озын гомер телим!

Реклама
Фотолар Арча муниципаль районыннан алынды

Илшат Галимуллин,
Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе

Хөрмәтле Любовь Михайловна!

Кем әйтмешли, «бер тәртәгә җигелеп», без Сезнең белән 16 елдан артыграк бергә эшлибез, һәм миннән Любовь Михайловнаны җитәкче буларак нинди сыйфаты аерып тора, дип сорасалар, болай дияр идем: һәр гамәлендә үз-үзенә ышаныч һәм тәвәккәллек. Сез һәрвакытта да килеп туган теләсә кайсы катлаулы вазгыятьтә дөрес карар кабул итә аласыз, максатларыгызны төгәл беләсез һәм куелган бурычларны хәл итүгә ирешәсез. Сезнең һөнәри юлыгыз ныклык һәм хезмәт сөючәнлек, һәртөрле башлангычларга һәвәслек һәм тәрбиялелек, гаҗәеп дәрәҗәдә эшкә сәләтле булуыгыз турында сөйли. Хезмәттәшләрегез һәм туган халкыгыз ихтирам итә, алар Сезне ару-талу белмәс эш кешесе, тормышта үз урынын тапкан кабатланмас шәхес буларак белә. Сезнең китапханә методистыннан башланган хезмәт юлыгыз 12 ел дәвамында район башлыгы урынбасары вазыйфасында дәвам итеп, күп җиңүләр һәм казанышлар белән билгеләнә. Үз эшегезне белеп башкаруыгыз, битараф булмавыгыз, кешеләрне уртак идея белән мавыктыра, аларны берләштереп, фикердәшләрегез итә алу – Сезнең уңыш сере.

Кадерле Любовь Михайловна! Сезнең киеренке дә, шул ук вакытта кирәкле дә тулы канлы һөнәри эшчәнлегегездә якты, күңел җылысы белән тулы мизгелләр мөмкин кадәр күбрәк булсын иде. Сезгә һәм гаиләгезгә ныклы сәламәтлек, тынычлык һәм иминлек! Юбилей елы Сезнең өчен чынга ашкан хыяллар елы булсын!

Фәнис Исмәгыйлов,
«ТР Арча муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе

Хөрмәтле Любовь Михайловна!

Безнең учреждениенең коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котларга рөхсәт итегез! Сезнең авылда социаль проблемаларны хәл итүгә керткән өлешегез олы ихтирамга лаек. Арча районының бик күп казанышлары Сезнең тырышлыгыгыз, ныклы ихтыяр көчегез һәм әзлекле эшчәнлек алып баруыгыз белән дә бәйле. Район үсешендә Сезнең өлешегезне бәяләп бетерү кыен.

Хөрмәтле Любовь Михайловна, артта – еллар, Сез алар белән горурлана аласыз, янәшәгездә – тугры дуслар, хезмәттәшләр, искиткеч балалар, оныклар, лаеклы эшегез. Киләчәктә дә башлаган эшләрегезгә уңыш һәм иминлек юлдаш булсын! Сезгә һәм якыннарыгызга ныклы сәламәтлек һәм иминлек! Чын күңелдән районыбыз халкы иминлеге хакына алга таба да шулай ук уңышлы хезмәт итүегезне телим! Кәефегез һәрвакыт күтәренке булсын!

Реклама

КҮННӘН АТКА ӘЙЛӘНГӘН АВЫЛ

Ел дәвамында Әгерҗе, Минзәлә, Бөгелмә кебек ерак районнарда булып, андагы халыкның яшәеше, көнкүреше белән танышып кайттык. Кызыклы исемле авылларны барлап, каян килеп чыкканнарын ачыклап, билгеле. Ә менә якындагы гына Питрәч районы ни өчендер гел читтә кала килде. Шушы «гаделсезлекне» төзәтергә ниятләп, Питрәч якларына кузгалдык.

Автор:
Руфия Фазылова

СОКЛАНГЫЧ ТА, КЫЗГАНЫЧ ТА...

Питрәчтән биш кенә чакрым ераклыкта урнашкан Күн авылына килеп тукталдык. Русча исеме – Конь. Күннән ничек атка әйләнгән ул? Бу хакта баш ватучылар күп, ишетеп без дә беләбез. Сәбәбе бик гади, хәтта гадәти. Безнең татар исемнәрен рус теркәүчеләре төрлечә язып бозганнар бит. Күн дә – шундый ялгыш теркәүгә дучар булган авылларның берсе.

Күн авыл җирлегенә өч авыл керә – Күн, Кызыл Яшьләр, Әлбәден. Иң зурысы – Күн авылы, биредә 800 дән артык кеше яши, 399 хуҗалык бар. Гомер-гомергә ул зур авыл саналган. Дөрес, хәзер дә буш йортлар күп түгел. Өстәвенә, кыр җирләрен аерып алып, 200 гектар махсус индивидуаль төзелеш җире итеп рәсмиләштергәннәр. Гади генә итеп әйткәндә, якын киләчәктә Күн авылы тагын 200 гектарга зураячак. Ул җирләрнең инде яртысы сатылып беткән. Казаннан кайтучылар күп икән. Авылның буш йортларын дача итеп алалар, ди. «Җәен хәтта күп кешене танымыйбыз да», – диде авыл кешеләре.

Күн гаҗәеп хозур җирдә урнашкан: авылны бөтен яклап нарат урманы чолгап алган. Таулар, чишмәләр, янәшәдә генә Мишә елгасы ага. Дистә еллар элек Мишә бөтенләй авыл эченнән аккан. Язын, елга ташып, иген басуларын су баскач, Мишәне авыл башыннан уза торган итеп ерганнар. Бүген исә ул урында кечкенә генә елга бар, аны халык «Үле Мишә култыгы» дип йөртә.

Бер гаҗәеп күренешкә тап булдык: буш өйләр аз булса да, мәктәптә бала саны 29 гына икән. Урта мәктәпне тугызъеллык итеп калдырганнар. Моның сәбәбе берничә: иске йортларны сатып алучылар – пенсия яшендәге, ягъни яшь баласы булмаган кешеләр. Икенчесе: яңа бүленеп биргән җиргә яңа йорт салучылар нигездә Казанда эшләүчеләр. Алар балаларын да үзләре белән йөртә. Өченчесе һәм иң гаҗәбе: җирле халык балаларын Питрәч урта мәктәбендә укыта, бигрәк тә соңгы берничә елда. Сәбәбе бик гади – Күн мәктәбендә татарча укыйлар, Питрәчтә исә – русча. Ата-ана, балаларның БДИ ны рус телендә тапшырасы бар, дип, баласын район үзәгенә йөртү ягын карый. Хәтта нәниләрне бакчага да Питрәчкә алып баралар икән. Имеш, русча өйрәнә торсыннар. Менә шундый аяныч та, шаккаткыч та күренеш...

Күңелне сөендергән күренешләр дә бар: авылда юллар каралган. Аны республика авыл юлларын төзекләндерү программасы буенча да, үзсалым акчасына да эшләгәннәр. Быел үзсалым акчасына тагын бер урамның юлын карарга ниятлиләр икән. Кое, чишмәләр дә ясалган. Күн авыл җирлеге башлыгы Рифгать Баһауов белән зиратка да барып килдек. Узган ел аның кырыйларын тотып, капка эшләгәннәр. Башка авылларда мондый хәлне күргән юк иде: Күн зиратына ут керткәннәр. Көпчәкле будка алып кайтканнар, ул җылытыла.

– Кышын бабайлар, кабер казучылар кереп җылынсын өчен шулай эшләдек, – диде авыл җирлеге башлыгы. Тагын әле зиратка махсус перфоратор сатып алганнар. Аныcы кышын туң җирне казыганда кирәк, дип аңлатты җитәкче.

– Авыл зур бит, аннан чыккан кешеләр дә күп, – диде Рифгать абый. – Мәет җирләү бүген шәһәр җирендә зур проблема. Вафат булгач, читтә яшәгән авылдашларны да бирегә алып кайталар. Урын җитмәгәч, зират янәшәсендә тагын бер гектар җир бүлеп бирелде, кырыйларын тотып алдык...

Фото: Александр Ефремов

«НИЧЕК АЯККА БАСТЫРЫРСЫҢ?!»

Авылларга баргач, гыйбрәтле тормыш юлы үткән берәр өлкән яшьтәге кеше белән очрашырга тырашабыз. Күндә дә андый сөйкемле, мөлаем әби белән таныштык. Хәдичә апа Нәҗметдинова бирердә туган, гомере буе ата-бабасы нигезендә яшәгән. Башта сукыр әнисе, авыру абыйсын караган, картайган көнендә ялгызы калган. Алай да моңаеп, зар елап утыра торганнардан түгел ул. Һаман да авыл мәдәният йорты сәхнәсендә җырлап-биеп йөри. Күндә «Яшь йөрәкләр» ансамбле бар. Заманында алар Россиянең төрле шәһәрләрендә чыгыш ясап, конкурсларда призлы урыннар яулаганнар. Хәер, хәзер дә район күләмендә узган чаралар алардан башка үтми икән. «Яшь йөрәкләр»дә бүген сигез хатын-кыз чыгыш ясый. Ансамбльнең иң өлкән кешесе Гөлҗиһан апага – 91 яшь.

– Киләсе елдан ансамбльне ташлыйм, дип әйтәм дә, үгетли-үгетли яңадан чакыралар, – диде Хәдичә апа. – Сиксән сигезне тутырдым бит, сәхнәдә йөрергә оят хәзер. Әле менә тагын концерт куярга әзерләнәбез, көн аралаш репетицияләргә йөрим. Кеше арасына бер чыгып керү начар түгел, тик картайдык инде.

Хәдичә апа кырык бер ел Питрәч балалар хастаханәсендә шәфкать туташы булып эшләгән. Аның турында авылдашлары кешелекле, кече күңелле, диделәр.

– Балаларны бик яратам, – диде Хәдичә апа. – Нишлисең, Аллаһы Тәгалә миңа сабый сөяргә язмаган. Югыйсә ике тапкыр тәрбиягә бала алырга талпынып карадым. Беренчесендә әни исән иде әле. Бишенче баласын тапканда вафат булган ананың сабыен безгә алып килделәр. Буш вакытым булган саен шул кызчыкны алып сөям, астын алыштыра идем. «Әни, бер кыз тәрбиягә алсам, үстерә алырбызмы икән?» – дидем. Әни каршы килмәде. «Картайган көндә үзеңә иптәш булыр, ал, кызым», – диде. Мин документлар җыеп йөргәнне белгәч, кызның әтисе баланы хастаханәдән алып китте. Туганнары кушкан бугай. Икенче тапкыр әтиәнисе үлгән баланы алырга теләдем. Ул вакытта әни мәрхүм иде, абый белән генә яшәдек. Ул трактор белән капланып, гарипләнде. Тәрбиягә бала алырга теләгәнемне белгәч, туганнар: «Хәдичә, авыру абыең да бар. Баланы ничек аякка бастырырга җыенасың? Көн саен эшкә барасың, ярдәм итүчең юк», – диделәр. Мин инде сабыйга ияләнгән идем, бер яшьлек кыз иде ул. Шулай итеп кулымнан диярлек тартып алып, сабыйны икенче гаиләгә тәрбиягә алып киттеләр.

Хәдичә апаның йортына замана цивилизациясе кагылмаган: су кермәгән, кер юу машинасы юк, бәдрәф кебек уңайлыклар турында әйтеп тә тормыйм. Тик әби боларның берсен дә кирәксенми:

– Йортта ирләр булмагач, су кертергә курыктым. Тишелеп, агып ятса нишләрмен. Җәй көне күп итеп яңгыр суы җыеп куям. Эчәргә суны Изгеләр чишмәсеннән апамның кызлары китерә. Әле, Аллага шөкер, үз-үземне йөртәм, урамнарга чыгып йөрим. Апаның кызы гаиләсе белән Күндә яши, гел килеп, хәлемне белеп торалар. Шулай аякта йөреп торырга гына язсын.

Хәдичә апа Нәҗметдинова бирердә туган, гомере буе ата-бабасы нигезендә яшәгән.

Исмәгыйлевлар капка төбендә бүген дә берничә трактор тора.

« ТРАКТОРЧЫ СУ ЭЧТЕ АННАН..»

Күп балалы Исмәгыйлевлар гаиләсендә булдык. Авылдагы иң тырыш, күркәм гаиләләрнең берсе икән алар. Дүрт буын бергә гомер иткән: 101 яшьлек Кафия әби (әле күптән түгел генә вафат булган), алты дистәне тутырган дәү әти – Касыйм абый, Илсөяр апа, яшь гаилә – Алмаз белән Лилия (утызар яшь) һәм аларның дүрт ул-кызлары. Үз көчләре белән ике катлы йорт җиткергәннәр. Бүген шунда гөр килеп, башкаларга үрнәк (авыл кешеләре Исмәгыйлевлар турында шулай диде) булып яшәп яталар. Хуҗалыкта ике сыер, үгезләр, кош-корт тоталар. Алмаз төрле эшләрдә хезмәт куя, Лилия әлегә өйдә генә.



– Безгә авыл мәктәбендә дә бик рәхәт, – ди Лилия Исмәгыйлева.

– Бездә һәркемгә эш җитә, – диде Лилия. – Җәен – бакчада, мал-туар арасында. Балалар да кечкенә, ишле гаиләгә ашарга пешереп торырга да бер кеше кирәк.

– Казан кызы икәнсең, ничек авылга кайтырга батырчылык иттең? Әле җитмәсә каенана, каенатa белән яшәргә, – дим.

– Ике каенана янына, – дип елмайды яшь килен. – Кафия әбиебез дә бар иде бит. Ясалмалык белән әйтү түгел: әнине дә, әбине дә беренче көннән үк үземнекеләр кебек яраттым. Мин әнидән башка тормышны күз алдына да китерә алмыйм, уң кулым да, сул кулым да ул. Ә авыл тормышы куркытмады мине. Әти-әнием Күннән. Балачагым, яшьлегем монда үтте. Авыл тормышын кечкенәдән күреп үстем. Кияүгә килгәч тә, сыер савуны үз өстемә алдым. Әни карышып торган иде, аннан күнде. Әле өч сыер асраган вакытлар да булды...

Исмәгыйлевларның ике кызлары – Азалия, Зәмирә Күн мәктәбендә укый, дүрт яшьлек игезәк балалары – Зөһрә белән Зәмир – Күннең балалар бакчасына йөри. Балалар бер дигән итеп татарча сөйләшә:

– Сез русча укысыннар, дип, кайбер авылдашларыгыз кебек балаларны Питрәчкә йөртү «модасына» кушылмагансыз икән, – дим.

– Безгә авыл мәктәбендә дә бик рәхәт. Икенче кызыбыз Зәмирә быел беренче сыйныфка китте, җиде бала укыйлар. Игътибар күп. Ә Питрәчкә илтсәң, бала иртәнге җидедә чыгып китә, кайтканда тагын автобусны көтеп утыра. Җитмәсә, класста егермедән артык бала.

Килен каенана туфрагыннан ярала шул. Илсөяр апа да, Лилия кебек, үткен, батыр. Районның атаклы тракторчысы ул. Утыз ел «Т-16» тракторында эшләгән. Унсигез яшеннән рульгә утырган.

– Өр-яңа тракторны ничек яп-яшь, тәҗрибәсез кызга тапшырдылар? – дип сорыйм Илсөяр ападан.

– Бер ел «Белорус» тракторында ярдәмче булып эшләгән идем. Яшьләргә юл булсын, дип, минем белән бергә Питрәч СПТУсында трактор курсларында укыган кыз – Рәйсә белән икебезгә бер өр-яңа «Т-16» бирделәр. Рәйсә бер ел эшләгәч, кияүгә чыгып, Казанга китте. Шулай итеп трактор үземә генә калды. Пенсиягә чыкканчы эшләдем.

Илсөяр апа әтисез үскән. Йомышка гел кешегә йөрергә туры килгән. «Эх, үскәч, тракторга утырам да кешедән ярдәм сорап йөрмәм», – дия торган була. Кызның хыялы тормышка ашкан – печән, салам алып кайту, басудан бәрәңге ташу дисеңме – барысын да тракторы белән алып кайткан.

Илсөяр апа белән сөйләшкәндә халык арасында йөри торган бер мәзәк хәл искә төште. Бер әби кулын юарга дип инешкә иелгән. Моны күзәтеп торган малай йөгереп килгән дә: «Әби, әби, бу суда кулыңны юма, аннан тракторчы абый су эчте», – дигән. Чынлап та, тракторчы һөнәре чын ирләр хезмәте кебек, пычрак була ул заманнарда.

– Ә мин пычранмый идем, – диде Илсөяр апа. – Руль артында йөргәндә майланмыйсың. Ә кара эшләр булганда, һәрвакыт халат кидем.

– Хатын-кыз, дип, ир-атлар сезгә юл куя, ярдәм итәләр идеме? – дим.

– Ирләр белән беррәттән эшләдем. Ә көпчәк алыштырганда, башка авыр эшләрдә ярдәм итәләр иде үзе. Ирем Касыйм һәрвакыт уң кулым булды.

Исмәгыйлевлар капка төбендә бүген дә берничә трактор тора. Дөрес, Илсөяр апа хәзер руль артына утырмый икән, трактор йөртү таныклыгының вакыты чыккан. Яңасын алыштырып тормаган. «Күп йөрдем, хәзер «дилбегәне» улыма тапшырдым», – диде.

Сокландык әлеге гаиләгә: тырышлар, сөйкемлеләр. Илсөяр апа җөмлә саен Аллаһка рәхмәт укый, шөкерана итә:

– Каенанам Кафия әни миңа карата бик җылы, мәрхәмәтле булды. «Мин киленемә әнигә караганда да яхшырак булачакмын», – дия идем. Аллага шөкер, тату яшибез. Алга таба да шулай булсын, дип, гел дога кылам...

Рәүф абый Ахунов (уңда) 67 яшендә яңача яшәргә уйлаган.

«ОНЫКЛАРГА – МИРАСКА!»

Авылда фермер булып эшләүчеләр дә, яңа эш башлаучылар да байтак. Шуларның берничәсе белән күрештек. Рәүф абый Ахунов 67 яшендә яңача яшәргә уйлаган. Пай җирен алып, авыл башында сиксән сыер өчен ферма төзеп ята хәзер. Дәүләттән 3 миллион сум акча – грант алган.

– Ферма бинасын төзү өчен 1 миллионнан артык сум акча китте инде, – диде. – Әле җылылык, ут, су кертәсе бар. Язга таналар алып кайтырбыз, дибез.

« Бу яшьтә курыкмыйча шундый эшкә ничек алынырга кирәк? Мөгаен, йорт тулы бала-чагасы бардыр». Башка килгән беренче фикер әнә шул булды. Юк, ялгышканмын икән, Рәүф абый тормыш иптәше белән генә яши.

Уенын-чынын кушып, фермер менә нәрсә диде:



Рәфыйковлар дәүләт ярдәменә башка өмет итми, кул селтәгәннәр.

– Оныкларга пенсия булмаячак. Үзем исән чакта аларны ач калдыра алмыйм. Хыялым – монда йорт салу, өч оныгымның да яшәргә кайтуын телим.

– Кайтсалар... – дигән булам.

– Кайтырлар. Дөресен генә әйткәндә, алар белән киңәшеп эшләдем. Оныгым Казан дәүләт аграр университетында укый, агроном булачак. Диплом алгач, Алла боерса, монда кайтачак. Шәһәрдә нәрсә бар анда, шул ыгы-зыгыда җан асрап яшисез...

Икенче фермер Илгизәр абый Рәфыйков, безнең кайдан икәнне белгәч, ярсый-ярсый зарын сөйләргә керешге:

– Языгыз әле, белсеннәр! Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы эшеннән канәгать түгел мин! Гел аяк чалалар!

Бактың исә, Рәфыйковлар күпләп каз, сарыклар үстерү белән шөгыльләнә икән. Күндә биш гектар җирләре бар. Шунда ферма салырга ниятләгәннәр. Моның өчен дәүләттән грант алырга өметләнгәннәр. Тик сентябрьдә җыйган документларын, дөрес түгел, дип, кире кайтарганнар.

– Шуңа аптырыйм: документларны сентябрь башында җыеп тапшырган идем, – диде Илгизәр абый. – Иртәрәк хәбәр итсәләр, төзәтеп яңадан илткән булыр идем. Ә алар соңгы көнгә кадәр тоттылар да: «Дөрес түгел», – дип шалтыраттылар. Иртәгәсен инде вакыты чыкты. Күпме көч, күпме хезмәт юкка булды.

Рәфыйковлар дәүләт ярдәменә башка өмет итми, кул селтәгәннәр. Язга үз көчләре белән кредит алып, ферма салырга ниятлиләр.

...Менә шулай яши Күн халкы: тырыш, горур. Кайбер төбәктә халык журналистлар алдында җирле җитәкчегә гел мәдхия кыла. Күндә исә кешеләр икенче: курыкмыйча фикерен әйтә, ялагайланмый.

Айдар Хафизов, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты:

– Күн – минем туган авылым. Аның турында сәгатьләр буе сөйли алам. Гаҗәп матур, бай авыл. Тарихына килгәндә, ул хәзерге урынга 1552 елдан соң гына килеп урнаша. Аңа кадәр хәзерге Вознесение бистәсе урынында була. Иван Грозный Казанны яулап алганнан соң, безнең бабайлар шәһәрдән ераккарак – хәзерге тирәләргә күчеп утыра. Документларда бүгенге урынга 30 гаилә килгән дип әйтелә.

Авылның исеме исә Коръән аяте белән бәйле дип фаразлана: «Вәйлә күн», ягъни «Риза булсаң кал» дигән мәгънәдә. Бабаларыбыз, монда килгәч, тыныч, кеше яшәми торган урынны күрәдә, бу җирләргә разый булып, туктый.

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ КАЙЛАРДА САТЫЛА

КАЗАН

«МИР ПРЕССЫ – РЕГИОН» ҖЧҖ

«ДЕЙЛИ» КИБЕТЛӘРЕ

К. Маркс ур., 59
Н. Ершов ур., 78
Зорге ур., 93
«Тукай мәйданы» метро станциясе
Н. Ершов ур., 1 а («Корстон»)
«Горки» метро станциясе
Белинский ур., 4
«Җиңү проспекты» метро станциясе
Чуйков ур., 69
Парк ур., 6
Короленко ур., 81
Фрунзе ур., 5
Мусин ур., 68 б
Лаврентьев ур., 9
Даурия ур., 40

«ТАТАР КИТАП НӘШРИЯТЫ» ТР ДУП

Декабристлар ур., 2
Бауман ур., 19
Бауман ур., 29/11

«ГОРПЕЧАТЬ» ЯАҖ

Фрунзе ур., 7
Пушкин ур., 2
Сахаров ур., 13
Межлаук ур., 15
Ямашев пр., 49
Вишневский ур., 2
Н. Назарбаев ур., 47
Восстание ур., 83
Кави Нәҗми ур., 7
К. Цеткин ур., 17/20
Восстание, 23 / Декабристлар ур.
Копылов ур., 5/1
Адоратский ур., 29
Максимов ур., 34/24
Липатов ур., 5
Достоевский ур., 74 а
Себер тракты, 7
Декабристлар ур., 189
Татарстан ур., 72
Даурия ур., 36
Даурия ур., 23
Автовокзал
«Казан Оргсинтез»
Горький шоссесы / Можайский ур.
Н. Ершов ур., 53
Кошевой ур., 16
Декабристлар ур.,178 а
Восстание ур., 56
Айдаров ур., 8 а
Окольная ур., 23
Себер тракты, 34
Декабристлар ур., 102
Челюскин ур., 31
Краснококшайская ур., 164
Максимов ур., 4
Ш. Усманов ур., 12
Гвардейская ур., 42
Батыршин, 16 / Коләхмәтов ур.
Революция ур.
Ильич ур., 30
Попов ур., 7
Беломорская ур., 73
Газовая ур., 9
Декабристлар ур., 115
Н. Назарбаев ур., 35
Черноморская ур., 3
Восстание ур., 6
Калинин ур., 73
Мәүлетов ур., 17
Гагарин ур., 22
Гагарин ур., 12
Халитов ур., 34 ж
Белинский ур., 9
Фучик ур., 72
Тынычлык ур., 33
Карбышев ур., 13
«Океан»
Чуйков ур., 38
Н. Ершов ур., 32
Гвардейская ур., 38
Чехов ур., 6
Халезов ур., 21
(Дәрвишләр бистәсе)
Короленко ур., 89
Декабристлар ур., 150

«ТАТАРСТАН ПОЧТАСЫ» ФПЭИ ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕ

Сахаров ур., 27
Мәүлетов ур., 9
Забайкальская ур., 3
Маршал ур., 25
Һ. Такташ ур., 75
Мехчылар ур., 3
Бауман ур., 37
Меридиан ур., 14
Әмирхан пр., 10 а
Максимов ур., 2
Салмач, Тынычлык ур., 6 а
Адоратский ур., 29 а
Адоратский ур., 12
Мусин ур., 68
Гаврилов ур., 40
Җиңү пр., 17
Ю. Фучик ур., 34
Кремль
Нокса авышлыгы, 1
К. Маркс ур., 44
Яңа аэропорт
Татарстан ур., 11
К. Цеткин ур., 33
Фрунзе ур., 1
Айдаров ур., 22
Декабристлар ур., 191
Юбилей ур., 1/43
Вишневский ур., 14
Волгоград ур., 22
Шатура ур., 155
Качалов ур., 95
«Оргсинтез» заводы
Беломорская ур., 1
Карьер, Нокса ур., 29
Мирный, Яңа Дәүләкәй ур., 16 а
Нагорный, Круговая ур., 12
Павлюхин ур., 116
Рәхимов ур., 33
Ирек мәйданы, 1
Черноморская ур., 3
Петровск, Үзәк ур., 1
Тынычлык ур., 45
Гвардейская ур., 42
Яңа Юдино ур.,140
Красиков ур., 8
Завокзальная ур., 57
Альберт Камалиев ур., 12
Беломорская ур., 73
Зур Урам, 11
Я. Гашек ур., 1
Дәрвишләр бистәсе,
Краевая ур., 8 а
Товарищеская ур., 28/70
Б. Заречная ур., 22
Кадыш, Калинин ур., 1
Кремль
Оренбург тракты

Реклама 16+

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

Реклама 16+

Безнең Инстаграмда – «Татарстан»ның йөрәге!

Фото: ООО «Ренессанс». Реклама

- Скульптуры
- Каминные часы
- Мебель
- Картины
- Иконы
- Ювелирные украшения
- Серебро
- Фарфор
- Монеты
- Радиолы
- Ордена, знаки
- …и многое другое!

Ренессанс®

антикварный салон

г. Казань, КРЦ «РОДИНА»
ул. Баумана, д. 44 (1–2-й этажи)

Новый салон: ТЦ «КОРСТОН»
ул. Н. Ершова, д. 1А (1-й этаж)

www.antik-renessans.ru

Инстаграм: antiksalon